# Самарские татары
# Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 3 (36), ИЮЛЬ – СЕНТЯБРЬ, 2022



КЕМ УЛ - ТАТАР? ЯГЪНИ, БӨЕК ТАТАР ИЛЕ КОНТУРЛАРЫ



## ИСЛАМСКАЯ ЖЕМЧУЖИНА НА САМАРСКОЙ ЗЕМЛЕ



БЕЗ ПРОШЛОГО НАМ НЕ ПОСТРОИТЬ БУДУЩЕГО



ТАТАР ТЕЛЕ: ИЛДӘН ЕРАГАЙГАН САЕН – КАДЕРЛЕРӘК



КАК БУЛГАРЫ ИСЛАМ ПРИНИМАЛИ

6+

# Хөрмәтле дуслар!

Сезнең игътибарыгызга журналыбызның көзге санын тәкъдим итәбез. Гадәттәгечә, аның битләреннән Самар татарлары тормышындагы вакыйгалар турында укып белә аласыз.

Һичшиксез, бөтен мөселманнар өчен Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе булып тора. Бу дата федераль масштабта билгеләп үтелә, шуңа күрә бәйрәм чаралары илебезнең төрле почмакларында уздырыла. Әлбәттә, Самар өлкәсе дә читтә калмады. Реконструкциядән соң Тарихи мәчетебезне һәм Ширяево бистәсендә Истәлек билгесен ачу тантаналары нәкъ шушы юбилейга бәйләнгән иде.

Яңартылган Тарихи мәчеткә былтыр 130 ел тулды. Ул хаклы рәвештә Самар архитектурасының тагын бер энҗе бөртегенә әверелде. Бу санда гыйбадәтханәне ачу чарасы турында укып белерсез.

Бу санда төрле һөнәр ияләре – укытучылар, фермерлар, чәчтарашчылар, кондитерлар турында да мәкаләләр урнаштырылды. Аларның барысы да сезнең игътибарыгызга лаек, хөрмәтле укучыларыбыз.

Без журналыбызны төрле яшьтәге кешеләр өчен кызыклы ясарга тырышабыз.

Бергә булыйк! Барыбызга да иминлек, тынычлык насыйп булсын!

# Дорогие друзья!

Рад представить вам осенний номер нашего издания. Как всегда, со страниц журнала мы постарались рассказать вам о всех более или менее значимых событиях в жизни самарских татар, произошедших за последнее время.

Безусловно, главным событием для всех мусульман стало празднование 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией. Этой дате был придан федеральный масштаб, и праздничные мероприятия прошли по всей стране. Не стала исключением и наша область, где к этому юбилею было приурочено открытие после многолетней реконструкции Самарской Исторической мечети и памятного знака в селе Ширяево. Обновленная мечеть, справившая в прошлом году свое 130-летие, по праву стала еще одной архитектурной жемчужиной Самары. О том, как проходило открытие, читайте в свежем номере журнала.

В этом номере журнала мы также представляем целую серию материалов о людях, проявивших себя в различных профессиях. Это – учителя, фермеры, парикмахеры, почтальоны, кондитеры. Все они достойны того, чтобы наши читатели узнали об их достижениях.

Мы делаем наш журнал для людей разных возрастов и интересов. Будьте с нами, читайте нас! Благополучия нам всем и мира!



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*"Самар татарлары" журналы мөхәррире*


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –** президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –** председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович –** гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –** главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Махмутова Альбина Харисовна –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –** старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –** председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –** директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –** член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширязданов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:

Исламская жемчужина на Самарской земле........ 6
Тарихыбыз - яшьләр кулында........ 9
В Самаре отпраздновали День дружбы народов........ 10
Кем ул - татар? Ягъни Бөек Татар иле контурлары........ 12
Залия ХИСАМИ: “Радиобыз үзгәрмәде, заман үзгәрде»........ 21
Теләк булса – бар да була........ 23
Татар теле: илдән ерагайган саен – кадерлерәк........ 26
«Туган телеңдә бер генә сүз дә белмичә, мин – татар, дип күкрәк сугып йөрү дөрес түгел, дип саныйм»........ 29
Үз гомеренә балаларда ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләгән мөгаллимә........ 33
Кешедәге бар булган сыйфатлар гаиләдә тәрбияләнә........ 36
Без прошлого нам не построить будущего........ 38
«Иң яхшы укытучы»ны зурлап каршы алдылар........ 40
Как булгары ислам принимали........ 41
«Великая замятня»........ 43
Погасла яркая звезда среди татарок........ 48
Самарцы – почетные граждане в Оренбуржье........ 57
Первая книга – в 23 года, последняя – в 88 лет........ 75
Лечить больного, а не болезнь........ 85
Бер гасырлык үрнәк тормыш........ 91
“Өйләнгәндә үз ишеңне эзләргә кирәк”........ 92
Авылның матурлыгын, аның бәрәкәтен шунда яшәгән кешеләр булдыра........ 96
Хат ташучы... Бар гомере юлда. Юлда көз, кыш, ямьле җәйләр дә........ 98
Предвестники благополучия........ 101
«Тортларымны «бисмилләһ» әйтеп пешерәм»........ 106
«Татар халык җырлары миндә тирән хис-тойгылар уята»........ 109
Балыклы авылы кызы үз брендын булдырган........ 112
Безнекеләр - лидер........ 113
Разные традиции одного народа........ 114
Дары природы в традиционной кухне........ 116
О некоторых особенностях традиционного хозяйства заволжских башкир........ 118



45 МУЛЛА-ОБМАНЩИК



64 И НУЖЕН СТАЛ БЕРЕГ ТУРЕЦКИЙ




88 КҮҢЕЛЕ МИҺЕРБАНЛЫК БЕЛӘН ТУЛЫ



103 «ХӘЙРИЯЧЕЛЕК БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ БАШЛАГАЧ, РУХИ ЯКТАН БАЙЫЙ ТӨШТЕМ»

## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **магазин «Булгар» на территории Соборной мечети Самары.**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 250 рублей, стоимость номеров за 2021 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**
**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**

Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «СЛОВО»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 310, тел. (846) 267-36-82

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 3 (36), июль–сентябрь, 2022 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 10 октября 2022 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная

## МИННИХАНОВ С РАБОЧИМ ВИЗИТОМ ПОСЕТИЛ ИРАН

Президент Татарстана посетил в Тебризе кондитерскую фабрику, ознакомился с производством, обсуждались вопросы возможной поставки продукции в Татарстан. А днем ранее президент встретился с представителями деловых кругов Восточного Азербайджана в городе Тебриз.

*trt-tv.ru/news*



Губернатор провинции отметил, что этот официальный визит даст возможность глубже проработать вопросы сотрудничества. Состоялась презентация экономического и промышленного потенциала Татарстана. Рустам Минниханов также посетил в Иране завод по производству грузовиков компании DARIC, она стратегический партнер КамАЗа в России. В структуру компании входят более 20 дочерних предприятий по таким направлениям, как авиация, горное дело, металлургия, производство автомобилей и прицепов, строительство.

## КАЗАНЬ ВОШЛА В ТОП-5 ПОПУЛЯРНЫХ ТУРИСТИЧЕСКИХ НАПРАВЛЕНИЙ СРЕДИ РОССИЯН

*islamnews.ru*



В этом году Казань стала одним из наиболее популярных городов для летнего отдыха у россиян, сообщает ИА «Татар-информ».

«В этом году у нас топ-5 сложился из Алтая, Казани, Москвы, Нижнего Новгорода и Санкт-Петербурга», – сообщил на пресс-конференции медиагруппы «Россия сегодня» директор по работе с органами государственной власти ВЦИОМ Кирилл Родин.

По его словам, большинство туристов привлекают в эти места красивая природа и чистый воздух, а также возможности для активного отдыха. Порядка 9% путешественников едут полюбоваться достопримечательностями и архитектурой.

Как сообщил Кирилл Родин, главным недостатком отдыха в России туристы считают его высокую стоимость, плохие погодные условия и слабо развитую транспортную инфраструктуру.



## НОВОЕ ЗДАНИЕ ТЕАТРА ИМ. КАМАЛА НАЧНУТ СТРОИТЬ УЖЕ В СЛЕДУЮЩЕМ ГОДУ

*ТАСС*

Постройка нового здания Татарского государственного академического театра им. Камала начнется не позднее 2023 года. Об этом сообщил президент республики Рустам Минниханов

«Мы должны получить проектную документацию. После того, как проект будет, мы должны пройти экспертизу. Если в этом году не успеем, значит, на следующий год железобетонно. Объект уникальный, его нельзя начинать без проработки, и хорошей документации, и одобрения всех ведомств. Мы быстро построим, главное, пусть документация будет», – рассказал руководитель республики.

Напомним, что над проектом нового здания будет работать консорциум архитекторов из России, Японии и Германии. Новое здание татарского театра будет построено на правой стороне озера Кабан, на территории у пересечения улиц Назарбаева и Хади Такташа.




«Татар сүзе» халыкара телевизион нәфис сүз бәйгесенә гаризалар кабул итү дәвам итә.

*matbugat.ru*

## «ТАТАР СҮЗЕ» БӘЙГЕСЕНӘ ГАРИЗАЛАР ОКТЯБРЬ АХЫРЫНА КАДӘР КАБУЛ ИТЕЛӘ

Аңа 2022 елның 31 октябренә кадәр кушылырга мөмкин. Анкетаны теләге булган һәркем рус яки татар телендә тутыра ала. Гаризада видеоролик та булырга тиеш. Аны рәсми почтага: tnvtatarsuze@mail.ru җибәрергә кирәк. Конкурс берничә яшь категориясенә: 10 яшькә кадәр, 10 яшьтән 17 яшькә кадәр һәм 18 яшьтән зуррак катнашучылар өчен бүленгән. Шулай ук иҗади гаиләләр, 15 яшьтән зуррак башкаручылар һәм профессионаллар чыгыш ясый алачак. Бәйге нәтиҗәләре буенча гала-концерт узачак, ул 2023 елның 1 июненнән дә соңга калмыйча үтәчәк. Чараны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе акционерлык җәмгыяте оештыра. Ул татар халкының бай тарихи-мәдәни байлыгын популярлаштыру максатында үткәрелә.

# ГҮЗӘЛ БЕЛӘН ИЛДАР 20 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЙ КОНЦЕРТЛАРЫНДА ТАМАШАЧЫНЫ ШАККАТЫРЫРГА ҖЫЕНА

27 ноябрьдә Мәскәүнең Кремль концертлар залында Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимовның «20 ел сәхнәдә» дигән яңа концертлары узачак.

*matbugat.ru*



Җырчылар моңа кадәр татар эстрадасында күрелмәгән тамаша тәкъдим итәчәк. “Безнең өчен бу сезон - зур бәйрәм. Яңа форматта бераз оркестр, бераз Шоу-балет, искиткеч визуализация, ут, яңгыр, 3 этажлы сәхнә, яңа талантлар, көтелмәгән кунаклар булачак. Без 20 ел эчендә булган иң яхшы әйберләрне әзерләдек”, - дип ураклашкан Гүзәл Уразова үзенең социаль челтәрдәге битендә. Мәскәүнең Кремль концертлар залында узачак тамашага әле бер айдан артык вакыт булса да, билетлар санаулы гына калган диярлек. Билетларны өстәмә комиссиясез түбәндәге сылтама аша алырга мөмкин. Шулай ук +7(985)200-30-20, +7(915)387-82-45 телефон номерларына шалтыратып та сатып алырга мөмкин.

## ФИЛЬМ О ДЖАЛИЛЕ ВЫШЕЛ НА ТЕЛЕКАНАЛЕ «ЗВЕЗДА»

Фильм «Муса Джалиль» вышел на телеканале «Звезда» в рамках программы «Легенды армии».

*tatmsk.tatarstan.ru*



Поэт и Герой Советского Союза вошел в историю как человек, продолживший борьбу с фашизмом, несмотря на клеймо предателя. А его дар слова оказался так велик, что помог вовлечь в эту борьбу сотни людей с искалеченной пленом судьбой.

Они рисковали жизнью, чтобы вернуться на Родину с оружием в руках. А еще – не страшась пыток и смерти, сохранили записи, которые Джалиль сделал накануне казни. В работе над фильмом приняли участие дочь поэта – Чулпан Мусеевна Залилова, историк Рустэм Гайнетдинов, заведующая Музеем-квартирой Мусы Джалиля Назира Фаттахова и другие.

## ТАТАРСТАНСКИЙ ПИСАТЕЛЬ СТАЛ ЛАУРЕАТОМ ПОЧЕТНОГО СПИСКА МЕЖДУНАРОДНОГО СОВЕТА ПО ДЕТСКОЙ КНИГЕ




В малазийской Путрадже прошло открытие 38-го Всемирного конгресса Международного совета по детской книге (IBBY)

*milliard.tatar*

В ходе мероприятия детский писатель и главный редактор «Татарского книжного издательства» Ленар Шаехов был объявлен лауреатом Почетного списка IBBY. Он удостоился приза за произведение на татарском языке «Есть котенок у Гали» («Галиның песие»). Напомним, в 1994 году лауреатом Почетного списка Международного совета по детской книге из Татарстана стал выдающийся татарский поэт и государственный деятель Роберт Миннуллин.



## РДУМСО ПОМОЖЕТ АДАПТИРОВАТЬСЯ ИНОСТРАННЫМ СТУДЕНТАМ

В Самарской Соборной мечети прошла состоялась встреча председателя Регионального духовного управления мусульман Самарской области, муфтия Талипа хазрата Яруллина со специалистом отдела международного сотрудничества и образования управления международных отношений Самарского государственного медицинского университета Ксенией Даниловой и начальником отдела по развитию социальной среды и воспитательной работе с обучающимися управления молодежной политики СамГМУ Александром Лентовским. Речь шла об адаптации иностранных студентов из мусульманских стран.

*www.samddn.ru*

По словам Ксении Даниловой, в Самарском медицинском университете год от года увеличивается число студентов, приезжающих на обучение из стран, где основной религией является ислам. И если студентам из азиатских стран СНГ, таких как Узбекистан или Таджикистан, достаточно легко социализироваться в нашем регионе, то, к примеру, египтяне менее адаптированы к российской культуре и в российских реалиях чувствуют себя не очень комфортно. Специалисты из СамГМУ надеются, что взаимодействие иностранных студентов с местным мусульманским духовенством, общение с религиозными наставниками будет способствовать их скорейшей адаптации и социализации.

# «ФЕСТИВАЛЬ НАЦИОНАЛЬНЫХ СВАДЕБ» В САМАРЕ ОБЪЕДИНИЛ СЕМЕЙНЫЕ И НАРОДНЫЕ ТРАДИЦИИ

*tatar-duslyk.ru*




**Уже 13 лет в сентябре Управление ЗАГС Самарской области при поддержке Дома дружбы народов Самарской области организует яркое культурное событие – «Фестиваль национальных свадеб», который отражает суть праздника – День дружбы народов.**

Как любовь объединяет сердца, так наша многонациональная губерния объединяет свыше 150 различных культур и традиций. На Самарской земле звучат слова любви на многих языках. И поэтому неслучайно стало доброй традицией показывать многообразие культурных традиций и единство взглядов – трепетное и почетное отношение к семейным ценностям, сохранение мира и согласия – главные традиции нашей великой страны!

Самарская область – это сердце России, наполненное любовью, душой, трепетом и глубоким уважением к истинным корням, традиционным семейным ценностям, обычаям, бережно передаваемым от старшего поколения к младшему с колыбельными матери, с примерами долга и чести отца. Только семья наполняет любовью сердца, открывает душу и порождает веру. Семья является центром формирования нашего духовного единства. Поэтому на фестиваль были приглашены пары, которые прожили в любви и согласии более 50 лет и являются примером для молодого поколения.

В этот день молодые семьи Евстигнеевых, Яловенко, Зимлихановых, Михайловых и Байдулиных зарегистрировали свои отношения под обряд величания молодоженов, который провел заслуженный коллектив народного творчества РФ «Россияне».



Все присутствующие на церемонии выразили уверенность, что сегодняшние молодожены обязательно достигнут таких же высот, как и юбиляры, достойно воспитают своих детей, и будут бережно хранить традиции. Ведь свой семейный путь эти пары начинают с уважения к корням, с духовных ценностей, с национальных свадебных традиций.

На «Фестивале национальных свадеб» прошло чествование семей – юбиляров супружеской жизни, которые состоят в зарегистрированном браке 50, 55, 60 и более лет. Супругам – хранителям национальных традиций и семейных ценностей – были вручены именные поздравительные адреса губернатора Самарской области Д.И. Азарова и памятные подарки.

На мероприятии присутствовали: директор Дома дружбы народов Самарской области Игорь Буров, председатель Правления Общественной организации «Курултай (конгресс) башкир» г. Самары Камила Сизякова, член совета НКЦ «Проминь» Людмила Колескина, президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» (Родной язык) Ильяс Шакуров, президент Самарской региональной общественной организации «Национально-культурная автономия казахов «Ак Жол» (Светлый путь) Токтарбай Дусенбаев. Они душевно поздравили семейные пары юбиляров.

На фестивале с творческими номерами выступили украинский хор «Проминь», Народный ансамбль песни, танца и поэзии «Ялкынлы яшьлек», активисты Самарской региональной общественной организации национально – культурной Автономии казахов «Ак Жол» (Светлый путь), лауреат международных и всероссийских конкурсов Надежда Сорокина.



# ИСЛАМСКАЯ ЖЕМЧУЖИНА НА САМАРСКОЙ ЗЕМЛЕ

***1 октября состоялось самое долгожданное и радостное событие для всех самарских мусульман – после многолетней реконструкции открылась Самарская Историческая мечеть на улице Алексея Толстого.***

***Данияр Сайфиев***



В этот день погода словно решила разделить радость праздника и внесла свою позитивную лепту в общее настроение прихожан – после многодневных надоедливых дождей 1 октября целый день светило солнце, наполняя теплом и радостью сердца участников и гостей этого мероприятия.

Как и положено, на площадку перед мечетью куда с самого утра начали приходить люди, играла музыка, исполнялись со сцены мусульманские песнопения – нашиды, вокруг раскинулись многочисленные шатры, где можно было попробовать и приобрести необычайно вкусную халяльную продукцию, познакомиться с мастерами исламской атрибутики и приобрести понравившиеся вещи, а для детворы были организованы различные мастер-классы. Возле самой мечети разместили многочисленные информационные щиты, рассказывающие об истории мечети и жизни мусульманской уммы XIX века.

А история этой мечети богатая. За 130 лет своего существования она действительно повидала многое. Поистине сегодня она является историческим достоянием нашего многонационального и многоконфессионального города, живой историей в камне. В подготовленном известным самарским краеведом Шамилем Галимовым специальном буклете об этой мечети говорится, что в 1888 году известный меценат и благотворитель, симбирский фабрикант – владелец нескольких суконных фабрик Тимербулат Акчурин по просьбе общества самарских мусульман выкупил у крестьянина И.Н. Павлова земельный участок в 42-м квартале – на Казанской улице (между Заводской и Панской), чтобы через





три года построить на нем мечеть. Это событие стало знаковым и поворотным в истории татарской общины города и всего края и одним из важнейших эпизодов многовековой истории татарского народа. Практически сразу при мечети было открыто медресе, школа для детей, создано благотворительное общество «Хайрия», работала библиотека, имамом мечети Мухамметфатыхом Муртазиным с 1908 года начал издаваться первый в Российской империи экономический журнал на татарском языке «Икътисад» («Экономика»). В начале 1930-х мечеть была закрыта, а здание переоборудовано в детский дом, а потом много лет в нем находился детский сад. Сам хазрат был обвинен в сборе средств для осужденных религиозных деятелей и сослан в Сибирь. В 1937 году по возвращении из ссылки его вместе с сорока единоверцами осудили за «создание контрреволюционной исламской организации» и расстреляли. Здание прослужило в качестве детского сада до 90-х годов прошлого века, пока не было признано аварийным.

В 2003 году Региональное духовное управление мусульман Самарской области подписало договор о долгосрочном сотрудничестве с администрацией города Самары, после чего здание было возвращено мусульманам. Начался процесс ее восстановления. В 2007 году председателем Совета Самарской исторической мечети был выбран Усман Владимирович Илингин, который вместе с коллективом, спонсорами-мусульманами при поддержке областных и городских властей постепенно восстанавливал ее. Работа проведена огромная: укреплен фундамент мечети, заменены все инженерные сети, установлены вентиляция, пожарная система, проведена отделка фасада и внутренняя отделка помещений. К исторической части объекта пристроено двухэтажное здание с куполом и 38-метровый минарет с видом на Волгу и центр областной столицы, благоустроили территорию. За активное участие в воссоздании регионального памятника Усман Илингин отмечен благодарностью Губернатора Самарской области.

Сегодня здание Исторической мечети получило второе рождение и стало одной из достопримечательностей Самары, ее архитектурной жемчужиной. Приехавший на открытие губернатор Дмитрий Игоревич Азаров отметил, что здание украшает столицу нашего региона – Самару. Оно служит духовным символом, укрепляющим веру, объединяющим людей вокруг традиций ислама – религии, которая была представлена испокон веков на нашей земле.

*«Сегодня в единстве мировых религий, представленных на Российской земле, жители Самарской области, граждане России черпают духовные силы и черпают общенациональное единство. Я уверен, что вместе мы приложим все усилия для того, чтобы уникальные традиции Самарской земли, традиции дружбы, традиции братства людей разных национальностей, разных конфессий сохранялись и передавались из поколения в поколение. Я благодарю всех, кто прилагает к этому усилия. Я благодарю всех вас за вашу веру, ваше мужество, вашу сплоченность в эти непростые времена. Сегодня важный день. С молитвой и крепостью духа наши защитники встанут в строю, защищая интересы нашей великой Родины, всех ее жителей»,* – отметил в своем выступлении глава региона.

Он подчеркнул важность единства, сплоченности, веры и поблагодарил всех причастных к восстановлению регионального памятника архитектуры.

На торжества, связанные с открытием мечети, из Уфы приехал и председатель Центрального духовного управления мусульман России, верховный муфтий Талгат Сафа Таджуддин. Он в сопровождении имамов и муфтиев из соседних регионов ознакомился с работой выставки, пробовал выставленную продукцию, а затем со сцены поздравил с этим важным для всех мусульман Самарской области и Поволжья событием.

*«Самарская область нам очень дорога. Это жемчужина среди регионов нашей страны, когда-то входившая в Булгарию. Из Киевской Руси и Булгар начиналась Россия, и*





*сейчас она – огромнейшая единая страна. Мы только вчера слушали нашего Президента. Когда он говорит, у всех сердце замирает. Не только в России, во всем мире. Вчера мы услышали слова, которые записаны в наших сердцах. В них – забота о стране, о ее будущем, о ее силе, могуществе и процветании,* – отметил верховный муфтий Талгат Сафа Таджуддин. – *Сегодня, открывая этот храм, мы вспоминаем слова нашего Президента Владимира Владимировича Путина. Он сказал:*






*«Западная демократия нам не нужна». У нас и совесть, и жизнь, и семья строятся на основе веры – православия, ислама, иудаизма и буддизма. Восстановление этой мечети, в которое было вложено столько сил, любви и радости, – это восстановление самих себя. Пусть в каждом селе, в каждом городке красуются храмы Божьи, пусть люди приходят туда. Пусть Самара – цветущий край нашей великой Отчизны – России – и дальше процветает».*

В возрождении объекта культурного наследия регионального значения приняли участие представители самарской мусульманской общины, бизнесмены и все неравнодушные люди.

Благодарность за поддержку и помощь в восстановлении храма губернатору и Правительству региона, меценатам выразил председатель регионального духовного управления мусульман Самарской области, муфтий Талип хазрат Яруллин.

*«Спасибо Правительству, Дмитрию Игоревичу Азарову за участие в том, чтобы этот храм был восстановлен и сохранился в первозданном виде. И большое спасибо каждому из вас, кто внес посильный вклад в то, чтобы был этот храм. Помогали люди разных вероисповеданий, разных национальностей, чтобы он сиял своей красой,* – сказал муфтий. – *Мы рады тому, что сегодня восстанавливаются мечети, церкви, синагоги. Это значит, что у людей есть совесть, есть вера».*

Приглашение на открытие мечети также было направлено заместителю председателя Правительства Российской Федерации Марату Хуснуллину, который прислал в Региональное духовное управление мусульман Самарской области приветственный адрес.

*«Вот уже на протяжении 11 веков ислам был и остается одной из главных религий в нашей многонациональной стране, которую исповедуют миллионы верующих. Ислам вносит огромный вклад в развитие культуры и духовности современного общества. Он проповедует подлинные общечеловеческие ценности, идеи просвещения, истины, добра и гуманизма. По случаю знаменательного юбилея и открытия после реставрации одной из старейших мечетей По-*



*волжья желаю всем мусульманам Самарской области крепкого здоровья, счастья, мира и успеха во всех делах и начинаниях»,* – говорится в адресе.

Работы по развитию мечети и прилегающей к ней территории будут продолжены: здесь планируется создание мусульманского духовно-культурного комплекса, где будут в том числе детский сад и спортивный комплекс. Надеемся, что их открытие станет столь же ярким и запоминающимся событием, как и открытие самой мечети.

# ТАРИХЫБЫЗ – ЯШЬЛӘР КУЛЫНДА




**Самарның Алексей Толстой урамындагы Тарихи мәчетнең капиталь ремонттан соң ачылуы 130 еллык юбилее һәм Болгар дәүләте рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырыла торган күп санлы чараларның берсе 28 сентябрьдә Ленин проспектындагы өлкә универсаль фәнни китапханәдә үтте. “XIX – XX гасырларда, татарларның аякка басу чорында, Казанский урамындагы мәчетнең урыны һәм роле” дип аталган фәнни конференциядә дин белгечләре, милли оешмалар әгъзалары, төбәкне өйрәнүчеләр, милли тормыш белән кызыксынучы олы буын вәкилләре, студентлар һәм “Яктылык” мәктәбе укучылары һәм укытучылары катнашты.**

***Эльмира ШӘВӘЛИЕВА.***

Фойеда ук ниндидер туганлык атмосферасы хөкем сөрә иде. Килеп кергән һәрбер кешене, ерактан ук сәламләп, кочаклап яисә кул биреп исәнләшеп каршы ала тордылар. Моны читтән карап торган кеше өлкә татар оешмалары эшчәнлеге юкка булмаган, алар татарларны мәдәният һәм сәнгать, дин һәм мәгариф, тарих һәм төбәкне өйрәнү, китаплар һәм газета-журналлар бастыру эшләре тирәсендә туплый алган, дигән фикергә килә. Шунда ук өстәлләргә “Самар татарлары” журналлары, “Бердәмлек” газетасы җәеп салынган. Теләгән кеше аларны ала, кайберләре шунда ук киләсе яртыеллыкка ташлама буенча язылa. Арырак 1905 елгы Хәлиф Усман Коръәне күчермәсен күрергә мөмкин. Соңрак аның барлыкка килү тарихы турында китапханә мөдире урынбасары Наталья Малкова тәфсилләп сөйләде. Бу бигрәк тә “Яктылык” мәктәбеннән килгән укучыларга, студентларга кызыклы булгандыр, дип уйлыйм.

Конференциянең төп оештыручысы, өлкә татарлары тарихчысы, шул темага караган күп санлы басма китаплар авторы Шамил Хәйдәр улы Галимов чараны “Туган тел” татар җәмгыяте төшергән документаль фильм белән башлап җибәрде. Анда гомере буе диярлек китапханәче булып эшләгән, шунда туган як тарихы белән кызыксынып китеп, краевед буларак танылган мәрхүм Марат ага Сафинның тормыш юлы яктыртыла. Шулай ук тасмага революциягә кадәр төзелгән Самар мәчетләре, имамнары эшчәнлеге һәм күпчелегенең аянычлы язмышы турында да сюжетлар кертелгән иде.

Региональ Диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллин, конференциягә килүчеләрне сәламләп, өлкәбез җирләренең бер өлеше кайчандыр Идел буе Болгар дәүләтенә кергән булуын исебезгә төшереп үтте, ата-бабаларыбыз кабул иткән ислам диненең бүгенгә кадәр үзгәрешсез яшәп килүен искәртте. “Бүген без күп милләтле Россиядә бер-беребезнең динен һәм мәдәниятен хөрмәт итеп яшибез, киләчәктә дә шулай булсын өчен көч куябыз. Украина тәҗрибәсен күреп торабыз, нәрсәдән башланды бит: андагы милләтчеләр, үз-үзләрен әллә кемгә куеп, башка милләт халыкларының телен, динен кысрыклый башладылар һәм тора-бара бу канкойгыч сугышка китерде. Шулай булмасын өчен, өлкәбездә эзлекле рәвештә максатлы эш алып барырга кирәк.

Бүген илебез катлаулы чор кичерә: уртак илебезне дошманнан саклап калу өчен кулга корал алырга, берләшергә тиешбез. Туган илен, туган җирен, гаиләсен яклау – мөселман кешесенең иманы ул. Догаларыбызда сугыш тәмамлансын, яшь гомерләр өзелмәсен, илдә бердәмлек һәм тынычлык урнашсын, дип телибез”, - дип сөйләде.

Тарихи мәчет китапханәчесе Рөстәм хәзрәт Фәйзуллин әлеге мәчетнең төзелү тарихы, эшчәнлеге, фондларда саклана торган сирәк басмалар һәм борынгы әйберләр турында сөйләп кенә калмады, презентациясен дә күрсәтте, туксанынчы елларда Тарихи мәчетне кайтаруда эшкуар һәм депутат Зөлфәт Сәлаховның роле зур булуын билгеләп үтте.

“Яктылык” мәктәбендә тарих һәм обществоведение дәресләре укытучысы Айназ Фәхертдиновның чыгышы - Алтын Урда һәм Идел буе Болгарының археологик истәлекләренә, Алабин музее хезмәткәре Анна Кочкинаның доклады - киләсе елга ачылышының 100 еллыгын билгеләп үтәчәк Муром шәһәрчеге казылмаларына, тарих фәннәре докторы Наилә Таһированың чыгышы - XIX - XX гасырларда татар сәүдәгәрләре җитештерүчәнлегенә, Гомәр Батршинның чыгышы - Самар өлкәсендә болгар бабаларыбызның истәлеген саклауга, Җәмигъ мәчете имамы Иршат Сафинның доклады - шул чордагы Самар муллаларына, Камышлы районының “Туган як” җәмгыяте әгъзасы Римма Галимуллинаның чыгышы борынгы топонимнарга һәм, зиратта күмелгән авылдашларын барлап, электрон карта булдыру эшләренә юнәлтелгән иде. Ун минутка гына исәпләнгән булсалар да, чыгышларның барысы да бик әһәмиятле булып, татар тарихы белән кызыксынган кешегә үзе өчен күп ачышлар ясарга мөмкинлек бирде.

Өч сәгатьлек конференция бераз талчыктырса да, соңгы докладчының чыгышын җыелган халык аеруча зур игътибар белән тыңлады. Самар сәнгать институтының өченче курсында гына укучы Лилия Әхмәдуллина “Татарские шамаили. Сакральный смысл” дип аталган фәнни эшен тәкъдим итте. Төпле эзләнүләре шамаилләр тарихына багышланган - нинди билгеләр һәм текстлар язылa, нинди материалда һәм нинди ысул белән эшләнүе турында сүз бара. Яшь галимә гомер буе трибуна артында басып торган диярсең: татарча сөйләме дә, русчасы да камил, доклады да энәсеннән җебенә кадәр җентекләп эшләнгән. Менә шундый Айназ Фәхертдинов, Лилия Әхмәдуллиналар кебек тирән фикер йөртүче яшьләребез булуы милләтебезнең, динебезнең, тарихыбызның дәвамлы булачагына ишарә итә.

# В САМАРЕ ОТПРАЗДНОВАЛИ ДЕНЬ ДРУЖБЫ НАРОДОВ



***11 сентября 2022 года в Этнопарке дружбы народов состоялся праздничный Этнофестиваль «Наследие народов», приуроченный ко Дню дружбы народов и Году культурного наследия народов России.***

***www.samddn.ru***

День дружбы народов отмечается в Самарской области 12 сентября. Он был учрежден Законом Самарской области от 10 ноября 2014 года «О памятных датах Самарской области» по инициативе региональной общественной организации «Союз народов Самарской области», которая объединяет национально-культурные организации.

Организаторами праздника выступили ГКУ СО «Дом дружбы народов» и национальные общественные организации Самарской области при поддержке Правительства Самарской области.

Свыше 6,5 тысяч человек стали участниками Этнофестиваля «Наследие народов» и познакомились с многообразием народов, населяющих Самарскую область, узнали о традициях и обычаях, культуре и народном творчестве.

Пространство Этнофестиваля было наполнено национальной музыкой, весельем и творчеством. Гостей праздника встречали русскими народными песнями, ансамблем карнаистов, корейскими барабанами и выступлениями творческих коллективов.

На главной сцене состоялась многонациональная концертная программа с участием лучших коллективов национальных общественных организаций и муниципальных образований Самарской области.

Праздник посетили почетные гости. Вице-губернатор – руководитель департамента внутренней политики Самарской области Дмитрий Валерьевич Кочергин зачитал приветственный адрес Губернатора Самарской области, а также вручили региональные награды. Почетным знаком Губернатора Самарской области «За вклад в укрепление дружбы народов»



был награжден Вадим Николаевич Якунин. Благодарностью Губернатора Самарской области наградили Татьяну Павловну Сабинину и Людмилу Николаевну Павлову.

Также с Днем дружбы народов гостей праздника поздравили первый заместитель председателя Самарской Губернской Думы Марина Юрьевна Антимонова и председатель региональной общественной организации «Союз народов Самарской области» Ростислав Ерастович Хугаев.

На центральной площади развернулась творческая площадка. Ведущие мастера и творческие объединения региона представили гостям колорит традиционных промыслов и ремесел народов Самарской области. На локации «Артель» посетители стали участниками мастер-классов по художественной обработке дерева и кожи, ковке, гончарному делу, лозоплетению, национальной росписи и многим другим. На площадке «Ярмарочные ряды» знакомились с выставками изделий декоративно-прикладного творчества.

Выставку «Народы Самарской области» представили национальные общественные организации и Дом дружбы народов Самарской области. Посетители познакомились с национальными костюмами, предметами быта, литературой на разных языках, а также коллекциями кукол в национальных костюмах, традиционных музыкальных инструментов, национальных головных уборов.

Активное внимание гостей привлек арт-проект «Дружба народов», на площадке которого молодые художники писали портреты представителей разных народов.

С большим интересом гости праздника принимали участие в интеллектуальной игре «Этноквиз» и отвечали на вопросы, связанные с этнокультурной спецификой самарского региона. Каждый участник получал тематическую сувенирную продукцию.

Для юных гостей праздника была организована локация «Дружное детство» с подвижными играми, анимационной программой и интерактивными мастер-классами.

День дружбы народов – яркий символ многонациональной Самарской губернии. Праздник взаимопонимания, добрососедства и согласия между народами, которые веками проживают бок о бок в нашем регионе и вместе трудятся ради блага и процветания Самарской области и всей России.













# КЕМ УЛ - ТАТАР?

## Ягъни Бөек Татар иле контурлары

***Бу көннәрдә татар дөньясы күгендә тагын бер зур вакыйга булды: әлегә урыс телендә “Контуры Великой Татарии” китапларының беренчесе басылып чыкты! Бу китап укучыны дөньяның 5 кыйтгасында да татарлар гөрләп яшәгән заманнар булганын, тормышның төрле өлкәләренә караган, әлегәчә сакланган, “татар” сүзенә бәйле бихисап истәлекләр белән таныштырып, татарның Бөтендөнья кешесе икәнлеген исбатлый. Дөресрәге – исбатлый башлый, хезмәт бит 4 китаптан торасы.***

***Фирдәвес Галиева***



Өлкән автор – Нурмөхәммәт Хөсәенов, Бәләбәй шәһәрендә – Татарстаннан читтә беренче булып татар гимназиясе ачып, 20 ел буена шунда “Татар тарихы”н яңача укыткан һәм дә инде татар дөньясында шактый билгеле шәхес.

Икенче автор - Илдар, аның улы һәм укучысы, ул Татар энциклопедиясе институты аспирантурасында гомумтарих бүлеген тәмамлаган.

Аталган китап алдагы елларда татар мирасын ачыклау буенча авторлар тарафыннан язылган китапларның дәвамы булып тора.

Бу “комплекска” кергән китапларның беренчесе “Рус теленең төрки нигезләре сүзлеге” дип атала (I басмасы - 2006 елда, V басмасы 2012 елда басылды). Ул өлкән Хөсәенов тарафыннан язылган иде (Илдар исә ул чакта әле гимназия укучысы, әмма инде “компьютерда җыючылар”ның берсе булган).

Китап мавыктыргыч, монда авторның үзе булдырган уникаль методикасын кулланып эшләгән гаҗәеп тикшеренүләре буенча, һич уйламаган урыс сүзләренең гади генә ысуллар белән ясалып, татар нигезеннән чыгышлы икәне ачыла! (Әйтик, “волк” сүзе. Баксаң, татар телендәге улак, уларга хирыс сүзеннән ясалган атама икән! Татарда элек “в” хәрефе булмаган, аның урынына “уа”, ”уы”, ”уо”, w әйтелгән: уакыт, ауыл, уак-төяк... “Улак” сүзендә “у” “во”га алышына, “а” хәрефен “сызып ташлаганнар”).

Мәгълүм ки, урыс телендә берничә дистә мең сүз бар, аларның күпчелеге бер үк тамырдан ясалган сүзләр төркемнәреннән тора. Китапның Vнче басмасында автор, урыс сүзләрен тикшереп, биредә 4000ләп татар теле белән “уртак” тамыр-сүзләр барын ачыклаган, аларның татар сүз-тамырдан төрле юллар белән (гади укучы хакына лингвистик терминнарга кермибез инде) хәреф алыштыру яисә аны кыскартып кую, яисә тамырга хәреф өстәү һ.б. алымнар белән ясалганнарын дәлилли. Ягъни бу китап татардан алынган сүз-тамырдан ясалган урыс сүзләреннән торган сүзлек һәм анда һәрбер рус тамыр-сүзе ясалышына аңлатма бирелә бара. (Искиткеч зур түземлек һәм вакыт сарыф ителгән!)

Китапта тагын шундый кызыклы ачышлар бар: әйтик, татар телендәге сүзъясалыш аффиксларын урыс сүзләрендәге аффикслар белән чагыштырып, автор аларның башлыча шул ук татар нигездән үзләштерелгән аффикслар икәнен яисә, деформация аша үтеп тә, шулай да охшашлыгын саклап калганлыгын күрсәтә. Шундый 220ләп төрдәге “татар аффикслары” урыс телендәге сүзләр ясалышында кулланылган. (Мәсәлән, афф. “за, зә”: тат. күрәзә, тәрәзә, җилпәзә, урыс телендә “очраклы рәвештә”, “за, зя”: обуза, заноза, бронза, стрекоза, стезя һ.б. яисә тат. афф. “ач, әч”: калач, токмач, тылмач, әтәч. Урыста - “ач, ич”: первач, кулич, трепач, бородач һ.б. Шундыйрак охшашлы “очраклыклар” атлаган саен очрый!)

Янә дә ул китапның икенче бүлегендә мең ярым урыс фамилиясенең татар чыгышлы икәне күрсәтелеп үтелә! Боларның 600 - 700е фән тарафынан инде танылган.

- Бу китапны беренче нәүбәттә гамәлгә куймый мөмкин түгел иде, - ди Нурмөхәммәт әфәнде. - Алдагы хезмәтләребез белән танышкан кеше моңа инана...

Арытаба, 2016 елда аталы-уллы Хөсәеновләр “Что есть Московия” китабын чыгаралар, алар аны “Татар тарихының кыскача эскизы” дип атыйлар. Ошбу китапта алар рәсми тарихның, шул исәптән татар тарихының да, ялганлыгын күп төрле дәлилләр белән исбатлыйлар һәм “чын татар тарихы әле язылмаган”, дигән караштa торалар.

Әлеге китапта, йөзләрчә борынгы карталарга таянып, “Московите Татария”, шул исәптән “Московия Азиатская”, “Московия Европейская” дип билгеләнгән киңлекләрдә, төрле чыганаклардан алынган торак пунктлар (хәзер дә шәһәр, авыл исемнәре), тау, елга, күл исемнәре һәм башка төр атама-

ларга караган, татар теленнән чыгышлы, дистә ярым атамаларны эченә алган "топонимнар комплекслары" китерелгән иде: Джайлов-Жилово..., Мәскәү-Московка..., Коллома-Коломна, Ханово-Каново..., Кузнецово-Тимерязово..., Каран-Караново..., Казанлы-Казаново...

Биредә аларның географик буйлыкта, бөтен Евразия киңлегендә, шул исәптән СНГ илләрен һәм берникадәр чит илләрнең чиктәш өлешләрен дә эченә алып, әледәнәле "кластер принцибында" – кайбер исем-атамаларның уртача йөз һәм күбрәк тапкыр, икенчеләре – икешәр йөздән артык тапкыр кабатлануы күрсәтелә, һәм әлеге атамага бәйле мәгълүматлар ул киңлекләрдә көн күргән кешеләрнең яшәү рәвешенә, ритмына, төрле сезонда үтәгән вазифаларына карап аңлатыла.

Бөек Татар иле тарихына караган язма мәгълүматлар махсус рәвештә җентекләп юк ителгән булса да, Хөсәеновләр кулланган тарихи реконструкция алымнары аз-аз сакланып калган мәгълүматларга таянып, шактый нәрсәләрне аерымачык тасвирларга юл ача. Сүз уңаеннан, "юк ителгән" булуга һич тә шик юк икәнең дә - авторлар китергәннәрдән ике-өч штрих белән булса да күрсәтеп үтик әле. Урыс елъязмаларын караган кеше белә: аларның берсендә дә, бер җирендә дә "Московия" дип аталган ил күренми, анда бары тик "Русь" кенә атала, гәрчә, шул ук вакытта йөзләрчә карталарда бу киңлекләрдә Московия дигән биләмә күзгә бәрелеп ята, әмма анда "Русь"ка һич урын юк!

Әйе, 15 гасырдагы карталарда Балкан ярымутравында һәм Балтика буенда "Russia" дигән язу күренә башлый, әмма кайда аңарчы булган "Святая Русь" һәм, гомумән, Русь? Яки тагын бер мисал: Рәсәйнең Европа өлешендә, өчәр мең километрларга сузылган, биеклекләре 10ар метрга җиткән ике мәһабәт бөек "Татар валы" бар, әмма алар турында урыс тарихын тасвирлаучы елъязмаларда ярты сүзгә дә урын юк...

Никадәр биниһая дәү булсалар да, болар рәсми тарих битләреннән "төшеп калганнар"... һәм бит әле аларның реданнары урыс иленә каршы карап тора! Кем өстенә килгәнне күрсәтә бу валлар?! Шулай ук нигездә 8 почмаклы булган шундый ук технологиядә корылган галәмәт фантастик зурлыктагы крепость-калгалар булганлыгы ачылды, тик алар турында да Россиянең "чын тарихында" берни дә әйтелми...

Ә 700 ел вакыт буена басылып чыга барган карталарның битләреннән төшмәгән Бөек Татария дәүләтенең (ә андый карталар бүгенге көндә Хөсәеновләргә 340 - 350 данәдә барлыгы билгеле) тарих "фәнендә" бөтенләй искә алынмавы һәм дә аның урынына әлеге карталарда бер генә тапкыр да күрсәтелмәгән мифик "Монголия" белән тарихчыларның инде гасыр ярым саташулары уйлый белгән кешедә тәмам аптыраш тудыра, - диләр авторлар.

- Ни әйтәсең инде менә... – дип көлә Нурмөхәммәт әфәнде, әлеге китаплары турында миңа аңлатма бирә барып. Карталар бер нәрсә сөйли, "тарихи чыганаклар" – үзләренчә, ә рәсми тарих "фәне" бу аермалыкны күрмәмеш – үзенекен тукылдый бирә.

Һәм аңлашыла ич инде - биниһая зур географик биләмәләрне үз эченә алган Бөек Татария дәүләтен сакларга да кирәк булган бит. Әмма әлегә кадәр беркем дә әле аңлатмады: 300 - 400әр меңәр гаскәриләрдән торган Бөек Татария армияләре кайда яшәгәннәр, ничек, кайларда яши торып, бүгенге көндә күз алдына китергесез хәрби осталыкларга өйрәнгәннәр, атларын кайда тотканнар? (Бөек Хубилайханга каршы, мәсәлән, Наян исемле чукынган абзыйсы, Христос сурәтләнгән флаг астында 400 мең атлы гаскәр белән яуга килә, аңа каршы Бөек хан 360 гаскәр куя), ничек алар үзләрен һәм атларын (һәрбер гаскәригә 5 ат тиеш булган!) кышын-җәен азык белән һәм, гомумән, көнкүреш һәм хәрби кирәк-ярак белән тәэмин итә алганнар?

Хөсәеновләр исә, бихисап күп чыганакларны җентекләп өйрәнеп, алардагы очраклы рәвештә сакланып калган, еш кына "икенче пландагы" мәгълүматларны җыйнапанализлап, аларны искитмәле табигый, спай һәм төзек системага салып классификацияләгәннәр һәм бу сорауларга тулы җавап бирәләр.

Аларның географик, табигать һәм социаль-көнкүреш объектлары атамалары төркемнәрен җентекләп анализлауларына игътибар белән карасак, дәүләтчелектә иң мөһим эшләрдән булган: илне саклардай армия тоту, сугышчыларның тиешле әзерлеген тәэмин итү – болар барысы да табигать законнарына һәм ел фасылларына идеаль рәвештә җайлаштырып оештырылган хәрби система булганлыгы аерымачык күз алдына килеп баса.

Менә, мәсәлән, сәяхәтче Г. Рубрук (һәм башка сәяхәтчеләр дә) язган: "Татарлар Скифияне – Дунайдан башлап кояш чыгышына кадәр арада – төп-төгәл чикләр белән бүлгәләгәннәр; алар җәен иң төньяк (географик) киңлекләргә кадәр менәләр, кышын исә көньяк киңлекләргә төшеп, кыш үткәрәләр; һәм һәрбер капитан үзенең кул астындагы кешеләренең - язын, җәен, көзен, кышын - нинди урында буласын төп-төгәллектә белә".

Сорау бит шунда ук туа: кем шулкадәр галәмәт киңлектәге җирләрне "капитаннарга" төгәл итеп бүлгәләп биргән һәм моның мәгънәсе нидә? Күренә ки – сүз ошбу киңлекләрдә өстенлек итүче, ошбу "капитаннарның капитаны" бүлеп биргән, төньяктан көньякка таба сузылган җир полосалары буйлап хәрәкәт итү турында бара. "Капитаннар" булгач, алар җитәкчелегендәге хәрби частьлар турында сүз түгелмени? Шулай итеп, бик гади һәм зирәк чишкәннәр татарлар атлы армияләрен тоту мәсьәләсен: ка-

зармалар, ат абзарлары, складлар; печән чабып-җыеп, эскертләр салырга да кирәкми... Сугышлар булмаган вакытларда, гаскәри частьлар, төгәл бүленгән маршрут-полигоннардагы җәйләүлагерьларда чатырларда яшәп, хәрби осталыкларын чарлаганнар, атларын һәм ит ризыгы чыганагы булган сарыкларны (“ордынская овца” дип аталган табигый порода бар) тукландыру өчен, әледән-әле яңа җәйләүләргә күчеп йөргәннәр. Аңлашыла ич - хезмәткә алынган ир-егетне шундый галәмәт зур гаскәрләр составында, командование сигналларына төгәл буйсынырга, бердәм маневрлар ясарга, төрле кораллар белән кул сугышы алып бару осталыгына даими өйрәнүләр булган. Югыйсә, Бөек хан карамагындагы дәһшәтле Ордалар күктән төшеп яу чапмаган ич инде...

Боларның “капитаннар” җитәкчелегендәге хәрбиләр булганын авторлар бик күп дәлилләр белән раслый. Шулардан иң фәһемле икесен генә китерәм: Татария Урдалары таркалганнан соң хасил булган казакларның (качакларның) мәҗбүри рәвештә хәрби тормыштан утрак тормышка күчкән мәлләрдәге яшәү рәвеше тасвирламалары шактый тарихи чыганакларда теркәлгән: казаклар тарих мәйданында күренә башлаган “беренчел чорларда” (ә бу 14нче гасыр - Урдаларның нәкъ таркалыш чоры) аларның станнарында хатын-кызлар бөтенләй булмаганы турында шактый язмалар билгеле, шуңа күрә казаклар ул вакытларда баскынлык иткән мизгелләрдә (һәм бу аларның төп шөгыле булган) хатын-кызларны күпләп урлаган булганнар, сәяхәтчеләр биредә туктаусыз өйләнү процессияләрен тасвирлап язалар. Һәм дә ярылып яткан икенче шундый ук мисал: мәгълүм ки - “манчжур” татар Урдалары Кытайга фәкать ирләрдән торган составта бәреп керәләр: алар арасында, аларның обозларында да хатын-кызлар һәм балалар бөтенләй булмаган. Ягъни Татариянең ”классик чорында” “күчмә татарлар”, ә дөресе – хәрби татарлар, арбаларына гаиләләрен утыртып, “кочевать итеп” йөрмәгәннәр, ә ул “классик” чордагы “кочевать итеп йөрү” хәрби хезмәткә алынучыларның маршрут-полигон лагерьларында хезмәт итү рәвеше булган. Һәм ул чактагы кешеләргә бу киңлекләрдә яшәү өчен “земли рискового земледелия” саналган Төньяк Евразия кулай булмаган – ул, армияләрне тотар өчен, иң кулай җирлек булган.

Менә тарихчы А. Лызлов ни язып калдырган: “Татария... разделяется на четыре части. ЕДИНА имеет В СЕБЕ ОРДЫ ВСЕ. Вторая загатаи и все народы, иже суть при Уссоне... Третия обдержит Китай...



и Хинское государство. Четвертая содержит страны мало нам ведомыя...”

Ә орда, инде төгәл мәгълүм, армия дигән сүз. Менә Татариянең нәкъ шушы төньяк өлеше – Московия (Ак Урда аталганы, башлыча, чукынганчыга хәтле...) “имел в себе все Орды”, ягъни биредә барлык Урдалар (армияләр) маршрут-полигоннардагы хәрби лагерьларда хәрби хезмәт кылганнар. Шунысы да төп-төгәл күрсәтә моны: Урда-Орда дип аталган топонимнар җир йөзенең бары тик шушы өлешендә генә очрыйлар. Мәскәүдә, Новосибирскийда бүгенгәчә “Ордынка” һәм “Ордынское шоссе” юллары сакланып калган. Һәм бу ике арада, әлеге юлның өлешләре, төрле әдәбиятта төрлечә: Татарская дорога, Московская дорога, Большая Старая дорога фрагментлары рәвешләрендә сакланып калган икән, ләбаса.

- Әйе, ул чордагы Татария гаскәрләренең эчке төзелеше турында исән калган мәгълүмат юк дигәнгә тәңгәл, - ди Нурмөхәммәт әфәнде.

Һәм бу аңлашыла да, шактый тарихи чыганаклар сөйли бу хакта: чит кеше ялгыш кына да татарларның хәрбиләр станына килеп чыкса – аны, бернигә карамыйча, юк иткәннәр. Арага шымчылар керүне булдырмауны хәрби төзелештә “унлык” (иң кече подразделение) системасы 100%ы белән тәэмин иткәне дә тарихи чыганакларда ассызыклап теркәлгән, чөнки “унлык” командиры чит кешене күрми кала алмый бит инде... Димәк, бу турыда мәгълүматларны, турыдантуры күрсәткән чыганакларны эзләү - файдасыз...

Археологлар кебек үк – ишелеп бетеп, балчык өеменә әйләнгән бинаның рәвешен анда-монда сакланган фрагментлар буенча күз алдына бастырган шикелле, бу очракта да шулай ук күзгә күренер-күренмәс сакланган матди һәм язма “ишарәләргә” карап, берникадәр тарихи реконструкцияләү ысулы гына ярдәм итә алган очрак инде бу.

Хөсәеновләрнең әлеге “Что есть Московия...” китабы хәрби көнкүреш турында “аннан-моннан” бик күп “вак-төяк” нәрсәләрен җентекләп җыйнап исәпкә алып, өстәрәк әйтелгән үтә четерекле сорауларга тулаем һәм бик гади рәвештә җавап бирә, әйтик, Рубрук үз сәяхәте турында сөйләгәннәрне җентекләп карап, алар тасвирлаганнарны табигый яшәү практикасына күчереп күрсәтәләр алар.

Мәсәлән, мәгълүм булганча, әле 19 гасырда да хәрби подразделениеләрнең походка чыгу маршы алдында агиллар (сүзлекләр таныйлар - татар чорыннан калган гамәл һәм сүз!) була калып, алар гаскәрнең яңа дислокация урынына лагерь булып килеп утырасы урыннарын

әзерләгәннәр. Һәм инде Урдаларда әлеге маршрут-полигоннарда хәрби подразделениеләренең алдында баручы агиллар елныңелында – язын-җәен-көзен - озакка тукталып тору лагерьларының кормаларын (чираттагы тукталыш урында чатырлар; ашату урыннарын, ремонт базасы корамаларын һ.б.) әзерләп куялар. Ышанмаска булыр иде дә бит – әмма нәкъ ошбу системаның "римлылар гаскәрләрендә" дә кулланылган булуы фәндә тасвирлау тапкан икән инде. (Нурмөхәммәт әфәнде, елмаеп: «Римлыларныкы микән соң әле ул», - дип куйды.)

Әлеге лагерьлар "җәйләүләр" дип аталу сәбәпле, шул замандагы лагерьлар инфраструктурасының терәк пунктлары булган агилларның каралты-куралары, Урдалар таркалгач, утрак тормыш башлап җибәрүчеләргә дә табигый рәвештә терәк пункт буларак хезмәт иткәннәр (сүзлекләрдә бу теркәлгән: агил > авыл), һәм әлеге "җәйләү" агиллары корылмаларының атамалары бүгенгәчә Җәйләү-Жайлау-Джайлау > Зайлау, Зилоу>Жилово-Шилово, Старо-, Ново-жилово һ.б. шундый торак пунктлар исемнәрендә, географик атамаларда шактый күләмдә чагылыш тапкан. Һәм мондый рәвешле топонимнар шактый күп санда сакланып калганнар (мондыйларның 130 тирәсе барлыгы мәгълүм).

Ә инде хәрби подразделениеләрнең кышкы вакытта сыена торган хәрби лагерьлары - кышлыклар – бүгенге көнгәчә Россиянең (берникадәр төзәтмәләр белән – СНГ илләрендә) көньяк географик киңлекләре буенча тезелгәннәр, аларның элгәреге статуслары хәзергәчә Кышлак, Кишлак, Кыштак, Каштак һ.б. шундыйрак атамалы авыллар (ул киңлекләрдә авыл дигән сүз, гомумән, "кышлак" сүзе белән билгеләнә!) тезмәсендә аерымачык чагыла, дип күрсәтәләр авторлар. Ә хәрби осталык "чарлау" өчен ясалган махсус җайланмалар белән җиһазланган мәйданнар – "тукмаклыклар" - Тукмак, Токмак, Тукмаки, Токмаклы, Такмак һ.б. шундый географик атамаларда эзләрен саклап калган (авторлар тарихчыларның "Алтын Урда" дип атаган җирләрен тарихи чыганакларда "Тукмак Улусы" дип телгә алынуын искәртәләр).

Хәрби частьларны бар кирәкярак нәрсәләр белән комплекслы тәэмин итү урыннары һәм коммуникацияләре – көлләмәләр (кыпчак сүзлегендә "көлләмә" - тәэмин итү) – бүгенге көнгә Коллома, Коломна, Коломенка, Коламенка, Коломак һ.б. атамалар исемнәрендә чагыла (урыс чыганаклары мондый атамаларның элек бик күп булуларын искәртәләр).

Туклануны тәэмин итү белән бәйле урыннар – "казанлы" урыннар - Казанлы, Казанлык, Казанка, Казаново, Казановка; Барановка, Баранинцы, Сарыктау һ.б. шундый бихисап күп топонимнарда чагылыш тапкан, дип фаразларга урын бар.

Гаскәрләрне үзара һәм хәрби үзәкләр белән бәйләп торучы курьер-почта хезмәте инде исбатлауны һич сорамый – болар фәндә киң мәгълүм булган "ям"нар һәм "минзил"ләр челтәре, алар бик күп топонимнарда - Ям, Ямки, Ямполь, Ямы, Ямская; Минзәлә, Menzil (бүгенге көндә: menzil - төрек., крым. татар., азерб., курд., старохорват.; узбек. manzil, румынча men'zil – почтаны аңлата) һ.б. шундый рәвештә бүгенге топонимнарда чагыла. Һәм дә инде зур елгалар аша кичү урыннары – елга ярлары буендагы "Таш кичүләр" - Каменый Брод, Татарский Брод... кебек топонимнар да берникадәр бүгенгәчә сакланып калганнар.

Азмы-күпме хәрби эшләр тарихы белән кызыксынган кеше сугышчыларга тимер кораллар ясау, бихисап ук очлары әзерләү, гаскәриләрне һәм аларның атларын тимер кием, амуниция белән тәэмин итү, аларны даими ремонтлап тору кебек эшләр барлыгын аңлап, ул чор гаскәрләрен тимерчелек пунктларыннан башка күз алдына да китерми. Утлы коралга күчкәч тә әле, 20нче гасыр башында ат дагалау проблемасы булганга, гаскәрләрдә "ремонтёрлер" штатлары торган. Әмма безнең рәсми тарих фәне мондый "вак-төяк" проблемаларны бар дип тә белми, гәрчә бу – тимерчелек хезмәте белән тәэмин итү ифрат зур һәм катлаулы мәсьәлә булган. Авторлар күрсәтәләр: ул чорлардагы гаскәрләрдә, тимерне күз-күмер белән "кузын"нарда кыздырып эреткәннәр (чөнки ул заманнарда кокслаган ташкүмер әле мәгълүм булмаган), һәм мондый алачыкурыннар, һичшиксез, тиешле микъдарда стационар корылмалар белән тәэмин ителгән булуына дәлилләр китерәләр, һәм дә андый корылмалар урыннары, соңра, Урдалар таркалган чорларда, кузын>: Кузновка, Кузнецовка...; тимер> Тимиркузово, Тимиркузово, Тимирюзово, Тимирязово, Темерник һ.б. шундыйрак исемле авылларга нигез биргәннәр. Үз чиратында, болар топонимнарда чагылыш тапканнар. Һәм аңлашыла - бу ремонт пунктлары, үз чиратында, агач күмере белән тәэмин итү пунктларыннан башка эшли алмаганнар (ә андый күмер әзерләү ифрат күп көч таләп иткән), һәм, авторлар исбатлаулары буенча, күренә ки – мондый урыннар Каран сүзе белән билгеләнгән топонимнарда чагылыш тапкан.

Югарыда әйтелеп киткән атамалар һәрбер хәрби подразделениенең маршрут-полигонында мәҗбүри булырга тиешлеге бәхәссез, һәм, чынлап та, аларның эзләре археологик казынулар вакытында әледән-әле очрап тора, барысы да географик киңлек-буйлыклар буйлап кластер принцибында кабатланып торган атамалар комплексларында апачык күренәләр һәм авторларның сүзләренә дәлил булып торалар.

Аңлашыла ки – ошбу хәрби комплекслар белән идарә итү системасының "ГомумУрда" Штабы булганлыгына һич шик була алмый. Ә инде аның төп звенолары

маршрут-полигоннарда булган...

Урыс тикшеренүчесе И. Кондратьев,ниндидер, безнең вакытка килеп җитмәгән чыганакларга таянып, үзенең "Седая старина Москвы" (М., 1893) китабында (6 бит): "Москва была неким «центром или сборным местом» «для проходивших через нее ополчений, потому что князья и воеводы владимирские, новгородские, рязанские и черниговские сходились в нее со своими войсками...", - дип язган.

Димәк, татарларның әлеге хәрби системасы урыслар Татариядән аерылып чыккан чорларда аларга да берникадәр вакыт хезмәт итеп торган.

Әйтеп узгандагыча, авторлар Евразия киңлекләрендә "Мәскәү" сүзенә бәйле топонимик атамаларны шактый тәфсилләп тикшергәннәр (алар барлыгы 130дан артык икән!), һәм аларның һәрбере (санаулы искәрмәләрдән гайре) уртача 55нче параллель тирәсендә (берничә градус аерма белән) урнашкан "мәскәү"ләр тезмәсе булып чыга: Московка, Москаленка, Москwитиновка, Московиха, Старо-, Ново-московск, >Мос[]ква, һәм дә Мәскәү, Мәскәүлек, Мыски татар (казах, хакас) торак пунктлары, яки шундыйрак башка атамалар рәвешендә сакланып калган...

Боларның урнашу нокталары "Кышлак-...Киштак" топонимнары тезмәсе белән иң төньяктагы "Җәйләү-...Жилово"лар арасының уртасыннан берникадәр (10 градус чамасы) көньяктарак булып чыга. Бик җайлы урын: бер яктан, ул маршрут полигоннарының уртасына да якын, икенче яктан, яз фасылы бирегә маршрут-полигонның күпчелектәге җәйләүләреннән иртәрәк, ә кыш исә соңлабрак килә. Тагын бер искитмәле тәңгәллек китерәләр авторлар: тарихчылар сөйли: "төркиләр, һуннар заманыннан бирле язын һәм көзен җыеннар ясап, анда нәтиҗәләр ясаганнар"...

Москва – татарча Мәскәү. Ул - барлык көнчыгыш телләрдә дә "Мәскәү" сүзенә якын яңгырашта һәм сүз формасында. Алай гына да түгел - көнбатыш илләрендә дә шуңа якын яңгырый: Moscou, Moscow формасында, фәкать урыста гына Моск[-]ва рәвешендә! Аеруча кызык һәм игътибарга лаек: татар теленнән гайре башка телләрдә (шул исәптән – урыста) бу сүз һич кулланышта юк. Ә татарда һәм төньяк Казакстанда бүгенгәчә 8 Мәскәү авылы бар икән! Баксаң, татар диалектларында һәм әдәби ядкәрьләрдә (моңа өстәп – казахларныкында) сакланып калган "мәскәү (мәскү-н)" сүзе бар икән, ләбаса. Әлеге "Московия..." китабында ошбу урыс тарихында "йомылган", бүгенгәчә "серле" булып




калган ойконимның татарда кулланышта булганлыгы берничә чыганактан ачыла икән.

Авторларның җентекләп "Мәскәү" атамасының мәгънәсен ачыклауның кайбер мизгелләре. Алар элек үз якташлары булган Хаҗи-ага Әхмәтҗановның "Мәңгелек балачак елгасы" китабыннан берничә юл китерәләр. "Төбәктәге Мәнәүзтамак татар авылында халык "балык мәскәүләргә" (көнкүрештә балык тоту ысул-йоласы исеме) йөри: елганың тын урынында су өстен төнлә яктыртып торалар, моңа балык җыела һәм аларны ансат кына тоталар".

Бу очракта "мәскәү" сүзе "җыелу" сүзенә тәңгәл килүен билгеләп китәләр алар. Икенче очракта авторлар, Кара-бәк шәҗәрәсен искә алып, анда теркәлгән "мәскү – "язлыкта торуг урыны" булуын ассызыклыйлар. Шул ук мәгънәдәге "мәскүн" – казах эпосындагы "Бабалар Сөзі"ендә теркәлеп калган булганны да искәртәләр: «Рабиғ МӘСКҮН дегенің сенің алыс, Бұ сөзіңе ғажапқа біз қаламыз... Рабиғ МӘСКҮН жолыны білермісің, Оны дағы баян қыл Балқияға. – Әй, Балқия, айтайын саған сөзім...» - "Синең язгы Мәскүн дигәнең еракта, Бу сүздән без гаҗәпкә калабыз"... "Язгы мәскүнгә юлны син белмисең..."

Авторлар шуны да искәртә: Адлер Тимергалинның Миллият сүзлегендә дә телгә алынган икән Мәскәү сүзе. "Рабигы мәскүн – кешеләр яши торган җирнең дүрттән бере", - дип аңлаткан Мәҗит Гафури"», диелә (376 бит).

Бәлки, ялгыш тәрҗемә – "язгы мәскүн" тиештер ("рабиг"ның икенче мәгънәсе - язгылык). Ә инде тагын да соңрак дәвердә бу сүз (310 биттә): "Мәскүн - кеше тора торган урын", дип билгеләнгән, ә инде тагын да соңрак дәвердә бу сүз "Мәскән – яшәү урыны, йорт" (309), – дигәнгә калган...

Кайбер мәгълүматларны авторлар Габдерәшит Ибраһим мирасында да күреп алганнар: "Мәгърифәтче Габдерәшит Ибраһим "Бөгрәделек көндәлеге"ндә дә әлеге сүзне кулланып язган булган икән: "Русия хөкүмәте борынгыдан бирле биредә [Омск тирәсендә] КӨЛЛИЯТЛЕ гаскәр булындырмактадыр. Хәрби мәктәпләрдән шул җирдә... искедән кыргыз (казак) таифәсилә МӘСКҮНДЕР (мәскүндә булгандыр). "...мөселман казак илә МӘСКҮН улдыгындан... (мөселмән белән казак бергә мәскүндә булганлыктан)" һәм менә бер Казан ханы – урыс чыганагында болай аталган: «6. Мухаммед-Эмин (1469-1518+) - ...Сын Ибрагима от 2-й жены ..., МОСКОВСКИЙ татарин".

"Мәскәү" татар телендә бөрмә, бөрмәләп тегелгән бала итәк тә икән әле (Татар теленең зур диа-

лектологик сүзлеге, 474 бит) – монда, мәгънә төбендә - уратылып, бөрелеп-җыелып ясалган әйбер. Шуннанмы икән – мәчкәү – тозак, тозак элмәге (петля)?

«Урысларның хәрби ополчениеләренең төп җыйнау урыны" элек "Мәскәү"дә булган» - дип, рус тикшеренүчесе Кондратьевның онытылырга дучар ителгән хезмәтен дә телгә ала авторлар. Хәтта ки, бүгенге көнгә авторлар Пугачевның (ә аның фетнәсен Көнбатышта "Татар фетнәсе" дип атауларын ачыклап), аның биләмә башкаласының шулай ук Мәскәү дип аталган урында булуын ачыклаганнар... Һәм кайда бит әле - Кара-бәк шәҗәрәсендә "Мәскү" дип аталып үткән урында!

Авторлар уенча, ихтимал, бу факт, шулай ук "Әби патшаның" "предать вечному забвению" указына эләгеп, шулай ук "мәскәү" сүзен дә кулланудан төшереп калдырылуга бер сәбәп булгандыр.

Тагын бер кызык мизгелне билгели Нурмөхәммәт әфәнде: Ырымбур шәһәре башта нәкъ шул Пугачев Мәскәүе урынына тәгаенләнә, ә соңрак – күчерелә. Баксаң, Уфаның да беренче бистәләренең берсе Мәскәү булган... Һәм дә инде әлеге "мәскәү" терминының татар теленнән җуелуының икенче сәбәбе - 500 ел элек әһәмиятен югалту, ягъни татар телендә кулланыштан төшереп калдырылуы. Һәм, инде билгеле булуынча, татар архивлары тулаемы белән максатлы рәвештә юк ителгән.

Мәскәү атамасы турында югарыда әйтелгән мәгълүматларны бергә җыйнап, нәтиҗә ясасаң, Мәскәү ул Урдаларның хәрби подразделениеләренең Җыеннарга җыелу ["язгылыкта"] урыны булганы күзаллана. Авторлар моны шулай күзаллыйлар: Көньяктагы кышлакларда кышлаган Урданың һәр полкының аерым подразделениеләре, инде март аенда төньякка таба юлга кузгалып, кыска вакытка гына чәчәк ата торган көньяк чүлләрдә, ярымчүлләрдә, бик кыска вакытка гына чәчәк аткан сыек кына өлгергән үләннәрне малларга утлата-утлата (март-апрель аенда бирeдә яңгырлар, чүл чәчәк атып ала; майда инде корылык башлана), югары географик киңлекләрдәгедән берникадәр тизрәк хәрәкәт итеп, май башы-уртасына - инде үләннәре тәмам кабарып чыккан Даланың төньяк чигендә, берничә подразделениенең урталыгына – "штабына" табан тартылалар. Бу – "Мәскәү"гә җыелу – мәскү-н-московка дип аталган. Бирeдә, хәзергечә әйтсәк, смотр үткәрелгән: личный составны, атларны, сарыкларны барлау һәм сафларны тулыландыру башкарылган, дип уйларга урын җитәрлек, шул исәптән "төркиләрнең" язын һәм көзен шул рәвешчә җыеннар үткәрүләре шактый әдәбияттан да мәгълүм...

Һәм, тагын бер нәтиҗә буларак, авторларның бу анализланган топонимнар комплексларына карашлары бар яктан да берниди каршылыксыз мантыйкка да тәңгәл килә. Һәм бәхәссез, дияргә мөмкин, "мәскәү-московкалар" ниндидер "үзәк, җыелу урыны" мәгънәсен йөрткәнлеге ачыла. Тагын бер штрих: "Московка" дип аталган урыннар күп. Рус теленең кануннары буенча, бу "мәскәүләү" дигәнне аңлата бит! Һичшиксез, сүз кемнәрнеңдер "мәскәүләнгәннәре" турында!

Игътибар белән карасаң, өстә әйтелеп киткән географик киңлекләрдә әледән-әле кабатланып барган "атамалар комплекслары", топонимнарда берникадәр (дип уйларга кала) сакланып калган "Мәскәү-московка" нокталары тирәсендә һәм алардан көньяк һәм төньяк тарафларда урнашкан булуы күренеп тора. Өстәвенә, шунысы да мәгълүм: Төньяк Татариянең Урдалары (ә "урда" армия дигәнне аңлата) – Ак Урда, Күк Урда һәм Урта Кул Урда – нәкъ бит Төньяк Татариядә, башлыча кырыс-экстремаль табигатьле – элеккеге СССР, Балкан һәм Румыния, Венгрияне, Польша территориясендә булган. Тарихчы А. Лызлов, мәсәлән, яза: "Тартария... разделяется на четыре части. ЕДИНА ИМЕЕТ в себе ОРДЫ ВСЕ. Вторая загатаи... Третия обдержит Китай... Четвертая содержит страны мало нам ведомыя, яко Белгиан, Аргон, Арсатер...». Һәм, чынлап та, – Орда дигән ойконимнар (ә алар йөздән артык санда сакланганар) фәкать Төньяк Татариядә генә билгеле. Һәм бит әле, - ди автор, - тарихчыларча "Алтын Урда" дип аталган җирләрнең икенче төрле - "Улус Тукмак" дип тә аталганын ассызыклый...

Сорау туа: ник бу биләмә "Московия" дип аталган? Ә берише чорларда: Европа Московиясе һәм Азия Московиясе дип тә аталган? Димәк, һичшиксез, ниндидер "мәскәүләр" монда "причём" булган. Ә ник алар тарих китапларында юк соң? Һәм ник урыс тарихчылары Руссия, Украина, Белоруссия, Польша җирләрендә булган 130 "Мәскәү-Московка-Москватиновка..." топонимнары белән кызыксынмыйлар икән? Хәзер Хөсәеновләрнең фаразлары тулаем һәм ап-ачык аңлашыла: урыс иленең тарихыннан "Мәскәү" периодын сөртеп ташлап, ялган елъязмалар аша аны "Русь" дип атап язып керткәннәр. (Китапта Хөсәеновләр моны геометрик сызымнар аша график рәвештә дә фашлап күрсәтәләр).

Һәм дә бик урынлы сорау: ошбу географик киңлекләрдә әлеге "Мәскәү..." топонимнары тирәсендә һәм турысында әлеге атамалар комплекслары булуын һәм алар тирәли урнашкан, периодик рәвештә кабатланып очраган (югарыда китерелгән) топонимнар комплекслары барлыкка килүне башкача ничек аңлатырга?

Әлеге "Что есть Московия" китабы басылып чыккач, 2017 елда аталы-уллы Хөсәеновләр, тарихтан филологиягә "сикереп", "Словарь тюркских основ романо-германских языков" сүзлек-белешмә китабы чыгарганнар иде. Әлеге китапта Үзәк һәм Көнбатыш Европа халыклары илләрендә яшәүче халыкларның телләрендәге сүз берәмлекләре башлыча финно-угор телләре аша, ә кайбер очрак-

ларда "турырак" юл белән, татар сүз-тамырлардан сүзләр ясалу алымнары җентекләп каралган, боларга (беренче карашка) һич катлаулы булмаган аңлатма бирелгән. Хәер, авторларның әйтүе буенча, алар, бары тик "мохтаҗлыктан чыгып" ("юл уңаенда" була инде), роман-герман сүзләре нигезендә яткан финно-угор телләре тамырларын дә "тикшереп" үтәләр, ягъни алар нигезендә яткан татар сүз берәмлекләрен күрсәтәләр. Шулай итеп, татар сүзеннән ясалган финно-угор телләре сүзләренең, үз чираты белән, башлыча роман-герман телләрендәге сүзләргә нигез тәшкил итүен күрсәтәләр. Нәкъ менә күрсәтәләр шул: чөнки аларның оригиналь таблицалары аша күрсәткән сүзләр үсеш-күчеше, ап-ачык аңлаешлы итеп татар сүзеннән эзмә-эзлекле рәвештә башка телләр сүзләре барлыкка килү процессы күзгә бәрелеп бара.

Идеаль метод, дияр идем мин, Хөсәеновләрнең ошбу шактый специфик ноу-хоу таблицалары аша сурәтләү ысулын. Һәм монда китерелгән зур күләмдәге финно-угор, роман-герман, ирани телләр сүз массивлары, алай гына да түгел әле – хәтта (чагыштыру өчен китерелгән): япон, кытай, корея, индонезия, америндлар... телләреннән китерелгән тәңгәллекләр – ошбу "Тюркские основы романо-германских языков" китабын укучыны "кайчандыр Евразия һәм Америка халыклары бер телдә - татар телендә сөйләшкән", дигән нәтиҗәгә китереп тери. Бернichә ел элек бу китаплар турында күренекле язучыбыз Солтан Шәмси бик тәсфилләп язып чыккан иде.

Әлеге фикернең урынлы булуын бүгенге әһгәмәбезнең сәбәбе булган, 4 томга исәпләнгән "Контуры Великой Татарии" китапларының 1нче томы ук раслый башлый...

Һәм ошбу китаплар комплексының ниндидер бер планга буйсынып нәшер ителүе аңлашыла башлый төсле. Авторларның мантыйгын бераз шәйләп өлгерсәм дә, өлкән авторга сорау бирдем: "Сез башта урыс-татар теле филологиясе аша "Рус теленең нигезләре"н, татар теленнән икәнен шәйләгән хезмәт бастырдыгыз, аннан соң – Евразия тарихы "эскизы" аша "Мәскәү иленең" татарлыгын тарихи реконструкция аша шактый күләмдә күрсәттегез дә, тагын филологиягә – инде Евразия телләре филологиясенә, дөресрәге - дөнья күләме киңлегендә татар теленнән чыккан телләрне күрсәтүгә күчтегез?"

- Әйе, башта "Рус теленең төрки нигезләре" ачыла, аннан соң – "Мәскәү" иле, асылында, татар иле булганлыгы күрсәтелә. Аннан соң тагын лингвистика – Роман-



герман, финно-угор, индо-иран халыкларының телләре татар теле нигезле икәне... Ә әлеге "Контуры Великой Татарии" китапларының 1нче томы, янә тарихка күчеп, бу киңлекләрдә кайчандыр татарлар булганлы турында шикләнергә һич урын калдырмый, эзмә-эзлекле рәвештә тагын бер кат күрсәтә. Һәм бу китапларыбызның максаты нәкъ "шул гына..."

Аңлашыладыр: ник алдан рус теле филологиясен ачыкладык? Чөнки руслар белән мөнәсәбәтләр татар өчен - иң мөһим мәсьәлә. Икенче яктан – "тел уртаклыгын", рус фамилияләре нигезендә татар исемнәре ятуын күрсәтми торып, "Мәскәү иле"нең татардан хасил булуын кем дә кабул итмәс иде.

Дөресен әйткәндә, әле андый чиратта да "Что есть Московия"дә бирелгән "эскиз"ны да җиңел кабул итүне күз алдында тотмадык. Бу "эскизны" үзебез өчен һәм кайбер татар тарихчыларына фикер уяту өчен генә чыгардык. Планлаштырган 4 томлыгыбызда шул "эскизны" инде җентекләп "реконструкция"дә күрсәтергә уйлыйбыз. Гәрчә, әйе, Мәскәү татарлары чакыруы буенча, Мәскәүдә ул ике китабыбызга презентация дә үткәреп кайттык.

- Ә Татарстанда?

- Татарстанда тарихчы-галимнәрдән бу китапларга игътибар юк.

- Димәк, сез башта "салам җәясез" дә, аның өстенә...

- Нәкъ шулай. Урыс теленең һәм иленең татардан чыгышлы булуын күрсәтү инде үзе үк шактый киң эш башкара бит, алда торган эшләргә алшарт тудыра, чөнки рус теле, ә, киңрәк әйтсәк, "славян телләре төркеме" һинд-европа телләре гаиләсенә керә. Әгәр аларның берсе "татардан" икән, димәк, башкаларының да нигезе шул ук тарафтан... Шуңа күрә без инде "Рус теленең төрки нигезләре сүзлеге" өстендә эшләгәндә үк "Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге" китабына материал туплый килдек.

Ассызыклап әйтәм - һич авырлык тоймыйча. Әле бу хезмәтләребез берникадәр рәвештә минем гимназия директоры, улым Илдарның университетта, аспирантурада укып йөргән чакларына туры килде. Күрәсез ки – эшебез чиксез җентекләп, "буквально", "хәрефләп" анализлап җыйналганнардан гыйбарәт... Һәм инде күрәсез – ошбу әйтелеп үткән 4 хезмәтебез арасында да бернинди каршылыклар тумады – алар бербереен куәтли генә. Шулай итеп, без алдагы хезмәтләребездә "Контуры Великой Татарии" китапларының 1нче томына нигезләмә ясадык, һәм диалектиканың чираттагы канунnарына тәңгәллектә – "күләм үсеше – сыйфат үсешенә китерү"ен истә тотып, тагын бер кабат "ин-

карь итүдән" "баш тартып" ("отрицание отрицания"), лингвистикадан янә тарих өлкәсенә "күчтек".

Биредә дә шул ук принцип: тарих өлкәсендә яңа, "сыйфатлы" фикергә дәгъва кылу өчен, хезмәтебезнең беренче томында фәкать "күләм үстерү" эшенә тотындык - бу китапта бары тик дөнья йөзендә, континентларда кешелек мирасында фәкать "татар" сүзе белән бәйле мәгълүматны гына китерүне урынлы, дип таптык, һәм фәкать шуңа гына бәйле чынбарлык объектлары тасвирлана биредә. Алай да, күрәсез ки, нинди күләмле булып килеп чыкты китап! Ә монда бит әле кайчандыр "татар" исеме белән бәйләп аталган хәзерге милләт атамалары күрсәтелми калды – алар 2нче томда шактый урын алачаклар".

Хәзер укучыга әлеге шактый күләмле, 586 битлек китапның бүлекләрен бик кыскача гына тасвирлап үтәбез.

Китапның 1нче бүлегендә дөнья илләре буйлап "Татар/Tatar" сүзеннән ясалган географик атамалар – топонимнар тезмәсе китерелә. Китапны гамәлгә куйганда шундый 1325 топоним билгеле булган булса, бүгенгә авторлар инде шундыйларның 1500 данәсенең координатларын билгеләгәннәр. Бу топонимнарны картага керткәннәр һәм шул сәбәпле Тын океаны - Океания утрауларыннан башлап, Австралия, Индонезия, Япония, Филлипин, Кытай – бөтен Азия карталары алардан чуп-чуар булып күзгә ташлана. Әмма тагын да куерак - Европада – биредә Көнчыгыш Германиягә кадәр; Африкада – Мавританиягә кадәр. Көньяк Америкада – "Огненная земля"дан башлап Панамага кадәр. Болар – 1500 данә, барысы да "Татар" сүзе белән! Ике генә "ТаРтар" топонимы бар, аларны үткән гасырда атаганнар. Мәсәлән, Антарктида янындагы бер кыя-утрауны инглизләр атаганнар, чөнки ачыш ясаучы "Тартар" исемле корабның экипажы булган. Иранда үткән гасырда хасил булган бер ясалма сусаклагычбуаны шулай атаганнар. Димәк, Тартария түгел – Татария.

100гә якын "татар" сүзенә бәйле топонимнар инде юкка чыккан, әмма аларның булуы һәм урыннары турында мәгълүматлар төрле документларда теркәлеп өлгергән булганлыктан, болар шулай ук китапта теркәлгән. Бу 1500 топоним, тимер казыклар шикелле, Бөек Татариянең чикләрен һәм эчке өлешен тулаем бер җәймә-катлам итеп билгеләп торалар. Татар монда булмаган булса, кем атар иде аларны "Татар" дигән исем белән? Бу топонимнарның исемнәреннән тыш, аларның административ өлкәләре һәм координатлары бирелә. Шактые турында бик кызыклы өстәмә белешмә дә китерелә.

Китапның 2нче бүлегендә шулай ук "татар" сүзеннән ясалган сәяси, социаль, табигый атама тезмәләре, һәрберенә белешмә-аңлатма (әдәбиятка сылтамалар белән) бирелә бара. Алар төрле көнкүреш өлкәләренә тупланып бирелә. Мәсәлән, Японидә (14 "Татар" топонимыннан тыш, тагын) "Татара-мичләрдә", "Татара процесс" ярдәмендә "Татара-корычы" эретеп алалар икән дә, фәкать аңардан самурай кылычлары ясыйлар. Японнарда кыю хәрәкәт итү, кыю адымга бару – "татар адымы" - "татарская поступь" дип атала. Аларда милли сугышчан көрәш төрләрендә һәм нетрадицион медициналарында "татар", дип аталган шактый алымнар (приемнар) бар. Монда, утраулар арасындагы Эчке диңгездә, мәһабәт, озынлыгы бер километрга якын "Татар күпере" бар. Тагын бер мисал: Тын океанда, Француз Полинезиясе дип аталган берничә бөртек нокта рәвешендә билгеләнгән утрауда 3 татар топонимы сакланып калган, өстәвенә, анда "Татаро-моа" исемле шифалы куак-үсемлек үсә. Аларның телендә "Татара-кайукае" дигән фәрештә Тәңгәрә аллаһның хезмәтчесе санала... Биредә иң мәһабәт агач – "тотара" агачы... Менә шундый "татар" сүзе белән бәйләнешле төрле әйбер атамалары җир йөзендә 300гә якын табылды, һәм аларның да яшәештаралыш ареалларын картага җәйсәң, алар (бик аз гына чигенеш белән) шул ук топонимнар каплаган киңлекләрне каплыйлар. Европадамы? Германиядә 8 "татар" топонимы бар, герман телле илләрдә (Германия, Австрия, Швейцария) "татаенһут" дигән ризык пешерү җайланмасы, "татарброд" атлы икмәк, "тартар" атлы бар соуслар, салатлар, бифштекслар... Монда татарның борынгы көнкүреше җанлы образлар аша бирелә.

Бу бүлектә аеруча игътибарга лаек - "татар" этнонимының бихисап күп тарихи чыганакларда "скиф" атамасына бәрабәр итеп күрсәтелүе.

Китапның 3нче бүлеге. Монда төрле илләрдә "татар" дип аталган фамилияләр барланган. Кызганычка, шактый илләрнең халыкларының фамилияләре буенча белешмә китаплар гамәлдә юк икән. Шулай да, кайбер илләрдә аерым шәхесләрне булса да эзләп табып, кайсы илләрдә Татар, Татара, Татарено, Татарко, Татару, Татаренко, Татаринов... фамилияләрен барлап күрсәткәннәр. Мәсәлән, Кипрның төрек ягы Президенты Татар дигән фамилия йөртә, Әфган татарларының башлыгы да шундый фамилиядә...

"Китапны басмага керткәндә безгә утызлап илнең генә фамилияләр белешмәләре билгеле иде, хәзер исә без "Татар" исеме белән аталган фамилияләрне 91 илдә таптык!" – ди Нурмөхәммәт әфәнде. Бу – "Татар" фамилиясе йөрткән миллионлаган кешеләр катламы булган илләр белән дә җир шары катылыгының иң күпчелек өлеше каплана.

Китапның 4нче бүлегендә исә татарның бөек һәм данлы тарихы барлыгын күрсәтүче, 330дан артык "Бөек Татария"нең чикләре билгеләгән карталар барлыгы бәян ителә; шуларның 90нан артыгы китапка куелган; аларга бик фәһемле аңлатмалар бирелә. Кызганычка, бу карталарның иң борынгылары 14 нче гасырга, Бөек

Татариянең шактый таркалыш кичергән вакытына карый икән, әмма, шулай булса да, алардан “Бөек Татария” дәүләтенең бөтен Азияне, Океанияне, Европаны – “Онега губа”сына, Суздальгә, Балканга тиклем җирләрне үз эченә алганы күренә.

Китапның 5нче бүлеге Бөек Татариянең символик атрибутикасына багышланган. Татариянең символлары 100% дәлилләнеп, ап-ачык итеп билгеләнгән: грифон (Нажагай), “өч япле бизәк” (трезубец > бусы тора бара лалә-тюльпанга әверелгән); һәм “сигез почмаклы Йолдыз белән Ай”. Китапта аларның һәрберенә тулы аңлатма һәм кулланыш киңлеге күрсәтелә. Баксаң, Мисыр – татарның бөек ханнарының мизары икән!

Әлеге татар символлары төшерелгән тәңкәләр, каеш аеллары (перәшкәләр), плитәләр, монументлар, биналар калдыкларындагы бизәкләр һ.б. дөньяның ифрат күп төбәкләрендә табылган. Шулар арасында – Нажагай – бик күп илләрдә суднолар капитаннары өчен чыгарыла торган “Диңгез атлас”ларында “татар флагы” исеме белән аталган флагларда сурәтләнеп, ныклы һәм бәхәссез урын алган. Боларга кагылышлы табылдыклар да, табылган урыннары билгеләнеп, картага салынып, Бөек Татариянең чикләрен билгеләгән, алдарак китерелгән маркерлар өстенә ятып, аның чикләрен-контурларын ачык итеп күрсәтергә өстәмә дәлилләр булып торалар.

Китапның 6нчы бүлеге Татар дөньясын “вакыт тасмасында”, ягъни аның хронологик яктан чагылышын күрсәтә. Биредә дә “татар” исеме фәкать тарихи чыганаклар тезмәсе аша гына күрсәтелә. Укучы Татар дөньясының безнең эрага кадәр 200 нче еллардан мәгълүм булганлыгын һәм шул чорлардан бирле бар гасырларда да эзмә-эзлекле рәвештә бу этнонимның дөнья киңлегендә гамәлдә булган чыганакларда бихисап күп тапкырлар чагылуын күрә ала. Шул исәптән (үзе бер принципиаль ачыш!) шактый соң дәверләрдә генә татарларның бер өлешенә “төрек” атамасы европалылардан кереп тагылган экзоним икәне ачыла. Шул рәвешчә, бу бүлектәге мәгълүмат та, шактый кимәлдә, татарларның дөнья күләмендә билгән киңлекләрен тагын бер тапкыр кабатлап күрсәтә.

Китапның 7нче бүлеге Чыңгызханның килеп чыгышына һәм аның кыяфәтен сурәтләгән чыганакларга багышланган. Биредә без аның үзенең һәм



җитәкләгән халкының татар булуын, үзенең европеоид булганлыгын рәсемнәрдән һәм документлар җыелмасы аша күрә алабыз.

Китапның 8нче бүлеге “Татария – үткәннәрдән – киләчәккә” (“Татария - из прошлого в будущее”) дип атала. Биредә кешелек дөньясының Бөек Татариядән алган казанышларны, андагы принципиаль ачышларның нәтиҗәләрен куллану очраклары күрсәтелә. Баксаң, бик күп нәрсәләргә татарлар башлангыч биргән булган. Искитмәле ич – 13нче гасырда ук биредә кәгазь акчалар, банк системасы эшләгән, бушлай социаль страхование булган! Тагын бер кызыклы факт ачыла: бүгенге көннәрдә дә ниндидер яңа ачышларны, җисемнәрне “Татар” исеме белән атау очраклары дәвам итә икән әле дөньяда...

Авторлар китапта кызыклы киләчәк юрауларны китерәләр: “Дөньяның иң күренекле күрәзәчеләре: Нострадамус, Неро, Ванга – кешелек дөньясының киләчәктә “кеше йөзле” җәмгыяткә кайтуын Бөек Татария, турыдан-туры татар җирләре белән бәйләп юрыйлар; шуңарга өстәп, хәзерге заманның күренекле юраучылары: Кейси һәм Хайдал да шундый ук перспективаны Рәсәй җиреннән, ягъни тарихи Татариядән булачак, дип фаразлыйлар”.

Ирексездән Л.Н. Гумилевның “Черная легенда” хезмәте хәтергә килә. Тарихчы ул язмасында (хәер, башка китапларында да) татар исеменә төшкән ялган тарихлардан арыныр вакытлар җитәчәгенә ышанычын белдереп язган иде. Хәзерге көндә Казан уртасында Л.Н. Гумилевка, аңа тирән хөрмәт йөзеннән, һәйкәл тора. Аталы-уллы Хөсәеновләр, үз китапларында бары тик бүгенгәчә күзгә төртелеп торган “табигый” фактларга гына таянып та, татар халкы тарихына тиңсез принципиаль ачыклык кертәләр һәм шул рәвешчә аны һәртөрле уйдырмадан арындыруга принципиаль яңа юл ачалар. Аларның китаплары кешеләрнең кайчандыр бер телдә сөйләшүче, бер халык булып яшәвен искәртеп, әле дә үзара бүлешер нәрсә юклыгын, барча халыкны тыныч тормышның кадерен белеп, рухи, матди үсештә яшәү кирәген кисәтә төсле. Библия дә булган берлекне инкарь итми: “Вот один народ, и един его язык; сойдем, смешаем их язык так, чтоб один не понимал язык другого”.

“Беренче том – ул фәкать татар тарихы нигезенә (генә) кереш сүз”, - дип аңлата өлкән автор. Кыю итеп фаразлый алабыз: Хөсәеновләр тарафыннан языласы “Бөек Татариянең әлеге сериядәге киләсе 2-4нче китапларында, Бөек Татариянең “Московия...” “эскиз китабында” халкыбызның шәрехләнеп үтелгән шанлы тарихына яңа карашны тагын да ачыграк күрербез. Мин уйлыйм – бу китапларның һәммәсен һәм чыгачак томнарны татар телендә чыгару бик тә зарур.

# ЗАЛИЯ ХИСАМИ:
# “РАДИОБЫЗ ҮЗГӘРМӘДЕ, ЗАМАН ҮЗГӘРДЕ”



Соңгы елларда безнең бөтен көнкүрешебез интернетка бәйләнде. Бүгенге көндә аннан башка яшәүне күз алдына китерүе кыен. Газета-журналлар да акрынлап эшчәнлекләрен интернет киңлекләренә күчерә башлыйлар.

Июль азагында узган Бөтендөнья татар конгрессы съездында Башкортостанда эшләп килүче “Роксана” татар радиосы дикторы Залия Хисами белән танышу бәхетенә ирештек. Әлеге радионы интернет киңлекләрендә дә ишетергә була.

Самарда яшәүче татарларны берникадәр вакыт шатландырып торган татар радиосын әле күпләребез бик әйбәт хәтерлидер. Бәлки, татар радиосының эшчәнлеген интернет-радио рәвешендә яңартып булыр иде? Шуңа күрә Залия ханымга, “Роксана” радиосы турында тәфсилләбрәк сөйләвен үтенеп, мөрәҗәгать иттек.

**Эльмира СӘЙФУЛЛИНА**

Элек Залия Хисами (Залия Ахунова) белән танышыйк. Ул – Башкортостанда гына түгел, Татарстанда да танылган диктор, журналист, нәфис сүз остасы. Тумышы белән Башкортостанның Баязитово авылыннан. Балачакта астроном булу турында хыяллана, мәктәптә иң яраткан фәне математика булган. Әмма ул татар филологиясен сайлый һәм бу юнәлештә югары белем ала. Егерме елдан артык «Роксана» радиосы тыңлаучыларын ягымлы тавышы, актуаль темалар белән шатландырып тора.



*Эльмир Булатов*

– Безнең радио бик күп еллар Уфа шәһәре һәм Уфадан 100 километр ераклыктагы дулкыннарда эшләде. Күпме генә тырышсак та, радиодулкыннарны бөтен республика буенча җибәрергә мөмкинчелек булмады. Безнең редакциягә Эльмир Булатов килгәч, редактор һәм диктор вазифаларын үти башлады. Интернет челтәренең мөмкинлекләре чиксез булганга, ул безнең радионы онлайн форматка чыгарды. Бүгенге көндә “Роксана” радиосын, Украинадан кала, бөтен дөньяда яшәүче татарлар тыңлый ала, һәм ул рейтинг буенча 1 урында тора.

– Бу башкарып чыкмаслык авыр мәсьәлә түгел. Бары тик теләк кирәк, - дип аңлата Эльмир.

Моның өчен тәүлек буе эшләп торучы компьютер һәм арендага сервер алырга кирәк, - ди җитәкче.

– Элек безнең радиода 25-30лап кеше эшли иде, ике сәгать - башкортча, 2 сәгать татарча тапшырулар алып бара идек, төнлә дә - иртәнге 5 кадәр эшли идек. Генераль директорыбыз үлгәч, радиода төрле үзгәрешләр булды. Хәзерге вакытта коллективта 10лап кеше калды. Барысы да - татарлар. Алар инде радионы нык яратучы, үз эшенә бөтен җаны-тәне белән бирелгән кешеләр, - дип дәвам итә сүзен Залия. - Башкириядә радио аша котлаулар - бик популяр әйбер. Радио тыңлаучыларыбыз бик актив бу юнәлештә. Алар өчен бу бик уңайлы. Чөнки алар кемне котларга, нинди очрак буенча һәм кем котлаганны әйтәләр дә калган котлау сүзләрен без үзебез сайлап, матур итеп эфир аша җиткерәбез. СМСлар, вайбер-ватсап заманасында кеше күңеле матур, җылы сүзләргә сусаган, без акрынлап аларны оныта барабыз. Шуңа күрә радио аша җиткерелгән матур теләкләр һәм ихлас котлаулар тамашачыга бик кирәк. Котлаулар тапшыруын алып баручы буларак, мин һәр эфирга аеруча тырышып әзерләнәм. Кыска гына вакыт эчендә котлыйм, телим генә түгел, ә гаилә кыйммәтләрен дә, туганлык җепләрен дә, философик темаларны да онытмаска тырышам.

Шулай ук мин «Бәхет ачкычы» дигән тапшыру алып барам. Ул атнасына бер мәртәбә генә чыга. Бик



күп радиога интервьюга башлыча танылган кешеләр, җырчылар килә. Ә “Бәхет ачкычы” тапшыруына татар яки башкорт телендә иркен аралашкан, үз эшен яхшы белгән һәм яратып башкарган шәхесләрне чакырам һәм “Нәрсә ул - бәхет” дигән темага сөйләшәбез. Бу тапшыруда риэлторлар да, психологлар да, агрономнар да, кулинарлар, турагентлар, профессорлар һәм башка һөнәр ияләре катнашты инде.

Башкортостанда яшәгәнгә күрә, эфирыбызда башкорт җырлары да еш яңгырый. Чөнки башкорт моңнары искиткеч матур бит. Эльмир Булатов бик «тәмле» итеп «Музыкаль десерт»ны алып бара, яшь алып баручыбыз Алинә Галиева «Яшьлек дулкыны»н башлап җибәрде. Анда блогерлар, актив яшьләр белән әңгәмәләр була. Алып баручыбыз Алинә - үзе дә бик яшь һәм талантлы диктор.

Безнең радио төрле яшьтәге аудиториягә юнәлтелгән. Әбичәбиләргә дә, абый-апаларга да, яшьләргә дә кызыклы ул. “Иртәнге агентлар” сәхифәсе, радио тыңлаучылар белән туры элемтәгә чыгып, төрле ситуацияләрдә аралашуны күздә тота. Мәсәлән, безгә шалтыратучы бөкедә басып торуын хәбәр итә һәм без, аның җитәкчесенә шалтыратып, бу хакта кисәтергә тиеш. Тыңлаучыбызның теләген үтибез, әлбәттә. “Фәлән Фәләнович, сезнең хезмәткәрегез бөкедә утыра, бераз эшкә соңгарыр”, – дибез. Җитәкче башта бик җитди генә сөйләшә, соңрак языла... Әмма бу шулкадәр кызык килеп чыга ки, соңында барыбыз да рәхәтләнеп көләбез.

“Саумы, иртә” сәхифәсендә радио тыңлаучыларыбызны төрле яңалыклар, кызыклы вакыйгалар белән таныштырабыз. Аулак өй, танышу кичәләре дә бар. «Нур» театры артистлары безнең студиядә еш булалар. Шулай ук тамашачыларны сәхнә арты хезмәткәрләре белән дә таныштырабыз.

Элек безнең радио “Шәрык” исеме астында эшләде. Генераль директорыбызның яраткан кызы Роксана исемле иде. Шуңа инде төрле документаль үзгәрешләр вакытында радио “Роксана” дип атала башлады.

Радио яшәсен өчен акча кирәк. Безгә реклама һәм котлаулар акча китерәләр. Радионы чын күңелдән яратмасаң, аны алып барып, яшәтеп булмый. Безнең мөхәрриребез Эльмир Булатов радионы җаны-тәне белән ярата. Шуңа күрә без әле озак еллар тамашачыбызны эфирларыбыз белән шатландырып тора алырбыз, дип өметләнәм.

Элекке җитәкчебез әрмән кешесе иде. Шулай да, радионы искиткеч яратканлыктан, ничәмә ничә еллар дәвамында безнең радио гөрләп торды. Милләттәшләребез туган телгә сусаган вакытта барлыкка килгән радионы халык шунда ук үз итте, яратты. Директорыбыз тырышлыгы белән төрле бәйрәмнәр, шоулар уздыра идек. Залларга тамашачылар шыплап тула иде. Дикторлар белән танышып, аралашып, дуслашып китә идек. Радионы яратмаган кеше андый эшләр башкармый бит инде ул. Әрмән кешесе булса да, татар радиосын искиткеч популяр ясады ул.

Читтә яшәүче татарлар куллансын дип, үземнең YouTube каналымда (Zalia Hisami) радиотапшырулар өчен әзер материаллар куеп барам. Алар төрле темаларга багышланган. Мәсәлән, шигырь, кыйсса, мәкаль-әйтемнәр, эни, икмәк, туган як темалары. Бу - җырлар белән аралаштырып язылган әзер тапшырулар. Миңа алар өчен акча да кирәкми, рәхәтләнеп куллансыннар гына. Минемчә, алар бик файдалы, – ди Залия ханым.

Әңгәмәдәшем Самар активисты Фәрхат Мәхмүтов белән таныш булган. “Бик иртә мәрхүм булды, бик кызганыч”, – дип сыкрана ул.



– Без аның белән төрле җыеннарда, форумнарда, хәтта Стамбулда узган чарада да бергә катнашкан идек. Мин заманында татар яшьләре лидеры идем. Хәзерге вакытта җирле хатын-кызлар иҗтимагый оешмалары эшчәнлегендә катнашам. Безнең диагноз күптән куелган инде - без милләт өчен җанып-көеп, бөтен тырышлыкны куючы кешеләр, - дип елмая танылган журналист.

- Радиода акча эшләр өчен хезмәт итмибез. Монда халыкка милли моң, туган телне җиткерергә теләүче, үз эшен нык яраткан киң күңелле кешеләр генә эшли, - дип тәмамлады сүзен Залия Хисами.




# ТЕЛӘК БУЛСА - БАР ДА БУЛА...

***Туган телне саклау һәм үстерү — көнүзәк мәсьәлә, чөнки телнең яшәеше, үсеше халыкның аны көндәлек тормышта ни дәрәҗәдә куллануына бәйле. Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул — әти-әни, туган җир, Ватан сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә бөек, изге сүз.***

***Әңгәмәдәш - Эльмира СӘЙФУЛЛИНА.***

Туган телгә баланы аның иң газиз, якын кешесе – әнисе, назлы бишек җырлары җырлап, иркәли, юатып өйрәтә. Шуңа күрә аны халык ана теле, дип атый.

Баланың ана телен үзләштерүе һәм аны актив куллануы, шул телдә тәрбия һәм белем алуы аның һәрьяклы үсеше өчен уңай шарт булып тора.

Әмма Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен туган телдә белем алу, хәтта аралашу да бүгенге көндә зур проблема булып кала бирә. Регионнарда яшәүче милләттәшләребез татар телен, милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу өчен күп көч һәм тырышлык куялар - милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачалар, түгәрәкләр оештыралар.

Күрше Саратов өлкәсендә 154 санлы «Чишмә» милли балалар бакчасы 1994 елның октябреннән бирле эшләп килә.

***- Римма ханым, Саратовның милли балалар бакчасы ничек яши? Самарда да ике татар балалар бакчасы бар. Әмма бездә алар - шәхси, ә сездә - муниципаль оешма.***

- Чишмә" татар балалар бакчасы 154 санлы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе базасында ачылды. Бу эштә Идел буе мөселманнары Дини нәзарәте имамы Мөкаддәс Габбас улы Бибарсовның, ислам хәйрия фондының мактаулы рәисе Митясим Шиһабеддин улы Сөләймановның өлеше зур. Күренекле эшмәкәр һәм меценат, Саратов өлкәсе губернаторы киңәшчесе һәм төбәк



татарларының милли-мәдәни автономиясе башлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары һәм «Татарларның тарихи язмышы» китабы авторы Аблязов Камил Алим улы һәм күп еллар дәвамында әлеге балалар бакчасын җитәкләгән педагог, күпләргә үрнәк булырлык кеше Мингалиева Хәтирә Умяр кызы да зур ярдәм күрсәттеләр.

Бакчаны финанслау - тулысынча шәһәр хакимияте карамагында. Берникадәр вакыт попечительләр советы ярдәм итте. Шулай ук безнең бакчага Россия президенты советнигы Вячеслав Викторович Володин нык булыша. Тумышы белән Саратовтан булган сәясәт эшлеклесе туган җирен онытмый. Күп балалы укытучы гаиләсендә үскән якташыбыз мәктәпләр, балалар бакчалары, юллар төзетә, шәһәребезгә һәрдаим булышып тора, - дип сөйли «Чишмә»нең бүгенге җитәкчесе Римма Камиловна Абдульмянова.

Ул үзе тумышы белән Ульяновск өлкәсе Иске Кулатк районыннан. 2000 - 2008 елларда Карамалы авылы урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән. Мәктәпне япканнан соң, язмыш җилләре аны Саратовка илтә. Шулай итеп, ул 2007 елдан 2017 елга кадәр «Чишмә»дә өлкән тәрбияче булып эшли. Аннан соң, Хәтирә ханым, лаеклы ялга китәр вакыты җиткәч, Римманы үз урынына калдыра.

- Балалар бакчасы эшендә татар халкының телен, мәдәниятен һәм тарихын өйрәнү өстенлекле юнәлеш булып тора. Оешманың бөтен эше, татар халкының иң күркәм гореф-гадәтләренә таянып, балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирүгә нигезләнә. Кече Ватанга мәхәббәт тәрбияләү аша без Россиягә мәхәббәт тәрбиялибез. Анага мәхәббәт тәрбияләүгә аерым игътибар бирелә. Шулай ук без балаларда туганнарыбызга, күршеләребезгә, дусларыбызга, бигрәк тә татар халкының милли үзенчәлеге булган олыларга карата хөрмәт хисе тәрбиялибез. Балаларны мөселманнар һәм христианнар тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыру процессында без аларга толерантлык салырга тырышабыз.

Ел саен безнең балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр, төрле дәрәҗәдәге конкурс һәм фестивальләрдә катнашып, җиңүчеләр исемлегенә керәләр, - дип сөйли Римма Камиловна.

***- Сезнең бакчада бары тик татарлар гына эшлиме? Алар татар телен беләләрме?***

- Әйе, 26 хезмәткәребезнең барысы да - татарлар. Хәтта вахтерыбыз һәм урам җыештыручыбыз да - татар милләтеннән. Башка милләтләр арасында яшәп, туган телебездә аралашырга сусаган якташларым өчен безнең бакча бер сихри утрау кебек. Эшкә килгәч, без үзара бары тик татарча гына сөйләшәбез. Безнең өчен бу - зур бәхет.

***- Балалар бакчасы муниципаль булгач, ашау ягы ничегрәк, хәләл ризык кулланырга рөхсәт ителәме?***

- Аллаһыга шөкер, безнең балалар хәләл ризык белән туклаalar.

Бу мәсьәләне хәл итүдә дә шәһәр администрациясе бик нык ярдәм итте. Башка бакчаларда балалар сосискалар ашаганда, безнекеләр рәхәтләнеп хәләл сыер ите ашыйлар.

***- Бакчага татар балалары гына йөриме? Бакча шәһәр карамагында булганлыктан, электрон чиратлар, территориаль бәйләнеш тә бардыр бит?***

- «Чишмә» ачылган гына елларда анда гел татар балалары гына кабул ителә иде. Хәзер катнаш гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар да шактый. Аннан соң, бездә хәләл туклану булганга, мөселман динендә булган башка милләт кешеләре дә балаларын безнең бакчага бирәләр. Шулай ук безнең бакчада тәртип тә, чисталык та югары дәрәҗәдә оештырылган. Шуңа күрә безгә балалар шәһәрнең бөтен районнарыннан киләләр. Хәтта Иделнең аръягында урнашкан Энгельс шәһәреннән дә йөртүчеләр бар.

Балаларны электрон чират буенча кабул итәбез. Әмма, шәһәрдә бердәнбер милли балалар бакчасы





булганлыктан, без территориаль бәйләнештән азат ителгән.

***- Сезнең бакча башка мәктәпкәчә оешмалардан нәрсәсе белән аерылып тора?***

- Мәгариф турындагы закон буенча, барлык дәресләр дә рус телендә уза. Ә балалар белән аралашу - татар телендә. Исәнләшү, хәл-әхвәл сорашу, ашау-эчү, киемсалым, гомумән, көнкүрештә еш кулланыла торган темаларга балалар белән татарча сөйләшәбез.

Һәр көнне, балалар төшке ашны ашап, йоклап, ял итеп алганнан соң, аларны төркемнәргә бүлеп, татар теле дәресләре уздырабыз. Анда малайлар-кызлар татарча әкиятләр тыңлыйлар, шигырьләр, җырлар өйрәнәләр, шагыйрьләребез, язучыларыбыз иҗаты белән танышалар.

Бакчада узган чараларның 50 проценты рус телендә узса, калган яртысы татар телендә үтә. Ел саен «Каз өмәсе», «Карга боткасы», «Сөмбелә», «Сабантуй» кебек милли бәйрәмнәребезне, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган кичә уздырабыз. Сабыйларыбыз да, ата-аналар да анда рәхәтләнеп катнашалар.

***- Балалар үзара татарча сөйләшәләрме?***

- Төрлесе бар. Авылча матур иттереп татарча сөйләшүче малайкызларыбыз да бар, сөйләшергә авырсынучылары да бар. Авылдан күчеп килгән балалар татарча бик иркен аралашалар. Аларның уйнаганда сөйләшкәнен тыңлап торуы үзе бер рәхәт. Ата-анасы өйдә татарча сөйләшкән балалар да сизелерлек әйбәт сөйләшәләр. Ә менә катнаш гаиләдә үскән балалар өчен туган тел авыррак бирелә. Күптән түгел генә узган Бөтендөнья татар конгрессында бик тирән мәгънәле сүзләр ишеттем: яһүдиләр башка милләт кешеләре белән гаилә корса да, балалары яһүди булып калалар, ә татарлар катнаш гаиләдә эриләр, юкка чыгалар, татарлыгын югалталар. Бу, чыннан да, шулай, кызганычка...

***- Ата-аналар балалар бакчасы тормышында катнашалармы, ярдәм итәләрме?***

- Безнең ата-аналар бик актив. Кар чистартырга дисеңме, язгы-көзге өмәләргә дисеңме - җыелышып килеп, бөтен эшне ялт итеп эшләп куялар. Бик зур рәхмәт аларга. Шәһәребездә милли балалар бакчасы булуга алар бик шат. Шуңа күрә тору урыннары бакчадан никадәр ерак булса да, сабыйларын безгә китерәләр.

«Сез бит балаларны колач җәеп каршы аласыз, аларны тәрбияләүгә бөтен җан-тәнегез белән бирелгәнсез. Без дә, монда килгәч, рәхәтләнеп туган телебездә аралашабыз», - диләр.

Чыннан да, безнең балалар бакчасы бер гаилә сыман. Безгә килгән кунаклар да, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары да аның үзенчәлеген, уникальлеген, хезмәткәрләрнең тырышлыгын һәм профессиональлеген билгеләп үтәләр.

***- Милли балалар бакчасында салынган орлыкларны алга таба да ныгытырга, үстерергә мөмкинлек булса, бик әйбәт булыр иде...***

- Әйе, килешәм. Безнең Саратовта туксанынчы еллар башыннан Советлар Союзы Герое Гаяз Рамаев исемен йөртүче татар гимназиясе эшләп килә. «Чишмә» балалар бакчасыннан чыгучыларның күбесе шунда белем алалар. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында, башка мәктәпләрне сайлаучылар да бар. Безгә ерак дигән сәбәп атаучылар да бар. Гимназия белән балалар бакчасы янәшә урнашкан, бакчага йөртергә ерак булмаган, ә хәзер ерагайган... Аңлап бетермим андый ата-аналарны, - дип йомгаклады сүзен әңгәмәдәшем.

Чыннан да, шундый мөмкинлекләр булганда туган телне өйрәнергә теләк булмау аңлашылмый. Америка Кушма Штатларында, Япониядә, Англиядә, Австралиядә яшәүче милләттәшләребезнең берләшеп, милли бәйрәмнәр, түгәрәкләр оештыруы сокландыра. Ардагы туган телне саклау теләге күпләребезгә үрнәк булырлык.

Саратовта эшләп килүче милли муниципаль балалар бакчасы да үз эшчәнлеге белән: “Теләк булса - бар да була”, дигән гыйбарәне исбатлый, минемчә.





***Үзебезнең татар авылында туып-үскән, татар мәктәбендә укыган яшьләребез арасында, туган телен кирәксенмичә, үзара рус телендә аралашучылар бар. Ә Татарстаннан читтә – Россия төбәкләрендә, башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез татар телендә сөйләшергә омтыла.***
***«Чит җирләрдә гомер итүче татарлар өчен ана теле аеруча кадерле. Алар башка милләт вәкилләре арасында югалмыйча, үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклап, ассимиляциягә бирешмичә яшәргә тырышалар», – ди «Alima Academy» онлайн мәктәбенең татар теле укытучысы Гөлчәчәк Вәлиева.***

*Гөлназ Таипова*



# ТАТАР ТЕЛЕ: ИЛДӘН ЕРАГАЙГАН САЕН – КАДЕРЛЕРӘК

Гөлчәчәк Факил кызы Вәлиева 2007 елны Татар дәүләт гуманитар-педагогик институтының татар филологиясе факультетын тәмамлый. Ун елга якын журналистика өлкәсендә эшли. Бөгелмә, Яр Чаллы шәһәрләрендә яши. 2018 елны Мәскәү өлкәсенә күчә, татар телен укыта башлый. Хәзерге вакытта ул балалар үзәгендә эшли һәм чит илләрдә яшәүче татарлар өчен онлайн дәресләр алып бара.

### Ана теле – милли үзаңны саклау чарасы

– Урамда йөргәндә, кибетләргә кергәндә кызым белән гел рус телендә сөйләшә идем. Югыйсә, үзем бит - татар гаиләсендә үсеп, татар телендә югары белем алган кеше, – дип сөйли Гөлчәчәк ханым. – Ә Мәскәү өлкәсенә күчкәч, игътибар итә башладым: урамга чыксаң да, кибеткә керсәң дә, колакка башка телләр ишетелә. Һәрберсе үз туган телендә сөйләшә. Көн дәвамында, ким дигәндә, унлап төрле тел ишетәсең. Россиянең башка төбәкләреннән, Урта Азия, Кавказ, Европа, БДБ илләреннән килгән төрле милләт вәкилләре үз телләрендә аралашалар. Бу миңа шундый зур ачыш булды. Нигә соң мин, авыл кызы, профессиональ татар теле укытучысы, үз кызым белән русча сөйләшәм?! – дип уйладым. Сөйләшик рәхәтләнеп татарча! Ә Мәскәүдә, өлкәдә, үз гаиләңнән тыш та татар телендә аралашырдай кешеләр җитәрлек.

Минемчә, үз тамырларын, үз телен белмәгән кеше тулысынча бәхетле була алмый. Чит ил мәдәниятен үзеңә сеңдереп, син барыбер ул милләт булмыйсың, бары үз йөзеңне генә югалтасың, тамырларыңнан китәсең. Бу бигрәк тә Татарстаннан читкә киткәч сизелә. Чит җирләрдә яшәүче татарлар өчен туган телдә сөйләшү – милли үзаңны саклау чарасы. Шуңа күрә алар үзләре дә татарча сөйләшергә тырыша, балаларын да өйрәтә. Нәсел шәҗәрәсен төзеп, милли ризыклар әзерләп, ата-бабалардан калган йолаларны үтәп яши. Татар иленнән читтә, ят мохитта гомер кичерсә дә, башка культуралар йогынтысына бирешми, милли рухны саклап яши. Туган телен өйрәнү өчен мөмкинлекләр эзли.

«Alima Academy» онлайн-мәктәбе җитәкчесе Алимә Сәләхетдинова әйтүенчә, бирудә төрле илләрдә яшәүче 80 милләттәшебез белем ала, дүртбиш яшьлек балалар да, аларның әти-әниләре дә укый. Татар теле, татар әдәбияты, татар тарихы, татар телендә математика, программалау, мантыйк (логика) дәресләре үткәрелә. Моннан тыш, яшь әниләр өчен балаларны бишектән алып биш яшькә кадәр үстерү юнәлеше бар, өлкән буын өчен әдәбият клубы эшли.

### Атнага бер дәрес үткәреп кенә татар телен өйрәтеп булмый

Гөлчәчәк Вәлиеваның укучылары арасында Алмания (Германия), Финляндия, Согуд Гарәбстаны, Америка Кушма Штатлары, Казахстанда яшәүче балалар бар. Узган ел – өч, быел дүрт төркем укыта. Бер кыз бала белән индивидуаль рәвештә эш алып барыла.

– Татар телен өйрәнә башлаганда Соня исемле кызга нибары дүрт яшь иде. Ул Америкада яши, әнисе рус, әтисе татар, өйдә русча сөйләшәләр, – ди Гөлчәчәк Факил кызы. – Беренче дәрестә татарча түгел, русча да бер сүз әйтмәде. Бары тик «әйе», «юк» дигәнне аңлатып, башын гына селкеде. Икенче дәрестә инде, шөкер, берике сүз әйтте. Иң мөһиме – беренче дәрестән үк бала белән контакт

урнаштыру, үзеңне яраттыру, аның игътибарын җәлеп итү, кызыксындыру юлларын табу кирәк иде. Без шулай кояш рәсеме ясап утырдык. Аннан соң әкрен-әкрен генә русча сөйләштерә, татар сүзләрен әйтә башладым. Ә хәзер инде ул үткән темалар буенча сорауларга матур итеп татарча җавап бирә. Әлбәттә, атнасына бер тапкыр утыз минут (ә мәктәпкәчә яшьтәге балаларда дәресләр 30ар минут кына) дәрес үткәреп кенә татар телен өйрәтеп булмый. Гаиләдә телне кулланырга кирәк. Бу очракта кызның әтисе ярдәмгә килде. Ул татарча белә, дәресләрне бергә карыйлар. Соня туган телен өйрәнсен өчен әтисе бик тырыша, мәсәлән, иртәнге аш вакытында алар татарча гына сөйләшәләр. Кызның уңышларына мин сөенәм.



## Рус сүзләре кулланмаска

Гөлчәчәк ханым укыткан төркемнәрдә Казанда яшәүче балалар да белем ала. Алар күрәләр: чит илдәге яшьтәшләре татарча сөйләшергә тырыша. Сабакташлар үзара татарча аралаша, фикер уртаклаша. Бу да туган телне өйрәнүгә бер этәргеч булып тора.

– Мәсәлән, АКШтагы укучылар инглиз һәм татар телен генә белә, Алманиядәгеләр – немец һәм татар телен. Иң кызыгы менә шушында – Россиядә яшәүче татарлар туган телләрендә аралашканда кайбер сүзне онытып җибәрсә, тиз генә русча әйтеп куя, барысы да барысын да аңлый. Ә чит илдәгеләргә русча әйтеп булмый бит, алар русча белми. Менә шунда инде бала башында булган бөтен сүзләрен «актара» башлый, кирәкле сүзне ничек тә әйтә, – дип аңлата мөгаллимә. – Россиядән күчеп киткән ата-аналар рус телен үзләре яхшы белсә дә, дәрестә рус сүзләрен куллануны хупламый. Шуңа күрә аңлашылмаган сүзләрне инглиз теленә тәрҗемә итәм, гәрчә кайбер укучылар русча да белсә дә. Дәресләргә әзерләнгәндә алдан ук кайбер төшенчәләрнең инглиз телендә әйтелешен кабатлыйм, транскрипциясен язам. Хәзерге заман балаларына таныш булмаган сүзләргә игътибарны юнәлтәм. Әйтик, «Татар йорты» темасын өйрәнгәндә «мич» сүзен инглиз теленә тәрҗемә итәм, рәсем әзерлим. Шулай ук төс, сан, атна көннәрен өйрәнгәндә инглиз телен белү ярдәм итә. Аллаһыга шөкер, инглиз телендә аңлату өчен институтта өйрәнгән белемем җитә.

## Теләгән кеше әмәлен табар

Татар телен онлайн укыту өчен дә, үзлегеңнән өйрәнү өчен дә барлык мөмкинлекләр бар хәзер, дип саный мөгаллимә.

– Бу өлкәдә Рашат Якупов җитәкчелегендәге проектны аерым билгеләп үтәсем килә, – ди ул. – Аның «Сәлам!» (http://selam.tatar) дәреслекләрен кулланам. Өч ел элек, мин эшли башлаганда, дәреслекләр башлангыч мәктәптә укучылар өчен генә бар иде, ә хәзер 9нчы сыйныфка кадәр бар, 10-11нче сыйныфлар да әзерләнү этабында. Дәреслекләр, эш дәфтәрләре, интерактив уеннар, видео-аудио язмалар бик кызыклы, балалар игътибарын җәлеп итә торган. Укытучылар



өчен методик кулланма, реаль укучылар катнашында төшерелгән видеоматериаллар, сюжетлар бар. Һәр темага туры китереп җырлар да тупланган, аларны караоке форматында башкарып була.

«СалаваТIK», «Әйдә! Onlain» проектлары бар, аларны да дәресләргә әзерләнгәндә кулланып була, – дип уртаклаша Гөлчәчәк ханым. – Татар телендәге логоритмик җырлар, шигырьләр дәресне төрлеләндерергә ярдәм итә, балалар бик кызыксынып шөгыльләнә. Диафильм формасында эшләнгән әкиятләрне balarf.ru сайтында карап була. Диктор тавышын туктатсаң, экранда текст һәм рәсем генә калачак. Эчтәлеге буенча онлайн тест үтәргә мөмкинлек бар. Эти-әниләр үзләре дә балалары белән бергәләп әлеге сайтлардан файдалана алалар.

## Оясында ни күрсә…

Туган телнең кирәклеген балага ата-ана аңлата, дигән фикердә Гөлчәчәк Вәлиева. Алар балаларын акча түләп укыта, шул ук вакытта: «Без бирдек – сез өйрәтегез» - дип карамый. Татар телен белү кирәклеген аңлый, балаларына да шуны төшендерә. Эти-әниләр укыту ысуллары белән кызыксына, дәресләрне карый, еш кына: «Үзебез дә бүген яңа сүзләр өйрәндек», – дип әйтәләр. Әкренләп өйдә дә балалары белән татар телендә сөйләшә башлыйлар.

Гаиләдә тел кулланылмаса, укучының да өйрәнү теләге кими. Әйе, ул дәрестә утыра, укытучы әйткән сүзләрне кабатлый, күзләрендә кызыксыну очкыны да булырга мөмкин. Ләкин нинди генә тырыш, гыйлемле укытучы булса да, нинди генә шәп сайтлар эшләсә дә, гаиләдән килмәсә, телне куллану ихтыяҗы булмаса, аны мәҗбүри өйрәтеп булмый.

## Тәкъдим булгач – ихтыяҗ туа

Гөлчәчәк Факил кызы Мәскәү өлкәсендәге балалар үзәгендә офлайн форматта да дәресләр үткәрә.

– Балалар үзәгендә татар теле түгәрәге идеясы туды. Бу дәресләр ачылгач, ихтыяҗ да барлыкка килә, – ди ул. – Моңарчы татар теле турында уйламаган да мәскәүлеләр, якында гына шушындый мөмкинлек ачылганын белгәч, безгә килделәр. Төркемдә рус балалары да бар. Әйтик, бер гаиләдә әбиләре татар булган (әтисе ягыннан), шуңа гаилә башлыгы балаларына да татар телен өйрәтергә тели. Ул кызын да, улын да безгә укырга алып килде. Ана телен өйрәнергә теләүчеләрнең саны артып тора.

Татар теле укытучысы буларак, мин үз хезмәтемнең кирәклеген тоям, – ди Гөлчәчәк Вәлиева. – Белемем бар, эшләргә теләгем, дәртем бар. Татар телен өйрәнү өчен барлык шартлар да тудырылган, бу мине канатландыра.

Ерактагы кояш яктырак, диләр бит. Татарстаннан читтә торучы милләттәшләребез туган телне саклап, ата-бабаларыбыздан калган рухи мирасны киләчәк буынга тапшырырга тырышып яши. Татар теле, Татарстаннан ерагайган саен, кадерлерәк була түгелме?

*Фото Гөлчәчәк Вәлиева архивыннан.*

# “Туган телеңдә бер генә сүз дә белмичә, мин – татар, дип күкрәк сугып йөрү дөрес түгел, дип саныйм”



***Самарның “Яктылык” мәктәбенә быел 25 ел тулды. Әмма әлеге уку йортының тарихы чирек гасыр белән генә чикләнми, аның чишмә башы 1989 елга барып тоташа.***

***Миләүшә Газимова.***

Эш шунда ки, башта шәһәребезнең 12 санлы кичке мәктәбендә татар якшәмбе мәктәбе ачыла. Ә 1992 елда уку йортында беренче татар сыйныфы булдырыла. 1997 елда исә мәктәп, янәшәдә урнашкан балалар бакчасы бинасына күчерелеп, “Яктылык” барлыкка килә.

Хезмәт юлын 1984 елда 12 санлы кичке мәктәптә башлап җибәргән укытучы - Госман кызы Асия Сәйфетдинова бүгенге көнгә кадәр “Яктылык”та эшли.

Үз вакытында биология фәнен һәм әхлак дәресләрен алып бара ул, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары була. Ә бүгенге көндә мәктәптә “Мирас” этнографик музеен җитәкли һәм укучыларга әхлак кагыйдәләрен сеңдерә, хезмәт дәресләрендә үзләрен кул эшләре осталыгына өйрәтә.

Асия ханым Россия Федерациясенең гомуми белем өлкәсендәге мактаулы хезмәткәре исеменә лаек булган, Татарстан Республикасының “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесе һәм “Мактаулы остаз” билгесе белән бүләкләнгән.

Асия Сәйфетдинова балаларда ана телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, халкыбызга карата мәхәббәт, милли әхлак тәрбияләү, аларның милли үзаңын үстерү юлында армый-талмый, бар көчен, күңелен биреп эшли. Бу хезмәткә зур өлеш кертүче шәхес ул.



Тәҗрибәле мөгаллимәдән телебезгә, милләтебезгә кагылышлы фикерләре белән кызыксындык.

***- Асия апа, сез әдәп-әхлак дәресләрен алып барасыз. Балалар өчен бу никадәр мөһим? Укучылар сабакны теләп үзләштерәләрме?***

- Бу дәресләрне әле 12нче кичке мәктәптә мөдиребез Хәридә Дашкина керткән иде. Ул вакытта алар җиденчедән алып унберенче сыйныфка кадәр укытылды.

Ә инде 1997 елда уку йортыбыз янәшәдә урнашкан балалар бакчасы бинасына күчерелеп, “Яктылык” мәктәбе барлыкка килгәч, әдәп-әхлак дәресләре өченче класстан алып барылды. Хәзер бит инде бишенче сыйныфта гына калды.

Балалар сабакны яратып үзләштерәләр. Ник дисәгез, дәресләрдә без мәкаль-әйтемнәрнең мәгънәләрен чишәбез, тормыштагы төрле хәлләрне нигез итеп алып, шулар буенча фикер алышабыз.

Өлкән сыйныфларда гаилә темасына зур игътибар бирә идем. Әйтик, укучыларны парлап утыртам да үзләренә: “Күз алдыгызга китерегез, мәсәлән, сез ир белән хатын, ди. Балагыз сездән дискотекага барырга сорый. Бу очракта нишлисез?” – дигән сорау бирәм. Башка парга икенче төрле хәлне тасвирлыйм. Һәм инде монда сүз

көрәштерү тотына. Аннары, барлык фикерләрне тыңлагач, бөтен класс белән бергәләп йомгак ясыйбыз.

Татар халкының элеккеге еллардагы тормышына да кай-



тып киләбез. Укучыларга: “Менә хәзерге заманда гаиләдә бик еш ачуланышалар, низаглар килеп чыга. Ә ул чакларда тел яшергәннәр, ягъни каршы сүз дәшү уйларында да булмаган”, - дим. Алар: “Апа, ничек инде алай?!” – дип гаҗәпләнәләр. Мин исә: “Элек гаиләдә 5-6ар гына түгел, ә 10-11әр бала тәрбияләгәннәр. Олы уллары өйләнеп, йортка киленнәр төшкән. Кеше саны күбәйгән. Ә хәзер күз алдына китерегез – һәрберсе әрләшсә, тавыш күтәрсә, нәрсә булыр иде?! Тел яшерү гаиләдә тынычлыкны саклар өчен кирәк ул”, – дим. Моңа каршы балалар уйланып торалар да килешәләр.

Гомумән, укучылар барысын да зур кызыксыну белән тыңлыйлар.

Әле укытып чыгарган укучыларым да, күрешкәч: “Апа, әхлак дәресләрендә шундый-шундый хәлләр турында фикер алыша идек. Хәзер тормышта шулар барлыкка килә бит. Һәм ул вакытта алган сабак безгә бик ярдәм итә. Рәхмәт сезгә”, - диләр.

Кемдер мин үземдә шушындый сыйфат, мондый сыйфат тәрбияләдем, ди. Укучылар өчен әдәп-әхлак дәресләре бик мөһим, дип әйтәсем килә.

Аннары мин бу дәресләрдә балаларны татар теленә дә өйрәтергә тырышам. Тактада те-



маны, терәк сүзләрне ике телдә язып куям. Русча сөйләсәм, шунда ук татарчага тәрҗемә итәм. Татар телендә аңлатсам, кыскача русчага күчерәм. Һәрвакыт татарча гына сөйләп булмый шул, чөнки балаларның күбесе ана телен бик яхшы белмиләр.

***- Сезнеңчә, мәктәп кысаларында гына татар телен үзләштереп буламы әллә монда гаиләнең роле зурмы?***

- “Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми”, - диләр бит. Хак сүзләр бу! Татар телен өйрәтүне гаиләдән башларга кирәк. Әбибабайдан, эти-әнидән. Алар татарча аралашса, балалары да ана телендә сөйләшәчәкләр.

Татар телендә бишек җырларын көйләп, яңа туган сабыйга ана телендә эндәшеп, кечкенә чакларыннан әкиятләр, шигырьләр укып, нарасыйларда туган телебезгә мәхәббәт тудырырга кирәк. “Тел - ананың теләге, тел – ананың баласына иң кадерле бүләге”, - дип бик дөрес әйткән халкыбыз.

Гаиләдә ана теле яңгырамый икән, балалар аны белмәячәкләр һәм татар телен мәктәп кысаларында гына үзләштерә алмаячаклар. Биредә алар белемнәрен үстерергә, камилләштерергә генә мөмкиннәр.

Менә бер мисал китерәсем килә. Татар милли хәрәкәтенең ветераны Рәшит Абдулловны күпләр белә, дип уйлыйм. Аның кызы “Яктылык”ка беренче сыйныфка килгәндә инде шартлатып татарча сөйли иде! Әлбәттә, мәктәптә татар теле дәресләрендә ул үзе өчен яңа сүзләр ача, әмма аңа инде аларны үзләштерүе күпкә җиңелрәк.

Музей эшендә катнашучы укучыларым арасында да татар телендә бик яхшы сөйләшүчеләр бар. Бу – аларның ата-аналары, әби-бабайлары тәрбиясенең нәтиҗәсе.

Татар теле туган телебез булса да, кызганыч ки, күп эти-әниләр нарасыйлары белән бары тик русча аралашалар.

Кайберәүләрдән: “Балам белән татар телен өйрәнеп утырырга вакытым юк минем!” – дигән сүзләр ишеткәнем бар. Ә, әйтик, безгә эти-әниләребез ана телен махсус өйрәтеп утырдылармы соң? Юк, әлбәттә! Гаиләдә һәрвакыт бары тик туган телебез яңгырады. Шуңа күрә без аны сабый чактан каныбызга сеңдереп үстек.

Аннары мин вакыт тапмаучы андый эти-әниләргә шуны әйтер идем – ашарга пешергәндә дә, өй җыештырганда да балаң белән татарча сөйләшергә була ләбаса! Син аңа сораулар бир, ул сиңа җавап кайтарсын.



Гаиләндә рәхәтләнеп туган телеңдә сөйләшеп, татар бәйрәмнәрен билгеләп, татар ризыклары белән кунакларны каршы алып яшәүгә ни тора соң! Бу бит – безнең әби-бабайлардан, эти-әниләрдән калган мирас. Алар, зур авырлыклар аша узып та, үз телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен саклап килгәннәр. Безгә алардан үрнәк аласы да үз балаларыбызга шушы мирасны тапшырып калдырасы иде дә бит...

***- Ә менә кайбер ата-аналар үзләре ана телендә бик яхшы сөйләшәләр, әмма балалары татарча бер сүз белми. Моны ничек аңларга була?***



- Бала белән аралашырга кирәк бит. Ир белән хатын үзара гына татарча сөйләшеп, нарасый ана теленә өйрәнә алмый ул.

Аннары баланың кызыксынуларын күздә тотарга кирәк. Шул вакытта аның белән уртак тел табарга һәм татарча шул темаларга аралашырга була.

Мәктәпкә: “Балам, үзеңне яхшы тот, укытучыга каршы сүз әйтмә”, - дип ана телендә озатып калырга. “Көнең ничек үтте? Нинди билгеләр алдың, нинди яңалыклар алып кайттың?” – дип каршы алырга.

Тел мохитын булдыру мөһим, практика кирәк.

***- Сез “Яктылык”та “Мирас” музеен җитәклисез. Балалар тарихыбыз, гореф-гадәтләребез белән кызыксынамы? Эш барышында аларга татар телендә сөйлисезме?***

- Кызыксыналар. Һәр экспонатны рус һәм татар телендә тасвирлыйбыз без. Мәсәлән, тукыма ничек, ни өчен ясалган, аңа нинди бизәкләр төшерелгән.

Исем кушу, никах, каз өмәсе, яңгыр теләү һәм башка татар милли йолалары турындагы мәгълүматны яратып тыңлыйлар. Боларны да татар телендә сөйлим. Аңлап бетермәсәләр, русчага тәрҗемә итәм.

Укучылар белән Мәчәләй, Тупли, Байтуган, Гали авылларына этнографик экспедицияләргә барып, экспонатлар җыя идек. Музей эше барышында туплаган белемнәрен балалар аннары нииндидер предметлар буенча фәнни эшләр язганда да кулланалар.

Хезмәт дәресләрендә, әйтик, кызларны чигү чигәргә өйрәткәндә, аларны башта бу кул эшенең тарихы белән таныштырып үтәм. Элек кызлар, кич утырып, чигү чиккәннәр, сөйгән ярларына чиккән кулъяулыклар бүләк иткәннәр, дип сөйлим.

Сигезенче сыйныф укучыларына: “Мин сезне кияүгә чыгарга әзерлим. Никах табынындагы кыз чәкчәге кәләш чиккән тастымал белән капланырга тиеш”, - дигәч, әй, тырышып чигәргә тотыналар (елмая).

***- Сез укытып чыгарган укучыларыгызның балалары татарча сөйләшәме?***

- Әйе, шатлыгыбызга, андыйлар бар. Әйтик, мәктәпне 2002 елда тәмамлаган укучыларым үзләре дә татар телен яхшы беләләр, балалары да, шөкер, авыз тутырып татарча аралаша.

"Яктылык"ны 1994 елда тәмамлаган Гөлнара күптән түгел кызын кияүгә бирде, мине никахка чакырдылар. Татар егетенә чыкты. Үзе дә, ире дә бик матур итеп татарча сөйләшәләр.

Укытучыбыз Изидә Хуҗинаның кызлары - Алсу белән Румия нарасыйларында туган телебезгә



мәхәббәт тәрбияләп үстерәләр. Балалары үзләренә урысча берәр сүз әйтсә: "Бәбкәм, мин сине аңламыйм бит", - дип җавап кайтаралар.

Боларның барысы да – безнең өчен зур сөенеч, әлбәттә.

***- Асия апа, ә үзегез бала-оныкларыгыза татар телен өйрәтә алдыгызмы?***

- Аллаһыга шөкер, улым Йосыфны үстергәндә аның белән татарча аралаштым. "Сәләт" лагерына йөрүе дә ярдәм итте. Ә, өйләнгәч, ул телне тагын да камилләштерә төште, чөнки киленем Юлия татарча бик яхшы сөйләшә.

Өч оныгым ана телен бик теләп өйрәнәләр, шөкер. Интернеттан да үзләре өчен яңа сүзләр үзләштерәләр. Әлегә бик шома булмаса да, татарча сөйләшергә тырышалар.

***- Сезнеңчә, татар теленең киләчәге бармы? "Тел бетсә – милләт бетә", дигән сүзләр белән килешәсезме?***

- Әгәр дә менә мин алда әйтеп үткән укучыларымдай һәр әти-әни үз балаларына бишектән үк ана теленә мәхәббәт тәрбияли башласа, үзләренә сабый чактан татар



телен өйрәтсә, кечкенәдән гореф-гадәтләребезнең әһәмиятлелеген аңлатса, динебезгә ихтирам сеңдерсә, һәр татар кешесе милли үзаңын үстерү өстендә эшләсә, катнаш никахлар булмаса, "әйе", дип төгәл җавап бирә алыр идем дә бит.

Әмма бүген үзен татар, дип йөрүчеләрнең күпмесе ана телендә сөйләшә соң? Күпме оныкларыбыз әби-бабасын аңлый? Күпме бала әби-бабаларыбыз, зур авырлыклар аша үтеп, безнең өчен саклап килгән, безгә мирас итеп калдырган газиз ана телебез – татар телендә укый?

Инде алдан әйткәнемчә, "Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән керми" ул. Һәм, кеше татарча сөйләшсен өчен, ана теле аңа кечкенәдән гаиләдә өйрәтелергә тиеш! Мәктәпкә ул килә дә китә. Вакытының күбрәк өлеше өйдә, әти-әни янында уза. Һәм аның белән һәрвакыт татарча аралашырга кирәк.

Менә мисалга таҗик, үзбәк, кыргызларны алыйк. Балалары үз телләрен камил беләләр. Ә бит әлеге милләтләрнең ана телен өйрәтә торган бакчалары да, мәктәпләре дә юк! Әти-әни хезмәте бу – бишектән сабыйларына ана телендә сөйлиләр, гаиләдә бары тик туган тел яңгырый.

Уйлап карагыз – милли үзаңнары нинди көчле аларның, үз менталитетлары бар! Үз телләрен, милләтләрен ничек яраталар. Ә безнең халык яратырлык, горурланырлык түгелмени?!

Мин укучыларыма да: "Ана телеңне белү – зур байлык ул. Хәтерегез дә, логик фикерләү сәләтегез дә шуннан үсеш ала. Үз телен белмәгән кеше башка телләрнең матурлыгын да тулысынча күреп бетерә алмый.

Безнең татар теле – бик бай, аһәңле тел. Кайбер сүзләрне, гыйбарәләрне хәтта русчага тәрҗемә итеп тә булмый, чөнки аларның эчтәлеген, мәгънәсен тулы күләмдә тапшыру мөмкин түгел", - дип әйтеп киләм.

"Тел бетсә, милләт бетә", дигән сүзләр белән, һичшиксез, килешәм! Тел – халыкның иң беренче күрсәткече ул. Туган телеңдә бер генә сүз дә белмичә, мин – татар, дип күкрәк сугып йөрү дөрес түгел, дип саныйм. Татар булсаң, үз телеңне бел, өйрән син. "Ана телен оныткан – анасын да оныткан" , дигән тирән мәгънәле сүзләр әйткән татар язучысы Шәүкәт Галиев.

Барысы да – үзебезнең кулда. Безгә әллә кем килеп ярдәм итә алмый, булышырга тиеш тә түгел. Телебезнең, милләтебезнең киләчәге бары тик үзебездән, һәр татар кешесеннән тора!

# Үз гомеренә балаларда ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләгән мөгаллимә

***«Мөгаллимә хезмәтен балаларны чын күңелдән яратучы, алар белән уртак тел таба белүче, үзләрен бертигез күрүче кешеләр генә башкара ала", - ди Похвистнево районының Гали авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән Зөлфим Нәзахетдин кызы Аслгәрәева.***

***Миләүшә Газимова***



44 ел буена ул балаларда ана телебезгә мәхәббәт тәрбияли, аның матур, аһәңле булуын күрсәтә, ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген төшендерә.

Зөлфим ханым Оренбург өлкәсенең Северный районындагы Бакай авылында туып-үскән. Унынчы сыйныфны тәмамлагач, Оренбург шәһәренә китеп, анда бер ел заводта эшләгән. Аннары тормыш җилләре аны Гали авылына алып килгән. Татар телен бик яхшы белгән милләттәшебезгә биредә мәктәпкә урнашырга тәкъдим иткәннәр.

- Эшкә кергәч тә, читтән торып, Казан педагогика институтында белем ала башладым.

Мәктәптә дә туган телебезне бик яратып үзләштердем, гел “яхшы” билгеләр генә ала идем. Авылыбыз китапханәсендә мин укымаган татарча китаплар калмады. Бу әдәби телне тагын да камилләштерергә ярдәм итте. Шуңа күрә институтта уку да бик җиңел бирелде миңа.

Кечкенәдән туган телебезне сөеп үстем һәм, укучыларымда да ана теленә шушындый зур мәхәббәт тәрбияләр өчен, зур тырышлык куеп эшләдем.

Баштагы мәлләрдә татар телен атнасына алтышар сәгать укыттык. Тора-бара дүрт, соңрак өч сәгать кенә калдырдылар. Ә аннары, гомумән, моңа ике сәгать кенә бирелде. Балага татар телен тиешле дәрәҗәдә өйрәтер өчен, бу әлбәттә, бик аз.



Авылыбызда балалар бакчасы күптән түгел генә эшли башлады. Моңа кадәр нарасыйлар күршедә урнашкан Ырсай чуваш авылына йөрделәр. Анда инде телләре, билгеле, русча ачылды. Башлангыч сыйныфларда да татар теле дәресләренә сәгать әз каралган. Шуңа күрә соңгы елларда укыту кыенрак булды шул. Ә бүгенге көндә укытучыга тагын да авыррак, чөнки хәзер авыл балалары да рус теленә күчеп бара, - дип сөйли Зөлфим апа.

***- Моның сәбәбен нидән күрәсез?*** – дип кызыксындым аңардан.

- Кызганычка, күп ата-аналар нарасыйлары белән русча аралашалар. Ә өйдә ана теле яңгырамый икән, бала аңарда сөйләшмәячәк. Гаиләдән башларга кирәк! Әбибабайдан, әти-әнидән.

Менә без “Ак калфак” оешмабызның җитәкчесе Кәүсәрия Шәйхетдинова белән балалар бакчасына кергәләп йөрдек. Малайлар-кызларны әз генә булса да татар теленә өйрәтергә теләү





ниятеннән бу. Балаларның күбесе татарча унга кадәр дә саный белми. Калганын инде әйтеп тә торасы юк. Шуларны күреп, йөрәк әрни.

Быел бу эшне ныклап оештырырга дип торабыз.

Әгәр дә яшь буыныбыз туган телен белмәсә, милләтебезнең киләчәге булырмы икән?! Миңа шунысы куркыныч бит. Ата-бабаларыбыз кадерләп саклаган һәм безгә әманәт итеп калдырган мирасыбызны югалту җинаятькә тиң ул!

***- Ә сез мәктәптә эшләгән елларда укучылар ана телен теләп үзләштерәләр идеме?***

- Ул чакта да төрлесе булды. Әмма күбесе татар теле дәресләрен бик ярataлар иде. Мин укытып чыгарган укучыларым һәр елны туган көнемә миңа кунакка җыелалар. Араларында чуваш егете дә бар. Безнең телне бик яхшы белә. Мин мәктәптә оештырып җитәкләгән театр түгәрәгенә йөрде ул. “И, апа, ул елларны шулхәтле юксынам. Сәхнәгә менәр идем дә рәхәтләнеп татарча спектакль уйнар идем!” – ди. Һәм, шатлыкка, шундый укучыларым күп.

Татар теле буенча олимпиадаларда да бик теләп катнашалар иде алар, гел призлы урыннар яулап килделәр.

***- Балаларда ана теленә мәхәббәт тәрбияләр өчен нинди ысуллар кулландыгыз?***

- Моның өчен дәрестән тыш күп чаралар үткәрдем. Әйткәнемчә, театр түгәрәген булдырдым. Спектакльләр белән төрле бәйгеләрдә катнашып, җиңүче исемнәренә лаек булдык.

“Шатлык” дип аталган балалар җыр төркемен дә оештырып җитәкләдем.

Ул вакытларда математика укытучысы булып эшләгән Кәүсәрия Шәйхетдинова белән һәр елны “Туган як укулары” конкурсын үткәрә идек. Укучылар гаиләләре, әби-бабайлары, авыл, мәктәп, укытучылар турында иншалар яза, шәҗәрәләрен төзиләр иде.

Призлы урыннар алган нарасыйларны экскурсияләргә алып бара идек. Үзләрен йөртмәгән җиребез калмады – Арча, Мостафа, Болгар, Казан... Мәрхүм Расих Латыйповка рәхмәт, матди ярдәмен күрсәтеп торды.

Төрле төбәкләрдә үткәрелгән чараларда балалар белән гел катнашып килдек без.

Һәр елны Муса Җәлил, Габдулла Тукайның туган көннәренә багышланган шигъърият бәйгеләрен үткәрмичә калмадым. Балалар сәхнәдән бөек шагыйрьләребез иҗат иткән шигырьләрне яратып сөйлиләр иде.

Даими рәвештә татар теле атналыклары уздырып килдем – КВН, башка төрле кызыклы бәйгеләр оештырдым, иншалар яздырдым.

Гомумән, укучыларымда булган сәләтләрне күреп алып, аларны ачарга, үстерергә тырыштым. Әмма талантлары булмаганнарны да бервакытта да читтә калдырмадым. Булдырамы-юкмы, татарча яхшы сөйлиме-юкмы – сәхнәгә чыгардым. Чөнки бу аларда ана теленә сөю, кызыксыну уятыр өчен яхшы чара иде.

Татар теле дәресләреннән күңелләре кайтмасын дип, беркайчан да “икеле” билгеләре куймадым.

***- Ата-аналар белән мөнәсәбәтләрегез ничек иде? Аларның ярдәмен тоеп эшләдегезме?***

- Әти-әниләр бик яхшы булдылар, Аллаһыга шөкер. Уку-укыту процессында да, чаралар оештыруда да бик нык ярдәм итәләр иде. Беркайчан да бәхәскә кермәдек, бер-беребезне аңлап эш иттек. Бүген дә алар миңа хөрмәт күрсәтеп яшиләр, шалтыратып туган көнем, бәйрәмнәр белән тәбриклиләр, хәлләремне беләләр, һәрвакыт булышырга әзер торалар, үзләренә рәхмәт яугыры.

***- Ә сез укучыларыгызны сагынасызмы, аларның язмышлары белән кызыксынасызмы?***

- Әйе, сагынам. Аларның һәрберсе күз алдымда тора. Кайда эшлиләр, ничек яшиләр, ничә балалары – барысы белән дә кызыксынам, сорашып торам. Үзләре дә гел шалтыратып, хәлләремне беләләр, бәйрәмнәр белән котлыйлар, күрешергә киләләр. Озаклап сөйләшеп утырабыз, мәктәп елларын искә төшерәбез.

***- Мөгаллимә – ул тәрбияче дә бит әле. Балаларга нинди үгет-нәсыйхәтләр биреп укыттыгыз?***

- Әти-әниләрегезне, олыларны хөрмәт итегез, тәртипле булыгыз, хезмәтне яратыгыз, бозык юлга басмагыз, дип гел әйтеп килдем үзләренә. Аллаһыга шөкер, укучыларым акыллы, тәртиплеләр, лаеклы кешеләр булып үстеләр. Төрле тармакларда эшлиләр. Бу – минем өчен олуг шатлык.

***- Тәҗрибәле укытучы була-***






***рак, бу эшкә яңа гына керешкән яшьләргә нинди киңәшләр бирер идегез?***

- Мөгаллим – иң хөрмәтле һөнәрләрнең берсе ул, баладан кеше ясый, тәрбияли. Дәрәҗәле хезмәтләрен яратып, бөтен күңелләрен биреп, тырышып, җиренә җиткереп башкарсыннар иде. Балаларга карата игътибарлы булсыннар.

Үзләреннән олырак, остарак укытучылар белән элемтәдә торып, аларның киңәшләренә, нәсыйхәтләренә колак салып эшләргә киңәш итәр идем.

***- Укытучы – тынгысыз җан бит инде ул. Менә сез дә, дүрт ел элек лаеклы ялга чыккан булсагыз да, өйдә тик утырмыйсыз. Авылыгызның “Мирас” фольклор төркемен җитәклисез икән.***

- Мин аның эшчәнлегендә бик күптән катнашам инде. Ә өч ел элек әлеге коллективны җитәкләдем. Төркемебез сигез кешедән тора. Барысы да – укытучылар.

Аллаһыга шөкер, төрледән-төрле чараларда катнашып киләбез. Менә быел гына да Курган өлкәсендә үткәрелгән бәйгедә “Каз өмәсе” йоласы белән катнашып, беренче урын яуладык. Ә “Бишек җыры”быз өчен Гран-прига ия булдык.

Самарда узган “Мирас” фестивалендә дә беренче урынга чыктык. Өлкә Сабан туенда зур концерт программасы белән чыгыш ясадык.

Авылыбызда “Халкым минем” конкурсы булып үтте. Анда “Киез кату” йоласын күрсәтеп, шулай ук беренче урын алдык.

Быел Туймазыда Русия халыкларының мәдәни мирасы елы уңаеннан Башкортостан республикасы төбәк иҗтимагый оешмасының 25 еллыгына багышланган үзешчән татар фольклор ансамбльләре арасында “Җырлыйк әле!” дип аталган фестиваль-конкурс уздырылды. Безгә анда да үз осталыгыбызны күрсәтергә насыйп булды. Диплом алып кайттык.

Барлык сценарийларны да үзем язам.

Менә октябрь аенда авылдашыбыз Суфия Сәлимованың оныгы туарга тиеш, Аллаһы бирсә. Шул уңайдан “Бәби туу” йоласын үткәрергә ниятлибез.

Иганәчеләребезгә мең рәхмәт. Костюмнар тектерергә матди ярдәм күрсәтәләр. Менә әле Казанда яшәүче авылдашыбыз Дания Тулова кыйммәтле тукымалар алып җибәргән. Алардан тегүчебез Флюра ханым Низамова күлмәкләр тегеп маташа.

***- Зөлфим апа, гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде.***

- Мин – тол хатын. Кызганыч ки, хәләл җефетем Гобәйдулла 16 ел элек вафат булды. Бик әйбәт кеше иде. Бер-беребезне хөрмәт итеп, балаларны бергә тәрбияләп яшәдек без. Ул исән чакта миңа шундый җиңел, рәхәт иде. Барлык хуҗалык эшләрен ирем башкарды, үзе дә чиста-пөхтә иде, йортыбызны да гел тәртиптә тотты.

Кызыбыз Ләйсән, юридик институтны тәмамлап, Похвистнево шәһәрендә үз һөнәре буенча хезмәт итә.

Улыбыз Ильдар авылыбызда колбаса ясау цехында эшли.

***- Тормышта кемнәргә таянып яшисез?***

- Газиз балаларым – ышанычлы терәгем һәм таянычым.

Бакайда гомер итүче апам, Иске Усманда торучы сеңелем белән бер-беребезне яратып, ярдәмләшеп, аралашып яшибез. Туганлык җепләре нык безнең, Аллаһыга шөкер.

“Мирас” төркемендәге дусларым белән бер гаиләдәй тату без. Күңелле итеп, бер-беребезгә булышып эшлибез.

Авылдашларым да бик яхшы. Авыр вакытларда да, шатлыклы чакларда да гел бергә.

***- Үзегезне бәхетле кеше, дип әйтә аласызмы?***

- Бик бәхетле мин, иркәм, Раббыбызга мең шөкер. Яратып кияүгә чыктым, ирем белән яхшы тормыш алып бардык.

Әлхәмдүлилләһ, кызым да, улым да тәртипле, тәүфыйклы булып үстеләр. Тырышалар, дөнья көтәләр. Кияү-киленемнән дә уңдым. Биш яшьлек оныгым, күз нурым Алинә ямь өстенә ямь өсти.

Гомерем буе яраткан хезмәтемне башкардым. Мәктәптә эшләгән елларымны бик сагынам. Укучыларым бүген дә мине онытмыйлар, рәхмәтләрен белдерәләр, димәк, мөгаллимә хезмәтен юкка гына башкармаганмын.



# КЕШЕДӘГЕ БАР БУЛГАН СЫЙФАТЛАР ГАИЛӘДӘ ТӘРБИЯЛӘНӘ

*Тормыш үрнәкләре күрсәтеп яшәгән, уңган һәм изге җанлы кешеләрнең истәлеге халык күңелендә озак саклана. Аларның балаларында, оныкларында да андый матур сыйфатлар буыннан-буынга бирелеп килә. Бу исәптән Кошки районының Иске Фәйзулла авылында яшәгән Сәмигулла абзый һәм Хөснелбанат апа Латыйпов-Юзеевлар корган гаиләне мисалга китерергә була.*

*Фәрид Ширияздaнов*

Алар икесе дә авыр һәм эчтәлекле тормыш юлы үткәннәр. Сәмигулла абзый өч сугышта булган: Холхин-Голдагы японнар белән булган бәрелештә, финнар белән һәм, Бөек Ватан сугышында башыннан ахырынача катнашып, Берлинга барып җиткән.

Хөснелбанат апа да - сугыш һәм хезмәт ветераны. Кечкенә генә буйлы һәм чандыр гына булса да, ул, авыр тормыш сынауларын үтеп, эчтәлекле гомер кичергән. Әле буыннары да ныгып бетмәгән килеш, яшүсмер чагында ул хатын-кызлар һәм олы яшьтәге ирләр белән бергә хәрби тоткарлау сызыгы төзүдә катнаша.

1941 елның октябрь аенда хәзерге Самар һәм Ульяновск өлкәсенә кергән җирләрдә, СССР оброна комитеты указы нигезендә, Куйбышев оборона линиясен төзү бурычы куела.

Сугыш башлангач та, Куйбышев шәһәренә бөтен дәүләт органнары, төрле илчелекләр күчерелә. Ул иң әһәмиятле транспорт һәм оборона үзәгенә әверелә. Шуңа күрә, бу юнәлешне дошманнан саклау өчен, Урта Иделнең уң як ярындагы җирләрдә танклар үтә алмаслык өч метр тирәнлектәге һәм сигез метр киңлектәге тоткарлау сызыгы төзелә. Монда Куйбышев өлкәсеннән генә дә 300 меңгә якын кеше катнашырга тиеш була.



С.Ш. Латыйпов (беренче рәт, сулдан беренче)



С.Ш. Латыйпов



Латыйпов С.Ш. (өстәге рәт, сулдан беренче)

Якташлары белән Хөснелбанат апага да бу искиткеч авыр эшләрдә катнашып, өч ай буена нужа чигеп, зур сынаулар аша үтәргә туры килә.

Хәзерге вакытта шул яшүсмер кызларның ач килеш, караңгыдан-караңгыга кадәр туң җирне ломнар белән казуын күз алдына да китерүе авыр. Ә уч төпләре канлы җәрәхәткә әверелеп, төнлә салкын, якмаган өйләрнең идәнендә йоклауларын исәпләсәң - бигрәк тә.

Михнәткә чыдый алмыйча, монда үлүчеләр дә күп була. Хөснелбанат апа аннан исән килеш кайткач та, колхозда аларга элгәреге вакытта ирләр эшләгән авыр эшләрне башкарырга туры килә, чөнки авырлыкларның барысы да яшүсмерләр, хатын-кызлар һәм картлар җилкәсенә төшә.

Сугыштан соң Хөснелбанат һәм Сәмигулла өйләнешәләр. 1936 елда армиягә киткән булса, өч сугыш юллары үтеп, Сәмигулла абзый 1945 елда гына өенә кайта. Сугышта алган яраларга карамастан, ул колхозда тимерче булып эшли. Станоклар, сварка һәм башка җиһазлар, кирәкле материаллар булмаган чорда техниканы ремонтлау ул чакта бар кыенлыгы белән тимерчеләр өстенә төшә.

Сугыштан соңгы авыр вакытта кибетләрдә хуҗалык кирәк-яраклары юклыгы - билгеле хәл. Анда нидер булса да, халыкта аларны алырлык акча булмый. Шул чакта Сәмигулла ага, савыт-саба, өй һәм йорт кирәк-яраклары ясап, искеләрен төзәтеп, авыл халкының төп таянычына әверелә.

Кызганычка, ул озак яши алмый. Монда сугыш яралары да сәбәпче булгандыр. Гомере кыска булса да, кылган изгелекләре өчен халык аны һәрвакытта зурлап,



Улы Әнвәр



Улы Миннеәсхәт



Улы Равил



Улы Рөстәм



Кызлары Люция, Сәвия һәм оныгы Зөлфия



Кызы Халидә



«Бессмертный полк» Рузилә оныгы белән

рәхмәт хисләре белән искә ала иде.

Аларның гаиләсендә туган җиде баланы тәрбияләп үстерү бурычы бөтен авырлыгы белән Хөснелбанат апа җилкәсенә төшә. Ул үз балаларын орышып, кычкырып түгел, йомшак кына, күңел җылысын биреп үстерә һәм, үзләре кебек үк, кешелекле, киң күңелле шәхесләр булырлык итеп тәрбияли ала.

Хөснелбанат апа үз гомеренә авыл халкын үзенең уңганлыгы, эш сөючәнлеге һәм чисталыгы-пөхтәлеге белән дә сокландырып яшәде. Кайчан гына карама, ул, халыкта «Уф Алла арбасы» дип аталган тарантайкасын тартып, утын, печән яисә башка хуҗалык кирәк-яраклары әзерләп йөри торган иде. Тормышны ул шулай, бар куәткә тырышып-тырмашып, тартып-сузып алып бара алды.

Аның йорты да гел чиста, җыйган, бар нәрсә дә тәртиптә булды. Шунда туып-үскән балалары да кешелекле, тыйнак, итагатьле булып яшәделәр һәм яшиләр. Алар үзләренең туган йортын һәрвакытта карап, тәртиптә тоталар һәм һәр елны, әти-әниләренә, туганнарына багышлап, Коръән мәҗлесләре уздыралар. Аларның һәркайсында әти-әниләрендә булган матур кешелеклелек сыйфатлары ачык күренә. Барысы да ачык йөзле, киң күңелле, ярдәмчел, уңганнар.

Ни кызганыч, тик ир туганнарының дүртесе дә вакытсыз вафат булдылар. Шулай да, кайда яшәгән, эшләгән булсалар да, аларны белгән кешеләр үзләрен һәрвакытта олы хөрмәт белән искә алалар.

Олы уллары Әсхәт, Уссолье авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаганнан соң, Кошки районы үзәгендәге автомәктәптә курсантлар укыта.

Равил, Рязань авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаганнан соң, туган авылындагы колхозда гараж мөдире булып эшли. Аннан соң Кошкидагы май-сыр җитештерү заводында инженер булып һәм башка төрле җаваплы урыннарда эшли.

Әнвәр, мәктәпне «яхшы» билгеләргә тәмамлаганнан соң, Рязань авыл хуҗалыгы техникумында укый. Аны уңышлы тәмамлагач, туган авылында гараж һәм һөнәрханә мөдире була. Ә Рөстәм үз гомеренә колхозда тракторист булып эшли.

Ир туганнары инде бакыйлыкка күчкән булсалар да, кызлары исән-саулар һәм әти-әниләре үрнәгендә бәрәкәтле тормыш алып баралар. Халидә Шенталыдагы медучилищене тәмамлый. Аннан соң авыл хуҗалыгы техникумында бухгалтерлыкка укый һәм Тёплый Стан авылында бухгалтер булып эшли.

Сәвия, Подбельск педучилищесын тәмамлап, гел “бишле”ләрдән генә торган диплом ала һәм туган авылында укытучы булып эшли. Ахырда Мәскәүдәге экономика, информатика һәм статистика институтын тәмамлап, Кошкидагы промкомбинатта хезмәт итә.

Кече кызлары Люция Димитровградтагы авыл хуҗалыгы техникумының бухгалтерлар әзерләү бүлеген тәмамлый. Хәзерге көндә ул Тёплый Стан авылындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмасында эшли.

Сәмигулла абзый, Хөснелбанат апа һәм аларның балалары кайда гына булып, кем белән аралашсалар да, алар катнашкан һәр җирдә уңай мөгаләмә, аңлашучанлык урнаша. Кешеләрдәге матур сыйфатларны, алардагы уңай якларны гына күреп, башкалар фикерен һәм сүзен хөрмәт итә белеп аралашканга, аларның үзләренә дә халык лаеклы рәвештә хөрмәт күрсәтә һәм үз итә. Алар үзара да, башкалар белән дә тату, дустанә яшәделәр һәм яшиләр.



# БЕЗ ПРОШЛОГО НАМ НЕ ПОСТРОИТЬ БУДУЩЕГО

***1100 лет назад Волжская Булгария установила ислам как государственную религию на своей территории. Это событие во многом предопределило создание уникальной российской цивилизации, соединяющей традиции Запада и Востока. По распоряжению Президента РФ подготовке к празднованию юбилейной даты был придан общероссийский статус. О том, что эта дата значит для самарских мусульман и какие мероприятия в рамках этого события прошли и планируются в нашем регионе, мы поговорили с председателем попечительского совета культурно-исторического фонда «Булгарское наследие» Гумаром Батршиным.***

*Данияр Сайфиев*

***– Гумар Мулланурович, этот год особенный для мусульманского мира: мы отмечаем 1100-летие принятия ислама Волжской Булгарией. Конечно же, ваш фонд не остается в стороне от этого события…***

– Фонд «Булгарское наследие» с 2008 года ведет большую просветительскую работу по искоренению белых пятен в нашей истории и популяризации темы государства Волжская Булгария. Еще не далеко то время, когда о существовании этого древнейшего государства нельзя было даже говорить, и понятно, что о нем ничего не было ни в школьных, ни в вузовских учебниках. И это несмотря на то, что Волжская Булгария – это неотъемлемая часть истории нашего родного края, Средней Волги, нашей страны. Было государство, сильно развитое, по сравнению с соседними народами. В 922 году в его столицу – город Болгар – прибыло посольство из Багдада, положив начало взаимодействию этого государства с исламским миром. Принятие ислама волжскими булгарами дало мощный толчок развитию в Поволжье культуры, внесшей огромный вклад в общемусульманское наследие в различных отраслях науки, богословия, высокой литературы и искусства. Не случайно, что 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией сегодня придан общефедеральный статус и эта дата масштабно отмечается во многих регионах нашей страны. Я всегда был сторонником того, что история не должна умалчиваться или переписываться в угоду той или иной политической системе. Она или есть, или ее нет. Поэтому наш фонд делает всё возможное для того, чтобы в булгарской тематике не оставалось недоговоренностей, а само изучение истории этого государства было бы интересным для как можно большего количества людей…

***– Что уже удалось сделать в этом направлении и что в планах?***

– Нашим фондом построена мечеть в поселке Зубчаниновка, которая получила название «Булгарское наследие», мы инициировали строительство и установку памятного знака «Летящий барс» на Поповой горе в селе Ширяево, на том самом месте, где находилась примерная граница Волжской Булгарии. Занимаемся изданием исторических книг и созданием документальных фильмов на тему «Булгарская цивилизация». С приходом нового и очень энергичного дирек-





тора фонда Гюзяли Сагадатовой нам удалось ускорить реализацию наших планов. В этом году мы выпустили книгу «Возвращение к истокам» и провели целую серию ее презентаций, которые прошли в форме научно-исторических конференций, участвуем в краеведческих форумах и конференциях, в том числе и с выездом в Татарстан. На днях у стелы «Летящий барс» в Ширяево мы установили памятный знак к 1100-летию принятия ислама Волжской Булгарией, планируем установку информационных щитов, а сейчас проводим работы по благоустройству всей этой территории. Думаю, что совсем скоро там получится достаточно красивый и познавательный комплекс, который органично впишется в туристско-рекреационный кластер нашей области. Ведь только с начала этого года Ширяево посетили более 70 тысяч туристов и дальнейшее развитие этой территории находится под личным контролем нашего губернатора Дмитрия Игоревича Азарова. Место здесь очень красивое. Люди, побывав здесь, унесут с собой не только хорошие впечатления от красот и видов, но еще и знания о татаро-булгарской истории, истории Средней Волги, нашей страны. Все это будет работать на укрепление патриотизма и любви к родному краю. Это очень важно. Особенно для молодежи.

***– Помнится, с установкой стелы «Летящий барс» были многочисленные проблемы. Официальное открытие памятника к 1100-летию принятия ислама вы тоже пока не афишируете. С чем это связано?***

– Действительно, стелу нам пришлось несколько раз переносить. Изначально она была установлена на Монастырской горе. Заставили снести. Потом поставили ее на смотровой площадке, но из-за волокиты с разрешительными документами нам снова пришлось ее сносить. В итоге она был установлена на горе Поповой. Мы же татары – народ упертый: раз что-то решили, значит сделаем (смеется). Что же касается нового памятника, то здесь мы тоже столкнулись с вопросом оформления земли. Дело в том, что весь этот комплекс расположен на территории национального парка «Самарская Лука», что накладывает определенные ограничения на использование этих земель. На сегодняшний день эта проблема решена, но мы немного выбились из запланированных сроков. Нам необходимо сделать тропинку от основного туристического маршрута порядка 200 метров, чтобы прибывающие сюда гости могли чувствовать себя комфортно в любых погодных условиях, сделать площадки ожидания, поставить указатели. Хочется выразить благодарность нашему губернатору за ту помощь, которую он нам оказывает в создании этого комплекса, за то, что у него есть понимание, зачем, почему и для кого мы это делаем.

***– А кому принадлежит идея установки нового памятника и кто выступил его архитектором?***

– С этой инициативой ко мне обратился несколько лет назад наш бывший сотрудник Мансур Усманов. Уже было известно, что 1100-летие так или иначе будет отмечаться, и мы захотели увековечить это событие. Начали потихонечку воплощать эту идею. Архитектором самого памятника и благоустройства всего этого комплекса выступила моя дочь Марьям. Вместе с начальником строительного участка, нашим главным помощником Зульфикором Муминовым, они и ведут эту работу. Казалось бы, вроде и памятник не очень большой, всего-то три на полтора метра, но материала на его установку ушло почти три тонны. Учитывая, что всё это находится на горе и нет подъездных путей, всё это приходилось переносить вручную. Так что, труд очень большой.

***– Гумар Мулланурович, в свое время ваш фонд организовывал выездные уроки истории для школьников в село Ширяево. Будет ли эта практика продолжена?***

– Из-за экономических неурядиц, потом из-за пандемии эти уроки были приостановлены. Безусловно, мы их будем проводить, но формат будет изменен. Если раньше в основном в них участвовали учащиеся школы «Яктылык» и их родители, то сейчас мы планируем, что выездные уроки истории будут проводиться для лауреатов и номинантов областной исторической олимпиады, которую наш фонд собирается проводить. Думаю, в этом случае такие уроки будут более эффективны. Такую же олимпиаду мы планируем организовать для студентов наших вузов. Хочется, чтобы в них участвовали те, кому это действительно интересно, у кого горят глаза, кто в дальнейшем сможет стать ретранслятором полученных знаний для всех остальных. Наша задача – выявить этих людей, кому это действительно интересно. Может быть, в дальнейшем такие уроки можно будет проводить с выездом в Муромский городок с приглашением представителей научного сообщества. Ведь это тоже уникальный археологический памятник, история нашего народа. Если такая олимпиада будет востребована, то мы не исключаем возможности ее проведения на межрегиональном уровне.

***– Все то, что делается вашим фондом, требует достаточно немалых материальных затрат. Кто вам помогает?***

– Основная нагрузка ложится, конечно же, на фонд. Приходится вкладывать и свои личные средства. Помогают в чем-то власти, да и люди не остаются в стороне. Так, при строительстве мечети в Зубчаниновке при ее сметной стоимости в 40 миллионов рублей мы сумели привлечь 11 миллионов губернских денег и миллион рублей от моих друзей. Еще около 1 миллиона рублей собрали люди: кто из своей зарплаты, кто из пенсии. Второй пример – это памятник Летящему барсу, в возведении которого

помогли наши бизнесмены. Знаете, иногда деньги собираются не ради денег как таковых, а для вовлеченности людей в благое, а значит, общее дело. Те, кто помог или помогает нам, они сами с удовольствием бывают на этих объектах, привозят туда своих родственников, друзей, знакомых, начинают сами более глубоко погружаться в тему, в историю нашего народа. Это же здорово. Сейчас мы планируем создание небольшого выставочного музейного комплекса с площадкой для выступлений, где можно будет послушать лекции, небольшим минаретом и молельной комнатой. На реализацию этого проекта, думаю, нам тоже придется искать соинвесторов. Вместе с Царевым курганом этот выставочный комплекс также, уверен, будет интересен не только жителям нашего региона, но и для туристов. Эскизный проект у нас уже готов, сейчас занимаемся вопросом выделения земли.

***– Как вы думаете, столь масштабное празднование 1100-летия принятия ислама Волжской Булгарией, которое включает в себя проведение десятков различных мероприятий по всей стране, сможет ли послужить дальнейшему развитию интереса к истории этого древнего государства?***

– Я на это очень надеюсь. Ведь без знания своих корней, своего прошлого, невозможно строить будущее. И федеральные, и региональные власти это прекрасно понимают, иначе этому событию не уделялось бы столь пристальное внимание. Важно, чтобы такое же понимание было у нас у всех.

# «Иң яхшы укытучы»ны зурлап каршы алдылар




11–18 сентябрьдә Ставрополь крае, Пятигорск шәһәрендә узган “Туган тел һәм әдәбият фәне буенча иң яхшы укытучы” Бөтенроссия конкурсында катнашкан Рәхимә Илдус кызы ХӘЙРОВА Самара өлкәсен лаеклы рәвештә тәкъдим итте.

“Туган тел һәм әдәбият фәне буенча иң яхшы укытучы” Бөтенроссия конкурсының читтән торып катнашу этабында җиңү яулаган һәм икенче этабында да катнашкан “Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рәхимә Хәйрова 20 сентябрьдә Самарга кайтып төште. Вокзалда аны мәктәп директоры Радик Газизов, икенче сыйныф укучылары һәм ата-аналар чәчәкләр, шарлар һәм плакатлар белән каршы алдылар.

“Без бу очрашуга ныклап әзерләндек: кич буе плакатлар ясадык, иртән куыклар кабарттык. Рәхимә Илдус кызы шулай зурлап каршы алуыбыз белән бик канәгать калгандыр, дип ышанабыз”, — дип сөйли Әлфия Сөләйманова.

Бәйге туган телләрне һәм әдәбиятны укытуда инновацион педагогик тәҗрибә тупларга һәм башка педагоглар белән уртаклашырга ярдәм итә. Россиянең 69 төбәгеннән килгән укытучылар «Методик остаханә» һәм «Дәрестә» дип аталган этапларда көч сынаштылар, һәрберсе үз проекты буенча «Сыйныф сәгате» һәм «Мастер-класс» уздырды.



# Как булгары ислам принимали



## Для чего волжский народ 1 100 лет назад сменил государственную религию

*Волжская Булгария как централизованное государство закончило оформляться на рубеже IX и X веков – тогда же и появился в исторических источниках первый известный нам йылтывар (правитель) Алмуш, сын Шилки. Который, что характерно, начал отраженную в исторических источниках деятельность с введения единой государственной религии...*

*Дмитрий ГРЕКОВ*

### Внешнее лекарство для внутренних проблем

В истории многие народы меняли свои религиозные верования. Обычно это происходило двумя путями – подчинение или сильное культурное влияние соседей, когда вопрос смены веры был способом выживания или получения большой выгоды, либо на стадии перехода от первобытного родового строя к раннему государственному, в связи со сменой общественного устройства. Для Булгарии первая проблема не была актуальной – хотя многие историки пишут, что Алмуш просил у арабского халифата помощи от хазар, общей границы с ними у его государства не было – хотя авторы современных любительских карт в Интернете очень любят «всовывать» в каганат и саму Булгарию, на самом деле между ними лежали земли буртасов, которые считались вассалами хазар, но (по большей части) в основном самими хазарами. Естественно, степные всадники иногда доскакивали до реки Самары, южной границы Булгарии, и разоряли окрестности, но опасности для существования всей страны не было.

Так что озабоченность Алмуша вызывали, скорее всего, враги не внешние, а внутренние. В тюркском языческом культе единого бога неба Тенгри-хана, который исповедовали булгары, как и во всех прочих языческих культах, основную роль играла племенная знать. Которая в силу своей природы противилась централизации государства.

> В Булгарии было четыре больших племенных союза – эсегелы, берсула, баранджары и сувары. Последние были наиболее многочисленны и, во главе со своим вождем Вирагом, «активно мешали» Алмушу.

Так что принятие иной религии, которую принесут иноземцы, и которой они же будут учить, было хорошим способом ударить по местной знати и выбить у нее из рук опасное оружие. Так поступили, например, хан Богорис в Дунайской Болгарии (ставший царем Борисом I) и князь Владимир на Руси, принявшие христианство и, кстати, оба подавившие сильные языческие волнения по этому поводу. В Хазарии правители по тем же причинам приняли иудаизм – но, кстати, не заставляли перейти в него рядовых общинников.

Так что в 921 году к багдадскому халифу аль-Муктадиру прибыл посол правителя волжских булгар. Алмуш, кстати, к этому времени сам уже был мусульманином и просил «о присылке к нему кого-либо, кто наставил бы его в вере, преподал бы ему законы ислама, построил бы для него мечеть, воздвиг бы для него кафедру, чтобы он установил на ней от имени халифа хутбу в его собственной стране и во всех областях его государства».

### Как стать эмиром

Весной 922 года ответное арабское посольство прибыло в Волжскую Булгарию. Принято считать, что летом того же года состоялось всенародное принятие булгарами ислама. За исключением части сувар во главе с Вирагом, тогда как баранджары и берсула добровольно согласились на этот объединительный акт, а эсегелы, хоть и сомневались, в итоге все же не посмели ослушаться верховного правителя. Был ли каким-либо образом наказан или приведен к покорности Вираг, сведений в источниках не имеется, однако, судя по тому, что ислам всё же утвердился в стране как государственная религия, его «точка зрения не победила»... А йылтывар Алмуш «оборотился» в эмира Джагфара ибн Абдуллаха.

Еще одна просьба Алмуша к халифу касалась постройки крепости. Принято считать, что та была необходима для защиты от хазар. Однако, как мы уже отметили, такой прямой угрозы практически не существовало.

Ибн Фадлан, сообщающий в своем сочинении о письме новоявленного Джагфара багдадскому халифу, пишет, что булгарский правитель просил помощь в строительстве, «чтобы укрепиться в ней от царей своих противников», не упоминая при этом хазар. То есть, и тут правитель опасался больше «врага внутреннего» – видимо, всё тех же сувар и Вирага.

Естественно, что принятие Волжской Булгарией ислама вызвало в Хазарском каганате негативную реакцию. Как сообщает Ибн Фадлан, «в триста десятом году до царя хазар дошла весть, что мусульмане разрушили синагогу, бывшую в усадьбе ал-Бабунадж, он приказал, чтобы минарет [соборной мечети Итиля, столицы каганата,] был разрушен, казнил муэдзинов и сказал: «Если бы, право же, я не боялся, что в странах ислама не останется ни одной неразрушенной синагоги, я обязательно разрушил бы и мечеть». Произошло это в 310 году хиджры – значит, описанные события случились именно во время пребывания посольства из халифата в Волжской Булгарии летом 922 года.

Видимо, весть о прибытии людей халифа в страну волжских булгар и об окончательном утверждении там ислама вызвала возбуждение среди мусульман каганата. Но ссылаться на это как на причину репрессий было нежелательно, и правитель хазар выдвинул в качестве предлога разрушение синагоги в ал-Бабунадже.







*Булгары в X веке*

## Пропавшая мечеть

Об уровне исламизации Волжской Булгарии у исследователей до сих пор нет единого мнения. Одни ученые считают, что ко времени монгольского нашествия в XIII веке страна была практически мусульманской страной, другие – что булгары оставались «весьма поверхностными мусульманами».

Например, самое южное крупное поселение Булгарии было расположено на территории нынешней Самарской области – в Ставропольском районе. В XII веке площадь города составляла 150 га, а вместе с пригородами, окрестными селами и слободами – свыше 300 га. Он был обнесен двумя линиями укреплений, состоящих из валов и рвов. По оценкам специалистов, максимальная численность населения достигала 10 тысяч человек. Имя поселения нам, увы, неизвестно – Муромским городком его назвал академик Павел Паллас, исследовавший Самарскую Луку в XVIII веке.

При раскопках тут нашли много интересного – фундаменты каменных зданий и стен высотой 12 метров, следы плавильных печей, гончарных горнов, медных и ювелирных мастерских, а также многое другое. Но вот парадокс – практически все археологи и историки, пишущие о Муромском городке, не сомневаются, что в нем была мечеть, но... Точного ее местонахождения до сих пор установить не удалось.

Это, конечно, не говорит о том, что в городе не жили мусульмане (и даже что мечети там не было) – это подтверждают многочисленные археологические находки. Но сколько их было, и составляли ли они большинство населения – ведь найдены артефакты, указывающие на то, что в Муромском городке обитали (например) и русские ремесленники, причем не один и не два. Поселение, несомненно, было многонациональным и входило в состав Волжской Булгарии – но составляли ли именно тут мусульмане большинство? На этот вопрос историки пока точного ответа не дают.

В общем, именно в память всех описанных выше событий в мае 2022 года и было торжественно отмечено 1100-летие принятия ислама Волжской Булгарией – и в том числе и в Самарской области. По словам муфтия Самарской области Талипа Яруллина, религия булгар сохранилась в первозданном виде до сегодняшних дней и, ее последователи, благодарны предкам за то, что они выбрали именно ислам – религию чистоты и праведности, к чему все и должны стремиться.

# «Великая замятня»

## Как и почему в Золотой Орде началась «игра престолов»

***Убивал Бердибек своего отца или нет – вопрос не такой уж и принципиальный для его мрачной репутации, ибо как только он стал ханом Орды, так приказал казнить всех еще живых представителей рода Бату, которые могли претендовать на власть – всего «догнали и зарезали» 12 человек, в том числе 8-месячного младшего брата султана, которого старший, по уверениям хронистов, лично ударил головой оземь.***

***Дмитрий ГРЕКОВ***

### Братья на братьев

Естественно, что двенадцатью Батуидами репрессии не ограничились – все ключевые сановники при дворе лишились своих мест и были заменены на новых людей, которым Бердибек доверял (даже предполагаемый его соучастник в убийстве Джанибека, Тоглу-бай, был услан наместником-даругой в Азов). В числе прочих был освобожден от обязанностей беклярбек Кутлуг-Буга (незадачливый «непокоритель» Кафы), и этот пост достался ровеснику и другу детства нового хана, амиру (ака тёмнику) Мамаю, женатому на его дочери Тулунбек-ханум.

Мамай (носивший также мусульманское имя Кичи-Мухаммед) происходил из знатного, но не чингизидского рода Кият – его основателем был Хабул-хан, прадед Чингис-хана (отец которого Есугей-багатур основал род Кият-Борджигин, ответвление от основного). В Орде кияты возвысились при Тохте и с тех пор держались в высших эшелонах власти.



> **Отцом Мамая был Алаш-хан (Алыш, Алиш), долгое время управлявший Солхатом (ныне Старый Крым), резиденцией ордынцев в Крыму. Женитьба на дочери Бердибека позволила тёмнику после того, как тесть пришел к власти, зваться Мамай-гурген (почетный титул ханского зятя).**

Но вознесшая его на самый верх Фортуна очень быстро подставила подножку – в 1359 году Бердибек то ли скоропостижно скончался, то ли был убит в результате заговора недовольных казными, и новым ханом стал некий Кульпа, (ака Кульна), «человек ниоткуда» (ибо хотя и заявлял, что является сыном Джанибека и братом Бердибека, но все еще хорошо помнили, что сделал со своими братьями покойный султан). Он частично перебил приближенных «брата», но уцелевшие начали против него гражданскую войну.

Началась смута, названная русскими летописцами «Великой замятней» – часть эмиров призвала на трон правителя Улуса Орды-Эджена, ака Синей Орды (она же Кок-Орда) Чимтая (брата того самого Мубарака-ходжи, которого Узбек изгнал – см. предыдущие серии). Тот сам не поехал, но послал к «сопротивлению» своего младшего брата Орду-Шейха – однако люди Кульпы его перехватили в степи и убили. Тогда в богатом торговом городе Гюлистане (сведения о его местоположении ныне утеряны) ханом себя объявил Хызр (Хидырь, Кидырь), сын Сасы-Буги (правившего Синей Ордой в 1318/1319–1320/1321 годах, см. предыдущие серии; по другой версии – потомок Шибана, сына Джучи и брата Бату), и многие эмиры ему подчинились.

### Ханская чехарда

А смертельный удар Кульпе нанесла ханша Тайдула – в ее планы никак не входило отдавать трон каким-то «побочным приблудам». Она «тряхнула стариной» и вышла за некоего Науруз-хана (ака Мухаммеда), который тоже выдавал себя за «чудом спасшегося сына Джанибека» (по другой версии – потомок Тангута, сына Джучи и брата Бату)

Отчаявшись выйти на свободу, главный персонаж данной статьи сумел в середине августа скрыться из лагеря, имея на руках добытые женой фальшивые документы на имя представителя совета военной организации Габдуллы Рахимова, командированного в Баку.

В этот город Баттал и отбыл, надеясь затем отправиться в Иран, однако план не сработал. Пришлось возвращаться в столицу ТАССР, но уже с другими документами. Появляться дома было опасно, поэтому ночевал у знакомых, которые не спрашивали: «Тебя еще не повесили» (в разговоре с бывшими друзьями такое доводилось слышать). С наступлением зимы Габдельбари покинул город и около года скрытно скитался по всей России. Опять стало не до книг, поскольку пришлось заниматься

передвижной торговлей, имея на руках соответствующие бумаги, вновь ощутить жесткость тюремных нар, встречаться со знакомыми в Москве и Петрограде. Их предложение обратиться с покаянным письмом к И. Сталину он отверг и сентябрьской ночью 1921 года нелегально перебрался из Петрограда в Финляндию.

Здесь уже начинается история Абдуллы Баттала с измененной на 1883 (или 1882) год датой рождения. Опасавшийся преследования Габдельбари то ли перед эмиграций, то ли в Суоми в очередной раз поменял документы. В Финляндии он жил четыре года, занимаясь освоением финского и французского языков, преподаванием на курсах мусульманских основ для детей в гг. Хельсинки, Турку и поселке Терийоки (ныне – г. Зеленогорск, РФ), причем как сторонник джадидизма, и участвуя в общественных делах местной татарской диаспоры.



*Терийоки, начало XX века*

Так, вместе с бывшим имамом Петербурга Лютфи Исхаки наш герой ратовал за строительство мечети и татарской школы и вошел в состав комитета по возведению Дома Аллаха. Был он и членом комиссии, которая разрабатывала устав мусульманской общины Финляндии. Созданное в 1925 году общество татар этой страны «Исламия» было второй (после Австрии) официально зарегистрированной мусульманской организацией в странах Запада. Также Баттал работал в финляндском филиале американской организации «АРА» созданной для помощи голодающим Поволжья, и принимал активное участие в сборе и отправке продовольственных посылок. Персональные упаковки ушли в адрес известных просветителей Казани, Самары, Оренбурга, Астрахани, Уфы, Бугульмы. От некоторых из них поступили потом короткие благодарственные записки, а писатель Ф. Амирхан прислал весной 1922 года огромное письмо.

Кроме того Баттал наладил контакты с представителями турецкой прессы и писал статьи для их СМИ. Например, для газеты «Новый Кавказ», издававшейся в Стамбуле его знакомым Мамед Эмином Расулзаде (бывшим председателем Национального совета Азербайджана в 1918 году), с которым он встречался и в Финляндии. Некоторые материалы нашего главного персонажа увидели свет в турецких масс-медиа под псевдонимом «Казанлы». Однако основные усилия Абдуллы были связаны с историей. Пользуясь богатыми источниками на русском языке, хранившимися в библиотеках и архивах г. Хельсинки, он подготовил труд, который был издан в 1925 году в Стамбуле (с помощью Расулзаде) на турецком языке под названием «Казанские тюрки». В 1966 и 1988 годах сей труд переиздавался в Турции, а в 1996-м был напечатан на татарском языке в Татарстане. Эта книга о многовековой судьбе татар считается самой ранней работой, в которой уделено внимание национальному движению в Поволжье в революционную эпоху.

В ноябре 1925 года Баттал переехал в Турцию, где и прожил до конца своих дней. Сначала он обитал в Стамбуле, где трудился в Институте тюркологии и тюркской филологии, занимаясь переводами русскоязычных трудов на турецкий и написанием статей по теме этого учреждения. Через два года его пригласили в Анкару и приняли в Главное управление по печати для выполнения работ по переводу публикаций и документов. Отметим, что 1920–1930-е годы были в этой стране периодом «переводческой мобилизации». В центре внимания находилась идея формирования интеллектуального потенциала нации с помощью создания единых образовательных программ и общедоступных библиотек. Поэтому переводческой деятельности уделялось особое внимание.



*С женой и сыном*

К этому времени Абдулла эфенди хорошо владел арабским, русским, французским, финским, татарским языками и большинством наречий среднеазиатских республик. А после слияния этого управления с Министерством иностранных дел Турции наш герой с декабря 1931 года в течение 16 лет (до выхода на пенсию) был сотрудником данного министерства. С середины 30-х в соответствии с законом о фамилиях он стал именоваться как Абдулла Баттал Таймас.

В качестве турецкого чиновника наш герой сделал многое для становления истории и языка этой страны, а также тюркских народов. Он в 1932 году выступил с докладом о взаимосвязях чагатайского и турецкого языков на I конференции по изучению тюркских языков. А став членом «Общества по изучению турецкого языка», участвовал во многих его мероприятиях и по заданию этого общества подготовил некоторые труды по языкознанию. В 1934 году Таймас издал отдельной книгой тюркскую часть словаря Джамалетдина ибн Мухинна. По рекомендации президента Турецкой Республики М.К. Ататюрка, нацеленного на светские реформы и основавшего как «Общество по изучению турецкого

языка», так и «Турецкое общество исторических исследований», Баттал приступил к созданию «Словаря якутского языка» (в соавторстве) и переводу двухтомного «Большого киргизского словника» профессора Юдахина. К середине 40-х годов эти работы были завершены и изданы.

Абдулла эфенди регулярно печатался в газетах и журналах, выходивших на разных языках в Турции. Так, в одном из влиятельнейших изданий, формировавшем общественное мнение – журнале «Тюркский мир» – был опубликован его перевод статьи В.А. Гордлевского «Поворотная точка турецкой литературы». Кроме этого, только в течение 1926–1927 годов в 12 номерах этого СМИ появились собственные материалы Баттала о турецком языке, литературе и истории тюркских народов, подписанные порою инициалами «А.Б.». Его статьи печатались также в масс-медиа Германии (на татарском языке) и в сборниках, вышедших на французском и немецком языках.

То есть турецкая и тюркская линии в творчестве героя сей публикации занимают солидное место. Тем не менее основные усилия он приложил к разработке истории своего народа. В Турции им написано около десятка трудов на эту тему. Первым из них стала вышедшая в 1927 году книга «Нации, покинувшие Россию».

Спустя год Баттал принял участие в издании в Анкаре ежегодного бюллетеня, в котором увидели свет две его объемные статьи о казанских тюрках. А в 30–40-е годы напечатаны три статьи Таймаса об одном из идеологов татарского национального движения начала XX века, уроженце Симбирска Ю.Х. Акчуре.

Наверное, наш главный персонаж не знал, что в 1938 году в Казани готовился процесс над антисоветской «контрреволюционной организацией панисламистов» под названием «Идель-Урал». Он нужен был и для разгрома татарского национального движения внутри страны, и для влияния на эмиграцию в Германии, Турции и Маньчжурии. Аресту и допросам подвергли 40 человек. Среди лидеров организации в эмиграции значились Г. Исхаки, С. Максуди, Ф. Туктаров, А. Баттал, З. Валиди, Г. Идриси, Г. Терегулов, Р. Ибрагимов, А. Агеев. Несмотря на активную подготовку процесс не состоялся, а организаторы «дела» сами попали под колесо репрессий.

Таймаса в этот перечень включили, видимо, за старые «заслуги». Судя по всему, он за рубежом отошел от политики и полностью погрузился в любимые занятия – чтение и писательство. А выйдя на пенсию, наш соплеменник активизировал свою литературно-публицистическую деятельность. Так, в 1947 году в Стамбуле вышла его книга «Воспоминания о русской революции». После дополнения она повторно издана там же через 21 год.

Вторая часть воспоминаний о событиях тех лет была издана книгой опять-таки в Стамбуле в 1962 году и называлась «Я искал светлое будущее». В 2000 году эти книги вышли в Турции повторно. В переводе на татарский язык вторая книга выпущена в 2003 году в Казани.

После выхода первой из этих книг в стамбульской прессе конца 40-х годов писали, что Баттал в своем труде реалистично и объективно описал и оценил русскую революцию и большевистское правительство. А по мнению современных отечественных историков, эти труды Таймаса (как и Г. Исхаки, З. Валиди) сыграли особую роль в становлении эмигрантской историографии. Но так как эти авторы были активными участниками национального движения, то им не всегда удавалось сохранить объективность при описании событий революционной эпохи.

Назовем и книги нашего героя, посвященные отдельным известным представителям татарского народа, с которыми он общался, сотрудничал или наблюдал в действии: «Ризаэтдин Фәхретдин», 1958 год; «Муса Җарулла Биги», 1958 год; «Галимҗан Баруди», 1958 год; «Ике бертуган Максудилар», 1959 год. Все они серией «Казанские тюрки» вышли в Стамбуле, а последняя книга через 40 лет издана и в Казани. В 1996 году в столице Татарстана напечатан на татарском языке и труд «Казанские тюрки».

После их появления в Турции и распространения по свету в прессе Финляндии, Франции и США появились положительные рецензии на эти труды, а автор получил поздравления и слова благодарности из ряда стран. Ему писали: «Эти книги являются ценным источником для наших соотечественников, выехавших из России в очень молодом возрасте. Своими выдающимися трудами Вы внесли большой вклад в развитие национальной истории, выведя на свет наших великих деятелей, которые сделали для нации большое дело».

Такое обилие изданий, наверное, невольно подталкивает уважаемых читателей статьи к вопросу: «А на какие средства делал это Баттал?» Действительно, вопрос интересный, тем более, что он уже не работал, а его зарплата на госслужбе не была впечатляющей. В полной мере ответить на этот вопрос затруднительно, но один источник указать можно. Это деньги членов татарской общины Турции, которые не только поддерживали нуждающихся соплеменникрв, но и спонсировали их литературно-издательскую деятельность. Известно, что уже в 40-е годы такую помощь получали Г. Исхаки, А. Баттал, С. Максуди, а позже и другие ученые-эмигранты.

Публикации Таймаса о татарских личностях размещали и редакторы СМИ. Так, в журнале «Тюркский сборник» в 1955 году появилась его статья о крымском поэте: «Кырымлы Бәкер Чобанзадә шигырьләре». А журнал «Dergi», издаваемый на тюркских языках в Мюнхене, напечатал в конце 50-х

очерки о Р. Фахретдине, С. Максуди, Г. Баруди и в 1960 году – статью «Национальные традиции казанских тюрков».

В те же десятилетия в двух журналах Турции, освещавших проблемы культуры и языка, вышли воспоминания нашего героя о Г. Тукае, Г. Исхаки, Ф. Амирхане, Дж. Валиди, И. Гаспринском.

Порадовал в это время Баттал и турецких граждан, выпустив в 1950 году в Анкаре книгу «Зеленый Ризе и его область» после посещения этого города. Вспоминал ли он при этом того жителя Ризе, который «надул» его с документами в начале века в Крыму?!

В 1968 году при содействии Турецкого лингвистического общества Таймас издал в Анкаре книгу на турецком языке объемом в 151 страницу – «Пословицы и поговорки на казанском тюрки». Это был его последний труд, увидевший свет при жизни автора. Книга повторно вышла в Анкаре через 20 лет.

С этим городом Абдулла ага расстался в середине 50-х, переехав с женой после ее выхода на заслуженный отдых в Стамбул. А воссоединение семьи состоялось в 1928 году, когда супруга с сыном смогли выехать из России. Правда, по мнению их родственников, с которыми общался Л. Хамидуллин, это произошло пятью годами раньше – еще в Финляндии.

В Стамбуле А. Баттал Таймас и умер 26 апреля 1969 года. Похоронили его на старейшем городском кладбище Караджахмет, где покоятся многие видные деятели Турции. Здесь, на одном из самых больших некрополей мира, совершено более миллиона погребений.

А публикации Г.Г. Батталова, как отмечалось выше, продолжали выходить в турецких издательствах и СМИ, в том числе и во вновь открывавшихся масс-медиа. Так, в 70-е годы на средства владельца турецкого филиала компании Mercedes-Benz, татарина родом из Петропавловска Ахметвели Менгера, здесь издавался ежеквартальный литературно-публицистический журнал «Kazan» («Казань»). В его 21-м номере (1978 год) была опубликована статья Баттала «Тюркская литература новой Казани», в которой анализировалось творчество 21 соплеменника. Другая же статья Таймаса «Взятие Казани» появилась на страницах журнала шестью годами раньше – к 420-летию описываемого события.

В конце минувшего века, как видно из данной публикации, его труды стали печататься и в Татарстане. Материалы о деятельности Г. Батталова обнародовали писатели и ученые, а также его земляки. Например, Новобелогорская библиотека в 2015 году выпустила буклет, тематическую папку и видеофильм «Из реки забвения» об односельчанине, который последний раз посетил малую родину почти сто лет назад – в 1916-м, хотя ранее приезжал довольно часто на сабантуи. А осенью 2018 года в г. Троицке начались занятия в восстановленном медресе «Расулия» – в альма-матер нашего героя. Поставлена, наконец, точка в деле с его заключением. Решением Прокуратуры РТ от 28 февраля 2000 года он был реабилитирован как жертва политической репрессии.



*Открытие восстановленного медресе «Расулия», 2018 год*



СПРАВКА О РЕАБИЛИТАЦИИ

Прокурор Республики Татарстан

К.Ф. Амиров

*Справка о реабилитации Батталова*

Завершая рассказ о Г.Г. Батталове, вспомним еще одного нашего земляка – видного поэта средневековья Сайфа (Саифа, Сейфа) Сараи, родившегося, по мнению ряда востоковедов, в 1321 году в местности Камышла нынешней Самарской области. В 70 лет он перевел на кипчакский язык одно из наиболее известных произведений классика персидской литературы Саади Ширази, называющееся «Гулистан» («Цветочный сад») и представляющее собой сборник притч и стихов морально-этического характера. Рукопись Сараи «Гулистан бит-тюрки» («Гулистан по-тюркски») до нас дошла в виде копии из 373 страниц, которая хранится в Голландии. В середине



*С.Г. Батталова – внучатая племянница, рассказывает об А. Баттале Таймасе, 2015 год*

прошлого века турецкий профессор Феридун Нафиз Узлук опубликовал в Анкаре этот текст. А первым, кто высказал научное мнение о переводе Сараи, стал А. Баттал Таймас, проанализировавший эту работу с литературной, языковой и исторической точки зрения.

Наш герой наверняка был знаком со многими афоризмами Саади. Есть среди них и такой: «Блажен, кто сможет на земном пути / Сокровища познаний припасти». Габдельбари эфенди припас их, и немало, сделав упор на самообразование. Причем не просто припас, а задействовал для достижения научных вершин, прославления своего народа и внесения лепты в турецкую жизнь. Он действительно Баттал (отчаянный) и Таймас (упорный).

# ЛЕЧИТЬ БОЛЬНОГО, А НЕ БОЛЕЗНЬ

**Таков принцип нового лечебного учреждения, открывшегося в Самаре**

***Летом этого года в нашем городе начала работу в тестовом режиме многопрофильная клиника «Доверенный Доктор». Ее возглавила кандидат медицинских наук, врач-дерматовенеролог, косметолог Ася Ильдаровна Табашникова, а ее главным помощником в этой работе, заместителем генерального директора по развитию, стала ее коллега – кандидат медицинских наук, врач-дерматовенеролог, косметолог, врач превентивной и интегративной медицины Мария Сергеевна Измалкова. Мы попросили их рассказать читателям нашего журнала о том, чем новое лечебное учреждение отличается от других государственных и частных медицинских учреждений, какие здесь оказываются услуги и каким его руководители видят дальнейшее развитие клиники.***

***– В последние годы на региональном рынке медицинских услуг достаточно большая конкуренция. Скажите, не страшно было начинать новое дело и как вы планируете найти свою нишу?***

– Конечно, начинать любое большое дело очень волнительно. Тем более в наших непростых экономических условиях. Наличие в нашем регионе одного из крупнейших в стране медицинских вузов, широкой медицинской научной и практической базы – всё это самым положительным образом сказывается на темпах развития здравоохранения. В том числе и в частной медицине. Поэтому, вы правильно заметили, что в нашей сфере конкуренция очень высока. Концепцию работы клиники «Доверенный Доктор» мы строим по принципу «лечить больного, а не болезнь». Мы же знаем, что в организме человека всё взаимосвязано, поэтому при диагностировании и лечении заболевания важно найти причину болезни, а это, мы считаем, возможно только при мультидисциплинарном подходе – в поликлинике и объективной оценке состояния пациента врачами разных профилей. Когда план лечения тоже вырабатывается после совместного обсуждения со всеми специалистами, наблюдающими больного. Именно поэтому мы делаем упор на коллегиальное ведение пациента. Лечащий врач нашей клиники может принять решение о необходимости консилиума с врачами смежных специальностей и организовать его с согласия пациента. У нас есть возможность проводить такие консилиумы как

*А. И. Табашникова*



*М. С. Измалкова*



очно, так и заочно, используя возможности телемедицины.

***– Есть какая-то конкретная специализация у вашего лечебного учреждения? Какие направления в нем представлены?***

– В клинике «Доверенный Доктор» пять больших направлений работы. Это – врачебная косметология, стоматология, поликлиника плюс групповая практика врачей, учебный центр «Групповой медицинский тренинг» и специализированная аптека.

***– Расскажите о своей команде. Как вы подбираете врачей в клинику?***

– Медицинский прием в рамках поликлиники будут вести терапевт, эндокринолог, гинеколог, невролог, уролог-андролог, врач УЗИ, дерматовенеролог, ревматолог, гастроэнтеролог, подолог, трихолог, психолог и врач превентивной медицины. Уже сегодня в нашем коллективе 2 доктора наук и 3 кандидата наук. При выборе специалистов мы обращаем особое внимание не только на глубокий уровень медицинских знаний и квалификацию, но и на такие человеческие качества докторов, как умение сопереживать и поддержать человека в нужную минуту. Ведь если не будет доверительных отношений между врачом и пациентом, мы не сможем получить полное представление о заболевании пациента, а значит, оказать качественную помощь.

***– Какие методики диагностики или лечения в вашем лечебном учреждении вы назвали бы уникальными?***

– В клинике «Доверенный Доктор» планируется кабинет биологических, генно-инженерных препаратов зарубежных и отечественных фармпроизводителей для пациентов с дерматологическими и ревматологическими заболеваниями. Мы осуществляем комплексный подход к лечению хронических дерматозов, основанный на клиническом наблюдении пациентов и применении современных биологических препаратов. Планируем развивать длительное наблюдение и отдельных терапевтических состояний: например, аденомы предстательной железы с момента выявления и на всю жизнь. Из уникальных направлений клиники могу также подчеркнуть ведение пациентов с витилиго, очаговой склеродермией и другими редкими дерматозами. Сегодня в стране не так много учреждений занимается лечением этих заболеваний. Отдельного внимания заслуживают подологический и трихологический кабинеты с обученными докторами-дерматовенерологами по этим направлениям кожной патологии и современным оборудованием. Мы также предоставляем все виды стоматологических услуг: лечение и профилактика кариеса и его осложнений, имплантация и рациональное протезирование. И конечно, хочется отметить оказание медицинской помощи по принципу «доверенный врач». Мы планируем заключение партнерских отношений с другими лечебными учреждениями в разных городах России. Если пациент, находясь в другом городе, оказался в ситуации, когда ему понадобилась медицинская помощь, – мы поможем найти в этом городе квалифицированного специалиста и удаленно организуем запись на прием. Это дает пациенту чувство безопасности и заботы, а нам – уверенность, что медицинская помощь доверившемуся нам человеку будет оказана максимально качественно и в короткие сроки, даже если он сейчас находится в поездке.




***– Какие процедуры могут пройти пациенты непосредственно в вашей клинике?***

– Пациент может записаться на проведение дерматоскопии для диагностики новообразований кожи, трихоскопии при проблеме выпадения волос, мы также проводим широкий спектр лабораторных анализов и ультразвуковую диагностику. В клинике «Доверенный Доктор» сильное отделение косметологии, в котором проводятся процедуры не только эстетического профиля (современные инъекционные и аппаратные методики, комплексные программы уходов на качественной космецевтике и омолаживающие процедуры), но и врачебное направление косметологии. В клинике представлены высококлассные косметологические аппараты, парк которых еще будет пополняться ближайшее время. Основное преимущество современных косметологических методик – это возможность быстро решить широчайший спектр задач. Например, всего несколько сеансов фотоомоложения на американо-израильском аппарате Lumenis M22 способны ликвидировать дефекты, с которыми люди безуспешно борются годами – проявления акне и постакне, пигментные пятна, сосудистые сеточки, расширенные

поры и мелкие морщины. А $CO_2$-лазер итальянской компании DEKA (являющейся одним из мировых лидеров рынка лазерного оборудования) позволяет проводить удаление доброкачественных новообразований (с обязательной патогистологией удаленных тканей), коррекцию рубцов и растяжек любой давности и фракционное омоложение кожи.

***– В каком направлении вы будете развивать клинику дальше?***

– Мы считаем очень важным развитие телеконференций и телеконсультаций. Телемедицина – это формат медицинской консультации через видеоконференцию онлайн. Оборудование учреждения позволяет вести трансляцию из любого врачебного кабинета в лекционный зал учебного центра клиники без ограничения количества участников. Большой экран высокого разрешения дает возможность точно передавать все подробности косметологических процедур. Подобный формат – это универсальная обучающая платформа и для медицинских сотрудников, и способ оказания помощи пациентам. При этом онлайн-формат не снижает качество оказанной консультации, а наоборот, повышает доступность медицинской помощи людям и дарит возможность связаться с высококлассными докторами не только из городов России, но и из любой точки мира. Уже сейчас ведутся переговоры с зарубежными коллегами по услуге «второе врачебное мнение».

***– У многих жителей сегодня сложился стереотип, что частная медицина – это дорого. Скажите, кто ваши клиенты? На каких пациентов вы рассчитываете?***

– Наша клиника открыта для всех жителей Самарской области и ее гостей. В основе профессии врача лежит улучшение и продление жизни человека, поэтому мы считаем, что качественная медицина должна быть доступна для всех людей, вне зависимости от уровня их дохода. Мы стараемся создать комфортные условия для оказания профессиональной медицинской помощи для всех. Конечно, хотелось бы видеть больше молодежи, для которой мы будем предлагать разные программы лояльности и поддержки. Для нас самым лучшим показателем доверия являются рекомендации наших пациентов их близким и друзьям. Конечно же, мы постараемся сделать все от нас зависящее, чтобы таких рекомендаций было как можно больше.

***– Планируется ли праздничное открытие клиники? Если да, то когда?***

– Нет, никаких торжеств по этому поводу мы устраивать не планируем. В непростых эпидемиологических условиях, связанных с распространением коронавируса, такие массовые мероприятия проводить просто опасно. Наша клиника уже работает. Сегодня ведется прием в отделениях косметологии, стоматологии и по отдельным терапевтическим профилям у приглашенных специалистов. Надеемся, что до конца года будут открыты приемы пациентов и по другим направлениям. Всю информацию о работе клиники можно получить на нашем сайте: ***www.td-clinic.ru*** и в социальных сетях.








# КҮҢЕЛЕ МИҺЕРБАНЛЫК БЕЛӘН ТУЛЫ



***«Өлкәннәр мине үз кызларыдай күрә, алар да минем якын кешеләремә әйләнделәр инде", - ди алты ел социаль хезмәткәр булып эшләүче милләттәшебез – Рафаэль кызы Гөлназ Нураева.***

***Миләүшә Газимова.***

Авылдашлары аны сабыр, тыйнак, мәрхәмәтле, уңган, эш сөючән, ачык йөзле ханым буларак тасвирлыйлар. Бик ипле, тәмле итеп сөйләшә Гөлназ, ә тавышы шундый йомшак, ягымлы ки, шунда ук үзенә әсир итә, тыңлап торуы бик рәхәт.

Язмам герое үз һөнәрен дөрес сайлап алган, дип саныйм. Социаль хезмәткәр булып, нәкъ Гөлназдай, олы йөрәкле, киң күңелле, миһербанлы, башкалар белән уртак тел таба белгән шәхесләр эшләргә тиеш тә. Чөнки аларның төп вазифасы – җан җылысын бирү, дияр идем. Олы кешеләргә, иң беренче чиратта, яхшы сүз, күңелләрен күрү кирәк бит ул.

– "Кызым, эшләрне аннан карарсың. Минем белән бераз сөйләшеп утыр әле", – дип сорыйлар миннән әби-бабайлар. Серләрен дә чишәләр, моң-зарлары белән дә уртаклашалар, – ди бу турыда Гөлназ үзе дә.

Камышлыдан Гали авылына килен булып төшкән бу ханым бирердә менә инде 27 ел гомер итә. Тугыз ел элек ире Ринат якты дөньядан китеп баргач, Гөлназ өч малай белән ялгызы кала. Иң кече улына ул вакытта алты ай гына була.

"Кайгы агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри", – дип дөрес әйтәләр инде. Кызганычка, милләттәшебезгә күп хәсрәт, авырлык күрергә туры килә шул. Ел ярым элек ул газиз әнисен җирли. Ә быел июль аенда бертуган сеңелесе дә гүр иясе була. Аның ятим калган баласы Данилны, уйлап та тормыйча, үзенә ала Гөлназ.

"Улым, әниеңне мәңгелеккә югалттык. Хәзер инде мин синең әниең булам. Сине беркайчан да ташламаячакмын, гомер буе безнең белән бергә яшәячәксең", – дип аңлата ул тугыз яшьлек Данилга. Һәм малай шул көннән аңа "әни", дип эндәшә.

Гөлназның үз балалары да моңа каршы бер сүз әйтмиләр, киресенчә, шунда ук: "Инәкәй, энебезне үзебезгә алабыз", – диләр.

– Алар болай да бертуганнардай иде, гел аралашып, күрешеп тордылар.

Мине хуплаганнары өчен улларыма рәхмәтлемен. Данилны үзем дә, малайларым да бик яратабыз. Миңа ул үз баламдай", – дип сөйләгәндә күз яшьләрен тыя алмады Гөлназ ханым.

Әлхәмдүлилләһ, нарасыйларын миһербанлы, тәртипле, тәүфыйклы итеп тәрбияләгәннәр Нураевлар.

Олы уллары Рамазанга 26 яшь, ул вахта юлы белән Себердә эшләп йөри икән. 24 яшьлек Расул Богырыслан шәһәрендә нефть компаниясендә хезмәт итә, әйдәп баручы инженер. Кече малае Раушан Данил белән бер елгы, аралары бер ай гына. Быел алар дүртенче сыйныфта белем алачак.

– Ирем исән чакта мин балалар, өй-йорт эшләре белән шөгыльләнә идем. Бакчада күпләп җиләк үстерә идек.

Ринат вафат булгач, социаль хезмәткәр һөнәрен үзләштердем. Рульгә утырырга да туры килде. Җиләкне базарга илтеп сатарга кирәк. Төрле йомыш белән чабарга да яхшы. Күрше авылларда яшәүче әби-бабайларым янына да тимер атта йөрим.

Хәләл җефетемне югалткач, ике ел эчендә яңа йорт са-



лып кердек. Бу эштә зур матди ярдәм күрсәткәннәре өчен бөтен авылдашларыма, туганнарыма, мәчетләргә, Похвистневоның “Дуслык” ит эшкәртү предприятиесенә олуг рәхмәтләремне белдерәм.

Ялгыз хатынга җиңел түгел инде. Раббыбызга мең шөкер, Үз ярдәменнән ташламый. Малайларым да, әлхәмдүлилләһ, тәртипле, акыллы, һәрнәрсәдә булышалар, күңелемне күрәләр. Алар – минем бәгырь кисәкләрем, яшәү мәгънәм, – дип сөйли нарасыйларын өзелеп яратучы Гөлназ.

Күп кайгы күрсә дә, яшәешкә якты карашын, тормышка мәхәббәтен, кешеләргә карата игелекле мөнәсәбәтен югалтмаган бу ханым. Киресенчә, әйтерсең лә авырлыклар аның күңелен тагын да йомшарта төшкән, дөнья көтәр өчен тагын да күбрәк көч өстәгән.

Гөлназ Нураева Галидә һәм күршедә урнашкан Ногай, Кызыл күпер авылларында барлыгы 15 кешегә хезмәт күрсәтә. Кемгә көн аралаш, кемгә атнасына ике мәртәбә барып йөри ул.

– Бер-икесе бөтенләй ялгыз, ә калганнарының балалары читтә яши, әти-әниләре янына ял көннәрендә генә кайта алалар.

Иң яшенә – 65 яшь, иң өлкәнә – 94 яшьлек бабай.

Аллаһыга шөкер, барысының да зиһене яхшы, әкрен генә үз аякларында йөриләр, – дип сөйли Гөлназ үзе караган олылар турында.

***– Аларга нинди хезмәт күрсәтәсез?*** – дип кызыксындым аңардан.



– Ризык, дарулар, көндәлек кирәк-яраклары сатып алып китерәм, өйләрен җыештырам, ашарга пешерәм, савыт-саба юам. Кайберләрен мунча да кертәм.

Урында ятып торучылар булса, аларның памперсларын, киемнәрен алмаштыру да безнең вазифага керә.

Шундый эшләрдән тыш, сәламәтлекләрен күзәтеп торырга кирәк: температурасын, кан басымын үлчәргә, хәлләре начараеп киткән очракта табибны һәм туганнарын чакырырга. Гомумән, андый-мондый хәл килеп чыкса, беренче медицина ярдәмен күрсәтергә тиешбез.

Гөлназ Нураева сүзләренчә, социаль хезмәткәр, иң беренче чиратта, сабыр, мәрхәмәтле булырга тиеш.

– Картларны тыңлый, аңлый белергә кирәк. Һич кенә дә үпкәләтмәскә, җаена гына торырга. Һәм, әлбәттә инде, үз хезмәтеңне сөю мөһим. Безнең эшне олы йөрәкле, киң күңелле кешеләр генә башкара ала.

Шушы еллар эчендә бик күңдем үзләренә, мин булмасам, кем карый инде аларны, дип борчылам. Ял көннәремдә дә, миннән башка нәрсә эшләп беттеләр икән, дип уйланып йөрим, кайгыртам, караган кешеләрем өчен зур җаваплылык тоям, – ди әңгәмәдәшем.

***– Һәр эштә дә авырлыклар була, сезнең хезмәтегез дә җиңел түгел. Стресслардан ничек арынасыз?***



– Өйгә кайтып кергәч, эштәге кыенлыклар шунда ук онытыла ул. Башың белән йорт мәшәкатьләренә чумасың, балалар белән мәш киләсең.

Күңелсезләнгән чакларымда догалар укып тынычланам.

***– Балаларыгызны нинди үгет-нәсыйхәтләр биреп тәрбиялисез?***

– Ата-ана нарасыйларын яхшыга гына өнди инде ул. Кешеләргә ярдәмчел булыгыз, авыр вакытларында ташламагыз, дип үстердек үзләрен.

Ирем дини кеше иде. Олы улларыбызны кечкенәдән үзе белән мәчеткә алып йөрде, мәдрәсәдә дә белем алдылар. Бүгенге көндә дә, шөкер, гыйбадәт кылалар, мәчеттә җомга намазларын калдырмыйлар. Дин юлыннан атлаган бала тәртипле була бит ул.

***– Улларыгыз татарча сөйләшәме?***



– Әйе, ана телен бик яхшы беләләр. Өйдә татарча гына сөйләшәбез.

***– Гөлназ ханым, сез заказга тортлар да ясыйсыз икән бит әле. Бигрәк уңган да инде үзегез!***

– Тортларны хәзер бер егерме еллап пешерәм инде. Токмач кисеп тә сатам.

Кубесенчә баллы (медовый) торт ясыйм мин. Тик аларны бизәп утырырга вакытым җитми шул. Шуңа күрә гади килеп чыгалар.



Әмма тәме буенча барысына да ошый (елмая). Туган көннәргә, юбилейларга, дини мәҗлесләргә пешертәләр.

Ураза, Корбан айларында заказлар аеруча күп була.

Уңган, дигәнегездән, тормыш барысына да өйрәтә ул. Кечкенәдән әби, әнидән күреп үстем. Тора-бара тәҗрибә туплыйсың бит инде.

Похвистневода Үзәк мәчеттә никах туйлары, авыз ачу, корбан мәҗлесләре үтә. Күрше хатыны Хәмидә белән анда аш-су әзерлибез.

Улларымны да татар милли ризыклары белән сыйларга яратам. Бәлеш, өчпочмак, мантыйлар ясыйм. Көн дә төрле нәрсә пешерергә тырышам. Өй тулы егет бит (елмая)!

***– Галидә күп еллар гомер итәсез. Ул үз авылыгызга әйләнгәндер инде?***

– Үземне бирегә килгән кеше, дип әйтә алмыйм, әйтерсең лә шушында туып-үскәнмен.

Авылыбыз дини, зур, матур, чиста-пөхтә. Халкы яхшы, ярдәмчел. Дус булып, туганлашып яшибез.

Киләчәге дә өметле. Яшьләр туган җирендә төпләнеп кала. Авылыбыз, шөкер, гөрләп яши.

***– Сезнеңчә, хатын-кызның бәхете нидә?***

– Минем өчен – малайларымда. Тәүфыйклы балалар – ана өчен иң зур бәхет ул. Исән-сау, озын гомерле, бәхетле булсыннар, дип сорыйм Раббымнан.

Аллаһыга шөкер, улларымнан бик канәгать. Олыларын өйләндереп, бергә тату тормышта яшәргә насыйп булсын. Кечкенәләрен тәртипле кешеләр итеп үстерергә язсын.

***– Бүгенге көндә нәрсәләргә куанып яшисез?***

– Тормыштагы һәр мизгелне татып яшәү – минем өчен зур сөенеч.



Туган һәр көнгә разый булып, Раббыбызга шөкер итәм. Эшебез, торыр урыныбыз бар, тамагыбыз тук, әлхәмдүлилләһ. Үзем, балаларым исән-сау – шунысы үзе олуг бәхет инде ул.

***– Киләчәктә дә гаиләгезгә хәерле көннәр генә насыйп булсын, Гөлназ.***

Әйе, социаль хезмәткәр һөнәр генә түгел, ул – вазифа, яшәү рәвеше һәм җан халәте дә әле. Бу һөнәр иязләре ярдәмгә мохтаҗ булган олы яшьтәге кешеләргә таяныч һәм терәк, кирәк чагында юатучы да, киңәш бирүче дә булып торалар.

Шуңа күрә Гөлназ Нураева караган әби-бабайлар үзенә: “Кызым, син бит миңа баламдай якын”, – дип, изге хезмәте өчен рәхмәт яудыралар.

Менә шушы өлкәннәрнең берсе – 76 яшьлек Суфия Минегалиева Гөлназ ханым турында болай ди:

“Аллаһы Тәгаләнең барлык рәхмәтләре яусын иде бу балага. Ул булмаса, мин нәрсә эшләр идем икән!

Ирем бер ел элек вафат булды. Ялгыз яшәү җиңел түгел. Әле дә Гөлназ бар. Аны сагынып көтеп торам мин.

Шулхәтле намуслы, шәфкатьле кеше ул – исләрең китәр! Һәрнәрсәдә булыша, мине хастаханәгә дә алып бара, дарулар да кайтара.

Сөйләшкәннәребез икебез арасында гына сакланып кала. Бер йорттан икенче йортка сүз йөртми.

Мин аңа: “Раббым үзеңә исәнлек бирсен, мине берүк ташлама инде”, – дим. Гөлназ миңа, туган сеңелемдәй, бик кадерле.

Аллаһы Тәгалә бу изге күңелле кешегә исәнлек, озын гомер, бәхетшатлыклар бирсен. Рәхмәтем чиксез”.

70 яшьлек Рузия апа Муратова да үз фикерләре белән уртаклашты:

“Гөлназ мине өч елдан артык карый инде. Шулхәтле мәрхәмәтле, игелекле балакай, һәр яктан килгән.

Тырыш, уңган, хезмәт сөючән, тиешлесеннән артыгын да эшләп китә әле ул.

Үзе ачык йөзле, елмаеп кына тора, яхшылап сөйләшә. Аның миһербанлылыгына хәйран калам инде мин.

Гөлназга зур рәхмәтләремне белдерәм, сәламәт, озын гомерле була күрсен. Аллаһы Тәгалә аны Үзенең ярдәменнән, рәхмәтеннән ташламасын”.



***1941 - 1945 елгы Ватан сугышы вакыйгаларын үз күзе белән күргән, катнашкан кешеләрне хәзер бармак белән генә дә санап чыгарга да буладыр. Кайдандыр тарихыбызны икенче төрле итеп күрсәтә торган псевдотарихчылар, аналитиклар килеп чыгалар, тарихыбызны бозып күрсәтергә тырышалар. Россия патриотларының максаты шул: халык күңеленә чын дөреслекне илтеп җиткерү, фашистларның, бандерачыларның мәкерле планнарына чик кую. Советлар иле таркалгач баш калкыта башлаган милләтчеләр Украинаны әнә нинди хәлгә төшерде бит. Безнең илебез миллионлаган корбаннар бәһасенә азатлык яулады һәм, башкача беркайчан да дошманны илебезгә кертмәс өчен, аяусыз көрәш алып барачак.***

*Надеждино мәчете имамы Ислам ШАҺИӘХМӘТОВ,*
*Мәсхүт КЫЯМОВ*

# БЕР ГАСЫРЛЫК ҮРНӘК ТОРМЫШ

Әлеге язмабызның герое – Кошки район үзәгендә яшәүче сугыш һәм хезмәт батыры, 2нче төркем инвалиды, йөз яшьлек Хәйдәр Минсәлим улы ВӘЛИЕВ. Ул 1922 елда, халык ачлыктан кырылган чакта, Мәләкәс районының Крип авылында күп балалы крестьян гаиләсендә туа. Ачлыктан, авыр тормыш шартларыннан, авыруләрдан алты баласы вафат була, бишесе исән кала. 1934 елда туган авылы янып, күлгә әверелгәч, гаилә Ульян өлкәсенең Төгәлбуа авылына күченә.

Хәйдәргә яшьли эшкә җигелергә туры килә. Хезмәт юлы башында ул колхозда заправщик, юкә заводында слесарь булып эшләп йөри, техникага тартыла, үзлегеннән трактор белән идарә итәргә өйрәнә. Армиягә алынгач, аны Сызранга җибәреп, тракторчылыкка укыталар. Вәлиев фронтка китә, 164нче саперлар батальонына эләгә. Авыр артиллерия расчетын урыннан-урынга тракторлар ярдәмендә күчереп йөртә. Менә шул вакытта Вәлиев алган һөнәр кирәк булып чыга да инде.

Хәйдәр яраланып, сул күзен югалткач, аны комиссовать итәргә телиләр. Ләкин ул фронтта калам, дип кырт кисә һәм сугыш ахырына кадәр фронтта була, Румынияне азат итүдә катнаша, Берлинга, Япон фронтына барып җитә. Батырлыгы, ныклыгы һәм тәвәккәллеге өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыш тәмамлангач, Кошки районының Погрузная станциясендәге МТМга урнашып эшли башлый. Биредә ул, чәчү вакытында 150 литр керосин экономить иткән өчен, Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Бераздан бәхетен дә очрата, Минхәят исемле кызга өйләнеп, тормыш кора, алты баласы туып үсә. Еллар узган саен сугыш ветеранының сәламәтлеге какшый бара. Ләкин 2нче төркем инвалиды булса да, өйдә кул кушырып утырырга өйрәнмәгән. Надеждино авылының Энгельс исемендәге колхозында тракторчы, терлекче, слесарь булып эшли. Кайда гына эшләсә дә, Хәйдәр Минсәлим улы җитәкчеләрнең ышанычын аклап килә. Сугыштан соңгы елларда анда миллионер-колхоз рәисе булып Ленин ордены кавалеры Г.М. Косенко эшләгән һәм ул Вәлиевнең хезмәтеннән һәрвакыт канәгать булган. 1976 елда яшелчәчелек һәм терлекчелек өлкәсендәге уңышлары өчен Хәйдәр Вәлиев “Знак Почета” ордены белән бүләкләнә. 1976 - 1979 елларда социалистик ярыш алдынгысы булып таныла, 1978 елда терлекчелек буенча “Кошки районының иң яхшы терлекчесе” исемен алуга ирешә. Хәйдәр ага, пенсиягә чыккач та, әле тагын алты ел колхозда эшли. Хөкүмәт сугыш ветераннарына фатирлар бирә башлагач, аңа да үз фатирында яшәү бәхете тәти. Тик менә хатыны Минхәят кенә утыз ел элек үлеп киткән. Хәзер ул улы Рәшит һәм килене Гадиния белән яши.

Хәйдәр Минсәлим улы бик тә динле кеше. Аңа йөз яше тулып килүгә карамастан, ул ислам диненең бөтен кануннарын да үтәп килә: намаз укый, ураза тота, җомга көннәрендә улы Рәшит белән Кошки яисә Надеждино мәчетенә җомга намазына бара. Кайтуларына Гадиния тәмле ашлар пешереп тора. Бабай тугыз оныгы һәм алты оныкчыгы уңышларына да сөенеп туя алмый.

Аның белән тормыш, дин темаларына әңгәмә корып утыруы да күңелле. Аек акыллы аксакал сугыш вакытында артиллерия пушкаларын сөйрәп йөргән вакытларын еш искә ала. Туган иленең чын патриоты ул: Украинада барган махсус операция нәтиҗәләрен күзәтеп бара, безнең солдатлар һәм офицерлар өчен догалар укып, җиңү белән исән-имин кайтуларын теләп тора.

Хәйдәр Минсәлим улы Вәлиевка 1 июльдә йөз яшь тулды. Аның бер гасырлык тормышы, Россия исемле күп милләтле ил халыклары бөтен дөнья халыклары белән дуслыкта һәм хезмәттәшлектә яшәсен дип, корал тотып яуга чыккан хәрбиләр өчен дә тиңсез батырлык үрнәге.

# “ӨЙЛӘНГӘНДӘ ҮЗ ИШЕҢНЕ ЭЗЛӘРГӘ КИРӘК”

*Һәр авылның мактауга лаеклы, үрнәккә куярлык шәхесләре бар. Бу язма нәкъ шундый кешеләр – Иске Кулаткы районының Иске Мастяк авылында туып-үскән Сәит һәм Наилә Хөсәеновләр турында.*

*Миләүшә Газимова.*
*(“Сәлам” гәҗитәсе)*



“Ир кеше үз гомерендә өч гамәлне башкарырга тиеш: агач утыртырга, йорт салырга, малай үстерергә”, - дигән гыйбарә яшәп килә. Күп хатын-кызлар моңа тагын аракы эчмәскә, тәмәке тартмаска, хәләл җефетен кадер-хөрмәттә яшәтергә, тугры, гаилә җанлы, эшчән булырга, дигән гамәл-сыйфатларны да өстәрләр иде, мөгаен. Чөнки гүзәл затларның күбесе чын ир-ат нәкъ шушы сыйфатларга ия булырга тиеш, дип саный. Һәм тормышта андый ирләр, чыннан да, бар икән бит!

Кәшаф улы Сәит Хөсәенов та шундый ир-атлар исемлегенә керә. Ике малай үстергән ата, хатынын бик яратып, аны саклап-кайгыртып гомер итүче ир, эшендә зур уңышларга ирешкән тырыш кеше ул.

Ульян өлкәсенең Иске Кулаткы районындагы Иске Мастяк авылында туып-үскән Сәит әфәнде, армия хезмәтен тутырып кайткач, Куйбышевка килеп урнаша. Биредә ул Микоян исемендәге инженер-төзелеш институтының кичке бүлегенә укырга керә һәм авиация заводында эшли башлый. Башта мастер, аннан соң өлкән мастер була.

Биредә 18 ел хезмәт итү дәверендә акыллы, башлы, җаваплы, эш сөючән милләттәшебез хезмәткәрләре алдында да, җитәкчеләре алдында да зур хөрмәт, абруй казана. Ул, рационаллаштыручы һәм уйлап табучы буларак, 16 яңа технологияне булдыра, һәм аларның барысы да рәсми рәвештә җитештерүгә кертелә.

Ә авыр 90нчы еллар килеп җиткәч, авиация заводында зур кыенлыклар барлыкка килә, һәм Сәит әфәнде башка эш эзләргә мәҗбүр була.

“Заводтагы хезмәтем күңелемә бик якын иде. Кызганычка, ул вакытларда туган авырлыклар аркасында аннан китәргә туры килде шул. Авиацияне шулкадәр яраттым ки, әле дә, һавада очкычларны күргәч, йөрәгем дулкынланып тибә башлый”, - ди әңгәмәдәшем.






Үз эшен югары дәрәҗәдә башкарган Сәит Хөсәеновнең фотосурәте заводның Мактау тактасыннан төшми. Биредә ул цех комитеты әгъзасы булып тора. Гадел милләттәшебезне торак-көнкүреш комиссиясе рәисе итеп тә куялар. Әлеге комиссия хезмәткәрләрне чиратлап фатир белән тәэмин итү эшен алып бара торган була.

Заводтан киткәч, Сәит әфәнде “Сок” дип аталган төзелеш компаниясенә урнаша. Биредә хезмәтен мастер буларак башлап җибәрә, соңрак прораб, участок башлыгы, баш инженерның урынбасары дәрәҗәләренә күтәрелә. Әлеге фирмада 17 ел эшләп, лаеклы ялга чыга.

“Самарда, Тольяттида, Ульян, Пенза, Саратов өлкәләрендә бик күп торак йортлар һәм сәнәгать объектлары төзедек без. Төзүченең эше – ул иҗади хезмәт бит. Миңа, кешеләргә уңай шартлар тудыру өчен, ниндидер яңалыклар кертү, иҗат итү ошый иде”, - ди Сәит әфәнде.

Кайда гына эшләмәсен, Хөсәенов хезмәтен чын күңелдән, җиренә җиткереп, тырышып, зур җаваплылык белән башкара. Шуңа күрә авиация заводында көч куйганда да, “Сок” компаниясендә дә күп Мактаунамәләр белән бүләкләнә ул.

Бүгенге көндә Сәит әфәнде “Бауторг” фирмасында директор урынбасары булып эшли. Алар шәһәребезнең “Самаралакто”, “СамПо” һәм башка предприятиеләрендә суыткыч җайланмаларын урнаштыру белән шөгыльләнәләр.

***- Сәит абый, бигрәк эш сөючән инде сез. Һәр җирдә дә үзегезне бары тик яхшы яктан гына күрсәткәнсез, зур уңышларга ирешкәнсез. Димәк, сездә балачактан хезмәткә мәхәббәт тәрбияләп үстерделәр?*** – дип мөрәҗәгать иттем әңгәмәдәшемә.

- Әйе, дөрес әйтәсез. Без, җиде бала – биш кыз, ике малай, кечкенәдән әти-әниебезнең кул арасына кереп, йорт хуҗалыгында кайнап үстек. Авыр еллар. Тырышырга, көн күрергә кирәк иде. Күпләп мал асрарга, зур бакча тотарга туры килде.

Әтиебезне армиядә булган чагында фронтка алганнар. Әле сугыштан соң үзен ике елга Кытайга җибәргәннәр. Шулай итеп, ул, авылдан хезмәт итәргә чыгып киткәч, тугыз елдан соң гына туган җиренә әйләнеп кайткан.

Әти балтачы иде. Әни, җиде баланы карап, өй-йорт эшләрендә кайнап яшәде.

Әтием Кәшафкә, әнием Хәлифәгә бик рәхмәтлебез. Алар безгә үз үрнәкләрендә лаеклы тәрбия бирделәр, әлхәмдүлилләһ. Чама белән таләпчәнлек, чама белән йомшаклык күрсәттеләр. Яхшы укырга, тыңларга, эшләргә, кеше алдында оятка калырлык булмасын, дип өйрәттеләр. Урлау, тәмәке тарту, эчүнең никадәр начар гадәт, гөнаһ булуын әйтеп тордылар.

“Сәит бик тәртипле гаиләдән. Аның әтисе дә тартмый, эчми иде, - дип сүзгә кушылды аның хатыны Наилә апа. – Балаларына да күркәм сыйфатлар сеңдерә алганнар алар. Ирем, Аллаһыга шөкер, үз гомерендә авызына бер тәмәке капмады, беркайчан да хәмер эчеп кайтмады. Хатын-кыз өчен бу да зур бәхет бит”.

Ә Наилә апага 22 яшендә өйләнгән икән Сәит абый. Бер авылдан, бер мәктәптә белем алганнар алар. Егет кызны әле укыган чакларында ук ошатып йөргән. Ә инде армиядән кайтып, Куйбышевка урнашкач, алар очрашып йөри башлаганнар. Наилә апа ул вакытта Ульян шәһәренең медицина училищесын тәмамлаган. Бер елдан соң мәхәббәт утында янган яшьләр өйләнешергә булганнар.

***- Хатыныгызның нинди сыйфатларына кызыктыгыз?*** – дип сорыйм Сәит абыйдан.

- Чибәрлегеннән тыш, аның матур күңеле әсир итте мине. Ул шундый тәмле итеп, ипле сөйләшә ки, бөтен дөньяны онытып, аны тыңлап торасың. Тыныч холыклы, сабыр, олы җанлы, юмарт, ярдәмчел кеше. Иҗади шәхес буларак, нечкә күңелле. Ул шигырьләр, хикәяләр яза. Туган авылына багышлап, ике китап бастырды.







Аларны Иске Мастяк халкына садака итеп өләште.

***- Яши торгач, бу сыйфатларына тагын ниндиләре кушылды?***

- Наилә мине аңлап, ихтирам итеп, зурлап, ир итә белеп яши. Без әйтерсең лә бер-беребез өчен туганбыз. Тормышыбыз аһәңле, әлхәмдүлилләһ. Бер-беребезне яратып, кадерләп, бер-беребезнең фикерен хөрмәт итеп, менә инде 43 ел бергә гомер итәбез. Балаларыбызга, оныкларыбызга матур үрнәк күрсәтергә тырышабыз.

***- Ә улларыгызны тәрбияләүдә күбрәк кем катнашты – сезме, хатыныгызмы?***

- Мин күп вакыт эштә булганга, әлбәттә инде, балаларны күбрәк Наилә карады. Һәм аларга яхшы тәрбия биргәне өчен мин аңарга рәхмәтлемен.

Безне үз әти-әниләребез ничек үстерде, без дә Элмир белән Русланга шундый тәрбия бирергә тырыштык. Мактанып әйтүем түгел. Мине армиядә хезмәт иткәндә дә, авиация заводында эшләгәндә дә гел үрнәккә куялар иде. Бу – әти-әнием тәрбиясенең нәтиҗәсе, дип белдерәсем килә.

Нарасыйлар белән аңлату эшләре алып бару, үзләре белән сөйләшү, әхлак нормаларын җиткерү дә кирәк, әлбәттә. Әмма сүз белән әйтү – ул бер нәрсә, ә кайчан алар үз күзләре белән күреп үсәләр, бу инде күпкә нәтиҗәлерәк. Шуңа күрә, иң беренче, үзең үрнәк булырга тиешсең. Юкка гына: “Оясында ни күрсә – очканында шул була”, дип әйтмиләр бит инде.

Безнең үз әти-әниебезгә күрсәтеп яшәгән мөнәсәбәтебез дә яхшы үрнәк булды. Мәсәлән, Наиләнең сукыр әнисе берничә ел бездә урын өстендә ятты. Аны яхшылап карап, тәрбияләп, соңгы юлга озатканны балаларыбыз да, оныкларыбыз да күрде.

Аллаһыга шөкер, улларыбыз тәүфыйклы, акыллы, зарлана алмыйбыз.

Элмир үз фирмасын ачып җибәрде. Киленебез Юлия белән матур тормыш алып баралар, бер кыз, ике малай үстерәләр. Баланың баласы балдан татлы, диләр. Бу, чыннан да, шулай икән. Оныкларыбыз Ясминә, Сәлим, Мәликне өзелеп яратабыз.

Русланыбыз - полиция офицеры, әлегә өйләнмәгән.

Ике малаебыз – безнең таянычыбыз, терәгебез. Көненә берничә тапкыр шалтыратып, хәлләребезне белеп, ярдәмнәрен күрсәтеп, икмәк сыныгын да безнең белән бүлешеп яшиләр, безгә карата бик игътибарлылар, Аллаһыга шөкер.

***- Ә үзегез кемнәрдән дә булса үрнәк алдыгызмы?***

- Заводта эшләгәндә түрәләр арасында шундый кешеләр бар иде.

Наиләнең әнисенең бертуган сеңелләре гомер буена безгә үрнәк булдылар. Сәидә апа белән Ришат абыйдан, Мәүҗүдә ападан күп нәрсәләргә өйрәндек. Кызганычка, Мәүҗүдә апабыз якты дөньядан китеп барды. Сәидә апа белән Ришат абый да картлар инде хәзер, безнең дә яшебез бар, әмма бүген дә бу акыллы, күпне күргән, тәҗрибәле кешеләрнең асыл фикерләрен күңел түренә салып яшибез.

***- Ир белән хатын бер-берсеннән нәрсәгә булса да өйрәнеп яшиләр бит. Ә сез Наилә ападанниләргә өйрәндегез?***

- Сабырлыкка. Мин - тиз кызып китә торган кеше. Ә ул, һәрвакыт түземлек күрсәтеп, барысын да иплән, тыныч кына җиткерә. Күп вакыт сүз дәшмичә калсаң, яхшырак икән бит. Ә мин моны инде кызып китеп, суынгач кына аңлыйм.

Әлхәмдүлилләһ, хәләл җефетем дин юлында. Самар Җәмигъ мәсҗидендә танылган остаз - Сания ханым Мингачевада белем алды. Гыйбадәт кыла, Коръән укый.

Раббыбыз: “Ир белән хатын бер-берсенә дус. Алар бер-берсен хәерлегә өндәп, гөнаһлардан тыярга бурычлы”, – дигән бит. Наилә мине дингә җәлеп итә. Аңардан догалар өйрәнәм, Ислам турында мәгълүмат үзләштерәм.

***- Сезнеңчә, матур тормыш алып барыр өчен, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш?***








- Бер-береңә ышаныч белдерүне мөһим саныйм. Бер-береңне тыңлый, ишетә белергә, вакытында юл бирергә, хөрмәт белән карарга кирәк.

***- Сезнең өчен гаилә яисә карьера мөһимрәк булдымы?***

- Гаиләне һәрвакыт беренче урынга куйдым мин. Хезмәт баскычыннан күтәрелер өчен мөмкинлекләр күп булды. Башка шәһәргә дә чакырдылар үземне. Әмма мин хатыным, балаларым янында булырга теләдем. Һәм моңа бер дә үкенмим.

***- Оныкларыгызны тәрбияләүдә катнашасызмы?***

- Әйе, әлбәттә. Алар бездә еш кунакта булалар. Үзләренә әхлак орлыкларын салырга тырышабыз. Наилә үзләренә дини тәрбия бирә. Җиде яшьлек оныгыбыз Ясминә күп догаларны белә инде. Кечкенәләренә дә Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген аңлатабыз. Үзара дус булырга, бер-берсенә юл куярга, әти-әниләрен тыңларга кирәк, дип туглап торабыз.

Татар телен өйрәтәбез. Бездә "бабушка", "дедушка" сүзләре юк. Әбекәем, бабакаем, дип кенә эндәшәләр.

***- Чын ир-атка нинди сыйфатлар хас булырга тиеш, дип саныйсыз?***

- Әйткән сүзендә торырга. Вәгъдә бирдең икән, син аны башкарырга тиеш. Гаиләсен тулысынча тәэмин итәргә, тормыш дилбегәсен тартып барырга. Хатынына, балаларына карата миһербанлы булырга, аларны саклап-яклап яшәргә, үзләренә яман сүзләр әйтмәскә, рәнҗетмәскә.

***- Яшь егетләргә үзләренә яр сайлаганда нәрсәләр киңәш итәр идегез?***

- Мәхәббәт нинди генә көчле булмасын, башны югалтмаска киңәш итәр идем. Үз ишеңне эзләргә кирәк. Ул сине аңласын, ихтирам итсен, уртага салып сөйләшерлек темалар булсын. Пар канатыңны төрле хәлләрдә сынап карау да артык түгел. Башта бер-береңне яхшылап белергә кирәк.

Менә без Наилә белән бер авылда туып-үстек, бер-беребезнең нәселләрен белә идек. Бер мәктәптә укыдык. Яратуыбыз көчле булса да, бер ел очрашып йөргәндә дә бер-беребезне игътибар белән күзәттек. Һәм аның белән пар килгәнебезгә Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер.

"Ә мин кызларга киңәш бирер идем, - дип сүзгә кушылды Наилә ханым. – Гомерлек ярыгызны сайлаганда, иң беренче чиратта, шуңа игътибар итегез – ул үз сүзендә торамы, юкмы. Ир-ат, һичшиксез, вәгъдәсен үтәргә тиеш! Шуны да күздә тотарга кирәк – сез булачак балаларыгызның этисен сайлыйсыз. Ул аларга нәрсә бирә, аларны нәрсәгә өйрәтә алачак? Буш кеше нарасыйларына бернәрсә дә бирә алмаячак ул.

Ир рухи яктан синнән көчлерәк булсын, чөнки ул - гаилә башлыгы, төрле мәсьәләләрне чишүче, проблемнарны хәл итүче.

Шулай ук, өстәл янына утырып, синең белән эчтәлекле әңгәмә кора белерлек булсын".

***- Ә сез Сәит абыйның нинди сыйфатларын ошаттыгыз?*** – дип сорадым Наиләападан.

- Миңа карата бик илтифатлы булды ул. Аңардан ихтирамлылык, чын мәхәббәт тойдым. Тәртипле, акыллы, ышанычлы, максатка омтылышлы, тотрыклы, җитди, төпле булуы ошады.

Һәм аңа кияүгә чыкканыма бер генә дә үкенмәдем. Мине өрмәгән җиргә утыртмады, кадер-хөрмәттә яшәтте. Аңардан бер әшәке сүз ишетмәдем. Тырышып эшләде, мал тапты, әллә ни бай булмасак та, бернәрсәгә дә кытлык кичермәдек. Балаларга яхшы әти булды. Сәит белән мин бәхетле.

***- Кайбер кешеләр, үзләренең билгеле бер мәнфәгатьләрен күздә тотып, мәхәббәтсез генә дә өйләнешергә мөмкиннәр. Ә сезнең өчен тормыш корганда сөю мөһим булдымы?*** – дип кызыксындым язмам героеннан.

- Мәхәббәт дигән очар кош бардыр, канатлары пардыр. Сөю булмаса, мин өйләнә алмас идем. Әгәр дә инде өйләнсәм, бәхетле була алмас идем. Наиләне мәктәп елларыннан ошатып йөрдем, аңа чын күңелдән гашыйк булдым. Һәм шушы мәхәббәтне гомер аша үткәреп, саклап яшим. Торган саен, ул тәмләнә дә төште әле. Ник дисәгез, яшь чактагы сөюгә тирән хөрмәт хисе дә килеп кушылды. Нәкъ шушылар гаиләнең нигезе булып торалар, аны ныклы, бәхетле итәләр дә инде.



# АВЫЛНЫҢ МАТУРЛЫГЫН, АНЫҢ БӘРӘКӘТЕН ШУНДА ЯШӘГӘН КЕШЕЛӘР БУЛДЫРА

***Татарлар, табигать балалары буларак, җирне кадерләп, андагы бар нәрсәне изгеләштереп, гасырлар дәвамында шуларга сокланып яшәгәннәр. Кайда гына төпләнсәләр дә, алар чишмәләргә, күлләргә, әрәмәләргә, урманнарга, болыннарга бай, иң матур һәм иркен җирләрне сайлаганнар.***

***Фәрид Шириязданов.***

Иске Ярмәк авылы нәкъ менә шундый гүзәл табигать почмагында урнашкан. Аның төньягында салкын җилләрдән саклаучы таулар баскан. Авылны кочып алгандай, таулар итәгеннән Сок елгасы ага. Бу инде үзе генә дә борынгы бабаларыбызның никадәр хисләргә бай халык булганлыгы турында сөйли.

Шуңа да хәзер анда яшәгән халыкның җыр-моңга һәм төрле сәләтләргә бай булуы - ул табигый күренеш. Бүгенге көндә байтак җирләрдә татарлык рухының сүрелә баруы бераз көендерсә дә, Иске Ярмәк авылында төрле милли-мәдәни чараларның гөрләп узуы киләчәгебезгә ышаныч тудыра, башкаларны да моңсу уйлардан арындыра.

Бу авылда берсеннән-берсе матур өйләр төзелүе һәм анда яшәгән халык арасында тормыш кирәк-яраклары ясаучы эшмәкәрләр, оста куллы кешеләр арта баруы хәзерге дөньяга таралган өметсезлектән саклый, ямансу уйлардан коткара һәм киләчәккә ышаныч тудыра.

Кешенең эчке дөньясы нинди булуы аның тышкы кыяфәтендә, йөзендә, күз карашында чагыла. Тормыш матурлыгы, иң элек, кеше күңелендә ярала, һәм шуннан соң гына ул канатлы хыяллар ярдәмендә дөньяга туа.

Боларны уйлаганда шушы авылда яшәгән Шәүкәт һәм Гөлисә Бәтретдиновлар, алар йортындагы, өй эчендәге пөхтәлек, матурлык күз алдына килә.



Авылдагы универмаг каршында урнашкан ул йорт хәзер урамның матур бер бизәге булып тора. Ә элгәре бу урында кечкенә, мескен һәм таушалган-чалышайган өй басып тора иде бит! Шәүкәт һәм Гөлисә, аны сүтеп, шул урында



үз йортларын кордылар һәм тора-бара аны гүзәллек почмагына әйләндерделәр.

Бөтен ил зур бер базарга әверелгәндә дә, алар сату-алу белән дә мавыкмады, Себерләргә китеп, баеп кайтырга да тырышмады. Шәүкәт, остаханә корып, һөнәрләр үзләштереп, халыкка тормыш кирәк-яраклары, төрле җиһазлар булдыру эшенә алынды. «Тәвәккәл таш яра!» - дигәндәй, дөньялар буталган чакта да, ул уңай тормыш итү юлларын табарга тырышты. Ул әле дә яңа омтылышлар, хыяллар белән янып, яңадан-яңа планнар корып яши.

Тормышта күргәнебезчә, һәркем дә үз өендә һәм йортында чәчәкләр үстерә алмый. Бу гади генә эш булып күренсә дә, ул турыдан-туры кеше күңеленең баймы-ярлымы булуына бәйләнгән. Шәүкәт йортындагы төрле чәчкәләр, хикмәтле үсемлекләр генә түгел, хәтта сукмак буендагы тимердән коеп ясаган чәчкәле бизәкләр дә сокландыра.

Төрле сәләтләргә ия булу бәхете ул кемгәдер күбрәк, ә башкаларга азрак бирелә. Тик боларны тормышта кулланып, гамәлгә ашыру һәм, тормышны гөрләтеп кору өчен, тырышлык, үҗәтлек, күңел байлыгы һәм матур хыяллар белән яши белү дә кирәк.

Ә башка кешеләр күңелендә дә матур тойгылар уятып, аларның җаннарын рухландыру сәләте сирәк кешегә бирелә. Шәүкәтнең хатыны Гөлисә - менә шундыйлардан.

Ул авыл халкына социаль хезмәт күрсәтү оешмасында эшли. Актив җәмәгать эшлеклесе булганга, авылдагы бер генә бәйрәм, тантаналы чаралар һәм төрле очрашулар



*Мисбах бабай һәм Мәйсәрвәр әби – эш сөючеләр, данлыклы бакчачылар*





- берсе дә аның катнашыннан башка узмый. Ул аларны әзерли, оештыра һәм матур, җанлы рәвештә алып бара. Гөлисә эшләгән социаль хезмәт күрсәтү оешмасы да хәзерге көндә лаеклы рәвештә авылның рухи үзәгенә әверелде.

Гөлисә алып барган интернет группасында да бу авылда булган хәбәрләр, ниндидер яңалыклар, элгәре булып узган һәм хәзерге мөһим булган хәлләрнең берсе дә читтә калмый. Ул аларны матур итеп халыкка җиткерә һәм авыл киләчәктә дә матур булсын, аның халкы якты өметләр белән яшәсен өчен бар көчен куя.

Иске Ярмәк авылында халкыбыз өчен иң авыр, дәһшәтле заманнарда төрле җирләрдән күчеп килгән халык төпләнгән. Аларның һәркайсысы үзе белән ниндидер матур яңалык, осталык һәм башка милли хәзинәләр алып килгән. Нәтиҗәдә тора-бара авыл җәмгыяте, матур бер чәчәк бәйләменә охшап, әлегәчә шиңмичә, сакланып килгән.

Шуңа да хәзерге көндә ул - үзендә канатлы күңелле кешеләр яшәве белән танылган данлыклы авыл. Анда борынгыдан килгән милли һәм рухи хәзинәләр кадерләп саклана. Авыл халкы шул изге мирасны тагын да үстереп, аңа матур өстәмәләр кертеп, тулыландырып килде һәм бу юлда ирешкән уңышларына куанып яшәде һәм яши.

Дөрес, хәзерге буталчык замандагы рухи төшенкелек артканда, күп җирләрдә тормыш сүрелә, буш өйләр арта бара. Иске Ярмәк авылын да бу шаукымлы җилләр урап узмады, анда да шактый өйләр бушап калды. Тик шулай да монда хәзерге вакытта искиткеч матур өйләрнең арта баруы күңелне юандыра һәм киләчәккә өмет тудыра.

Менә шундый хәлиткеч вакытта халык күңелен төшенкелектән саклау - аеруча мөһим, җаваплы эш. Бу юлда Гөлисә һәм аның хезмәттәшләре, фикердәшләре халык күңелен үстерү, аны төшенкелектән саклау өчен бар куәткә тырышалар.

Уңганлык-тырышлык, чисталык-пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар татарларда борынгыдан сакланып килгән. Шәүкәт һәм Гөлисә Бәтретдиновлар тормышында болар аеруча ачык күренә. Бернәрсә дә юктан бар булмаган кебек, алар йортындагы муллык, гүзәллек - барысы да тырышлык, уңганлык нәтиҗәсе. Боларны күргәндә ирексездән Шәүкәтнең Мисбах бабасы күз алдына килә.

1950 елларда ул авылда данлыклы бакчачы булып танылган, уңган кеше иде. Татарлар эшчән, оста куллы халык булсалар да, ул чакта никтер яшелчә үстерү белән шөгыльләнмиләр иде. Һәр йортта бакча тутырып борай (полба) чәчү генә гадәткә кергән иде. Шул елларда авылда бары тик берничә кеше генә җиләк-җимеш, яшелчә үстерде. Шуларның берсе - Мисбах бабай. Кечкенә чакта аларга баргач, гомеремдә беренче тапкыр помидор ашаганым әле дә хәтердә.

Ул үзенең тау битендәге бакчасында ниләр генә үстерми иде: кыяр, помидор, кәбестә һәм башка яшелчәләрне. Шул бакча артында җәелеп киткән күлне халык «Мисбах күле» дип атаган. Ул шуннан тауга чиләкләп су ташып үстергән кыярларны мичкәгә тозлап, яз җиткәч, Сабан туена алып чыга, һәм халык аны чират торып ала иде.

Монда: “Шәүкәткә эшмәкәрлек сәләте кайдан килде икән?” - дип аптырарга урын юк. Башта агачтан ишек-тәрәзәләр, өй һәм йорт җиһазлары ясаса, аннан соң тимердән бизәкле чардуганнар һәм башка зәвыклы әйберләр ясауга алына. Тынгысыз, эзләнүчән буганга, ул үз мөмкинлекләрен төрле яклап сынап карарга тырыша.

Бал кортлары да үрчетә һәм, чәчәктән-чәчәккә күчеп, бал туплаган умарталары кебек, төрле эшләрнең серенә төшенергә, шуларның нечкәлекләрен өйрәнергә тырыша. Мәсәлән, виноград, гадәти булмаган төрле чәчкәләр үстерү кебек һәм башка эшләргә керешә.

Гомумән, Шәүкәт һәм Гөлисә Бәтретдиновлар гаиләсендә хисләргә бай, сәләтле, оста куллы, тормышны бәрәкәтле һәм яшәүне ямьле итәргә тырышучы, хыялый кешеләр яши.

Бу гаиләгә тормышта гүзәллек тудыру сәләте ике яклап та килгән. Мәсәлән, Гөлисәнең Ризатдин исемле бабасының йортындагы зур бакчада үскән җиләк-җимеш үсентеләренә, аның Мөкәрәмә әбисе үстергән матур чәчкәләргә сокланмыйча узу һич тә мөмкин түгел иде. Күп йортлар читән, частакол белән тотылган һәм әле коймалар да сирәк булган чакта аларның бакчасы буяган рәшәткә белән уратылган булды. Ризатдин бабасының яз кояшыдай гел елмаеп торган йөзе кебек, аның йортыбакчасы да гел балкып, урамга ямь биреп торды.

*Хат ташучы килә, хат ташучы!*
*Бала-чага ала сөенче.*
*Һәрбер йортта көтә яше, карты -*
*Рәхмәт сиңа, балам, дию че.*
*Зур сумкасы кулбаш күтәргесез,*
*Сиздерми ул авыр икәнен.*
*Үзе дә белмидер, килә калса,*
*Ничә чакрым юллар үткәнен.*

*Бер сумкада күпме хәбәр ята -*
*Бер сумкада илнең язмышы.*
*Бер сумкада мәхәббәт ярала,*
*Кавышалар хатлар язышып.*
*Чәй эчеп чык, балам, арыгансың...*
*Вакыты юк аның чәйләргә.*
*Хат ташучы... Бар гомере юлда -*
*Юлда көз, кыш, ямьле җәйләр дә.*

*Миләүшә Газимова.*

# ХАТ ТАШУЧЫ... БАР ГОМЕРЕ ЮЛДА - ЮЛДА КӨЗ, КЫШ, ЯМЬЛЕ ҖӘЙЛӘР ДӘ




Язмамны Наилә Әюпова иҗат иткән шушы шигъри юллардан юкка гына башламадым мин. Авылда үскән кыз буларак, балачакта капка төбендә үземнең дә почтальон апаны шатланып каршы алганымны бик яхшы хәтерлим. "Татарстан яшьләре", "Пионерская правда" гәҗитәләреннән тыш, аеруча хатларны зарыгып көтә идем. Ул хәзерге заманда кәрәзле телефон, социаль челтәрләр аша көннәр буе сөйләшергә, язышырга була. Ә элеккегрәк елларда дусларың, туганнарың белән аралашыр өчен хат бердәнбер элемтә чарасы булып торды бит.

Почта тартмасындагы хатны миннән алдарак күреп алып кергән әбием: «Әйдә, бие башта, аннан бирәм!» - дия иде. Андый чакларда инде биеп кенә түгел, җырлап бирергә да риза!

Менә Гали авылында почтальон булып эшләүче милләттәшебез - Рәшит кызы Румия Сәлимова да:

- Хатлар чоры узды шул. Авылда бүген әби-бабайлар сирәк-мирәк кенә еракта яшәүче туганнарына язгалыйлар. Кайчак Яңа ел, Хатын-кызлар бәйрәмнәренә открыткалар җибәрәләр.

Хәзер "сәлам хат"ларын халыкка күбесенчә ГИБДД белән салым инспекциясе генә юллый, - дип сөйли.

Румия апа Оренбург өлкәсендәге Әсәкәй районының







Казанка авылында туып-үскән. Мәктәпне тәмамлагач, Самарга китеп, 4нче подшипниклар заводында контролер булып эшләгән. Аннары тормыш җилләре аны яңадан туган авылына алып кайткан. Ә инде 1991 елда ул Гали авылына килен булып төшкән.

Биредә башта мәктәптә идән юып йөргән. Балалары тугач, башыаягы белән аларны тәрбияләүгә һәм өй-йорт эшләренә чумган.

Менә почтага эшкә урнашуына да 14 ел үтеп киткән инде. Участогы да шактый икән – 270ләп йортка хезмәт күрсәтә ул.

Милләттәшебез белән танышып аралашкач, авыл халкының аны ни өчен яратуын аңладым мин. Румия апа - тыныч холыклы, тыйнак, эчкерсез, мөлаем ханым. Елмаеп кына тора, кешеләргә игътибарлы, үзләре белән ихлас күңелдән, бик ипле, йомшак итеп сөйләшә.

Әйе, почтальон булып эшләүче кешедә әлеге сыйфатларның булуы зарур шул, чөнки алар хат, гәҗитә-журнал китереп кенә китмиләр бит, халык белән әңгәмә дә коралар, хәл-әхвәлләрен дә сорашалар.

- Безнең һөнәр ияләре сабыр булырга, кеше белән уртак тел таба белергә тиеш. Өлкәннәрнең күбесе өйдә ялгызы утыра. Аларга аралашу җитешми. Үзләре белән сөйләшеп тә алабыз, хәбәрләр белән дә уртаклашабыз. Берәр нәрсә кирәксә, шалтыратыгыз, дип телефон номерын да калдырабыз, - ди Румия ханым.

***- Алайса сез әби-бабайларга әле ярдәмче, йомышларын үтәүче дә.***

- Хат ташучыларның вазифалары артты бит. Хәзер почталар кечкенә кибетне хәтерләтә. Биредә канцелярия, химия товарлары да, көнкүреш кирәк-яраклары да сатыла. Сумкабызга шуларны да салып йөрибез. Кемгә нәрсә кирәген алдан белешеп, икенче көнне почта өләшкәндә китереп бирәбез.

Салымнарны, ГИБДД штрафларын, утка-суга, газга, торак өчен акчасын шулай ук безнең аша түлиләр. Пенсия, субсидияләрне дә без таратабыз.

***- Димәк, бүгенге көн почтальоны авылның тоткасы булып тора. Халык, бигрәк тә өлкәннәр, хат ташучыга карап тора, дисәк тә була.***

- Әйе, шулай булып чыга. Авылдашларыма ярдәм итә алганыма шатланам мин. Алардан изге теләкләр, ихлас рәхмәт сүзләрен ишетү канатландырып җибәрә.

***- Шулай да төп хезмәтегез – вакытлы матбугатка яздыру һәм аны өйләргә тарату. Бүгенге көндә авылыгызда гәҗитә-журнал укучылар күпме?***

- Мин почтага урнашкан елларда әбунәчеләр (подписчик) күп иде. Кызганычка, аларның саны елданел кими бара шул. Хәзер мәгълүмат алу чыганаклары артты бит - интернет, телевизор, радио, кәрәзле телефон.

Аннары гәҗитә укучы буын олыгая. Күп әби-бабайлар: “Язылыр идем дә, күзләрем начар күрә шул”, - диләр. Ә яшьләр кирәксенми, интернеттан файдаланалар.

Укыган кеше укый инде ул. Әйтик, укытучыларның күбесе вакытлы матбугатны зарыгып көтеп тора.

Казанда яшәүче авылдашыбыз Дания ханым Тулова үз акчасына мәктәп, китапханә, балалар бакчасын, авыл тормышында актив катнашучыларны татар телендәге гәҗитә-журналларга яздыра.

Кайбер эшкуарлар садака йөзеннән туган-тумачаларына алдыралар.

***- Авылыгызда нинди татар гәҗитәләрен үз итәләр?***

- Казаннан “Акчарлак”, “Ирек мәйданы”, “Авырмас өчен мең дә бер киңәш” басмаларын укыйлар.

Җирле матбугаттан “Сәлам”, “Бердәмлек”не яраталар.

Рус гәҗитәләрен алдыручылар алай күп түгел.

***- Ә үз өегезгә ниндиләр килә?***

- Татарстаннан “Ясминә”, “Авырмас өчен мең дә бер киңәш”, Самар-







дан “Бердәмлек”, “Вестник Похвистневского района” гәҗитәләренә язылам.

***- Бүгенге көндә вакытлы матбугат укучылар саны азаюның сәбәбе нидә, дип уйлыйсыз?***

- Алда әйткәнемчә, бүген күбесе интернеттан чыкмый бит. Мәгълүматны шуннан алалар. Кәрәзле телефон һәркемдә хәзер. Хәтта өлкәннәр арасында да аның белән куллана белүчеләр бар. Фотога да төшәләр, СМС та язалар.

***- Халыкны журнал-гәҗитәгә язылырга өндәлисезме?***

- Әйе. Безгә план куялар бит - аена шулкадәр товар сатарга, шулкадәр басмага яздырырга тиешбез. Планны үтәмәсәң, эш хакы да азрак була, премиядән дә калырга мөмкинсең. Рәхмәт яугыры, хәлебезне аңлаган кайбер олы кешеләр: “Күзем күрмәсә дә, язылам инде, кызым, сиңа да бездән ярдәм булсын”, - дип хат ташучыларга үзләренчә булышалар.

***- Бар мәгълүмат электрон версиягә күчеп барган заманада почта бүлекләре кирәкме? Сезнеңчә, һөнәрегезнең киләчәге бармы?***

- Яшьләргә бик кирәге булмастыр да, алар күбрәк онлайн-түләүләрдән файдалана бит. Ә менә өйдән чыгып йөрергә кыенсынган өлкән буын почтальон хезмәтенә мохтаҗ, дип саныйм. Әйткәнемчә, пенсияне, кирәкле товарларны да китереп бирәбез, коммуналь хезмәтләр өчен дә безнең аша түлиләр, гәҗитә-журнал да укыйлар.

***- Румия апа, мәктәптә татар телен өйрәнмәгәнсез, ә үзегез ана телендә шундый матур итеп сөйләшәсез...***

- Кечкенәдән гаиләдә татарча аралашып үстек без. Әнием “Азат хатын” журналын яздырып ала иде. Шуннан күп әдәби сүзләрне өйрәндем.

Аллаһыга шөкер, улыбыз, кызыбыз да туган телен яхшы беләләр, телләре татарча ачылды.

***- Балалар, дигәннән. Гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде.***

- Ирем Усман белән 31 ел бергә гомер итәбез. Ул – тыныч холыклы, киң күңелле, бик тәртипле кеше, яхшы нәселдән. Миңа һәрнәрсәдә ярдәм итә. Хатын-кызның бәхете – ирдән, диләр. Дөрес ул. Аллаһыга шөкер, хәләл җефетем белән матур тормыш алып барабыз. Мин аңа бик рәхмәтлемен.

Улыбыз Таһир, кызыбыз Алсу, югары уку йортларында бюджет урыннарда укып, Самарда эшлиләр. Әлхәмдүлилләһ, йөзебезгә кызыллык китергәннәре булмады, тырыш, эш сөючән, тәүфыйклы булып үстеләр. Ял көннәрендә кайтып, өй-йорт эшләрендә булышып торалар.

***- Хуҗалыгыгыз зурмы соң?***

- Әйе, маллар асрыйбыз, бакчада төрледән-төрле яшелчә үстерәбез. Сөт, каймагын, бәрәңге, кишер, суган, чөгендерен сатуга чыгарабыз. Самарга ярминкәләргә дә баргалыйбыз.

Йорт хуҗалыгы күбрәк ирем җилкәсендә. Раббым үзенә исәнлек-саулык бирсен инде.

***- Эшегез бик авыр, аңардан арып, ташлап китәргә теләгән чакларыгыз буламы?***

- Хәзер ничә еллар эшләп күндем инде. Минем хезмәттән файдаланган авылдашларым якын кешеләремә әйләнделәр. Алда әйтеп үткәнемчә, аларга ярдәм итә алуыма сөенәм.

Коллективыбыз да бик дус. Җитәкчебез Рания Низаметдинова, хат ташучылар Фәнүзә Насретдинова, Оксана Дускаева, оператор Руфия Латыйпова белән бер-беребезгә булышып, күңелле итеп, рәхәтләнеп эшлибез, Аллаһыга шөкер.

***- Киләчәктә дә дәрт-дәрманыгыз сүрелмәсен, Румия апа!***

Әйе, кышкы зәмһәрир суыкта, күз ачмаслык бураннарда да, язгы-көзге пычракларда, эссе җәйләрдә дә юлда хат ташучылар.

Заманалар үзгәреп, алга таба барса да, почтальон һаман җәяү, һаман җилкәсендә авыр сумка.

Үз хәлләрен үзләре генә белсә дә, зарланмыйлар алар. Халыкка хезмәт итүләренә куанып эшли бирәләр...

# ПРЕДВЕСТНИКИ БЛАГОПОЛУЧИЯ



*В постсоветское время села и сельское хозяйство переживали не самые свои лучшие времена. На протяжении десятилетий истинные хлеборобы были отлучены от своей земли. Земля во многих хозяйствах осиротела, а богатейшие черноземы стали прорастать сорняками.*

***Фарид Шириязданов***

Слава Всевышнему, сейчас в общественном сознании начинает укрепляться понимание того, что села – это животворящие источники, без которых невозможно представить современную жизнь. Ведь хлеб растет не в городах, да и то же мясо или молоко тоже невозможно производить в отрыве от земли, от сельского хозяйства.

В условиях всеобщего обвала все же были хозяйства, которым удалось выжить, и сегодня они успешно развиваются. Одно из них – сельскохозяйственный производственный кооператив (СПК) «Степно-Шенталинский» в Кошкинском районе. Его возглавляет Рамиль Дамирович Гиззатуллин, совсем не похожий на тот сложившийся в воображении многих стереотип сурового и внушительного начальника, резкого в выражениях и суждениях, не терпящего возражений. Рамиль Дамирович – представитель совершенно новой формации руководителей, в характеристике которого, наоборот, указали бы, что он вежлив в общении, отметили бы, что он уважителен в отношении к любому человеку. А если без характеристик, то, как руководитель он, конечно же, требователен, но при этом воспитание, образование, а, может, и просто жизненные принципы не позволяют ему терять свою человечность, веру в людей и, конечно же, в успех своего дела.

Именно Гиззатулин превратил сельскохозяйственный кооператив «Степно Шенталинский» в четко отлаженный механизм, коллектив которого сравним с дружной, работящей семьей. Может, это и не модно в наше время, но в его хозяйстве во всем просматривается чувство коллективизма, трепетное отношение к земле и уважение к труду земледельцев. Разработаны прогрессивные нормы оплаты труда, меры морального и материального стимулирования. Взаимосогласие, уважение и поддержка друг друга здесь давно стали нормой. Человек, оказавшийся в таком коллективе, просто не сможет работать спустя рукава. Сама атмосфера, царившая в этом коллективе, вдохновляет и настраивает на созидание и самоотдачу каждого работника. А по-другому здесь нельзя. Совесть не позволит. Ведь работать на земле – значит быть ответственным за судьбу будущего урожая. Здесь малейшая оплошность, недоработка, упущение сроков, пренебрежение тонкостями земледелия могут обернуться серьезным провалом.

Рамиль Дамирович из той породы руководителей, которая все силы и знания без остатка отдает работе и до тонкостей знает свое дело. Свою судьбу он связал с сельским хозяйством. Почему? А потому, что он родился на этой земле и рос в семье истинных сельских тружеников. Перед глазами всегда пример родителей. Отец, Дамир Хайруллович, – всю жизнь проработал шофером в колхозе, а мать, Фания апа, работала дояркой, телятницей и на других участках, где без ответственности и трудолюбия ну никак. Наверное, именно, поэтому все три брата, родившиеся в этой семье, выросли приученными к любому виду сельского труда, скромными, но при этом способными брать на себя ответственность не только за себя, но и за тех, с кем они вместе работают. Таким был и дед Рамиля Хайрулла, ставшим одним из первых председателей колхоза, когда они только-только начали создаваться. Так что организовывать сельхозпроизводство и успешно его вести – это у Рамиля Гиззатуллина, видимо, в крови.

Однако без образования гор не свернешь. После окончания Ульяновского сельхозинститута Рамиль вернулся на свою малую родину и приступил к работе инженером в колхозе «Шенталинский». Но с наступлением крутых перемен этот колхоз, куда входили три села, был разделен на части. Произошло это без необходимого для этого экономического обоснования и учета дальнейшей перспективы хозяйственной деятельности. Таким образом отлаженное хозяйство было

разрезано по живому. После раздела Рамиля Гиззатуллина избрали председателем одного из вновь созданных колхозов, который базировался в селе Степная Шентала. Практически заново пришлось выстраивать новую структуру в совершенно новых условиях, менять форму собственности, юридический статус и заново выстраивать отношения с собственниками земли и партнерами.

Сказать, что было трудно, – значит ничего не сказать. Справились. Все осталось позади. Сегодня СПК «Степно-Шенталинский» – успешное хозяйство, производственные циклы которого базируются на современных технологиях, мировом опыте и научных достижениях. Рамиль Гизатуллин ежегодно внедряет инновационные технологии, сотрудничает с профессорским составом университетов, занимающихся селекцией растений. В хозяйстве планомерно внедряются в производство новые сорта, адаптированные к нашим природным условиям и востребованные на рынке сбыта. Хозяйство оснастили современной техникой и технологическим оборудованием. Сегодня здесь самое серьезное внимание уделяется качеству подготовки кадров и их своевременному переобучению в условиях технического перевооружения и технологического роста, развитию сельхозпроизводства.

Современная агротехника и новые технические средства требуют своевременного выполнения всех производственных циклов, а значит, есть и жесткие сроки. Поэтому для бесперебойной работы в этом коллективе существует полная взаимозаменяемость среди работников. При необходимости Рамиль и сам в любой момент может сесть на любую технику и продолжить работу, не допуская перебоя.

Поражают воображение выстроенные здесь социальные принципы. В кабинете председателя кооператива на видном месте висит список работников, где указаны время и даты рождения каждого работника. Подарок, предназначенный юбиляру, они оговаривают заранее. Обычно он подбираются из числа предметов первой необходимости той или иной семьи. Праздники и дни рождения здесь также празднуют сообща. Рамиль Гиззатуллин знает, какими чаяниями живут его сотрудники, в чем они нуждаются. При необходимости он незамедлительно спешит оказать помощь и поддержку каждому своему сотруднику. В его хозяйстве созданы такие условия, при которых каждый член его коллектива в своем личном хозяйстве может содержать столько скота и живности, на сколько хватает его сил и способностей. Тут по сходной цене выписывают фуражное зерно и специально засевают травы на корм скоту, содержащемуся в их личных подворьях. Созданы условия, чтобы труженики полей трудились, вкладывая душу, что особенно важно в работе хлебороба. Только тогда и земля, в знак благодарности за их труд и заботу, может одарить их высокими урожаями. Немаловажным залогом успешной работы СПК является кооперативная форма организации производства. Здесь каждый является совладельцем собственности и заинтересован в конечном результате. Как показывает опыт, такой подход является основой подъема и расширения производства.


*Рамиль с братьями, папой и мамой*

Рамиль Дамирович немногословен, деловит и не любит тратить время на пустые разговоры. Заслуженное уважение и его не менее заслуженный непререкаемый авторитет помогли ему неоднократно избираться депутатом в местные органы власти.

Плечо к плечу со своим мужем, разделяя все радости и невзгоды по жизни, с Дамиром Гизатуллиным идет его жена Алсу. Будучи главным бухгалтером ПСК «Степно-Шенталинский», она грамотно выстраивает все финансовые отношения в хозяйстве, обеспечивая надежную экономическую основу производственной деятельности коллектива. Чета Гизатуллиных вместе уже 37 лет, и они давно уже являются дедушкой и бабушкой. Основной гордостью семьи, как и принято, являются их дети. Сын Юнус окончил СамГТУ. Работал региональным представителем строительной фирмы «Сворог». Под его началом было построено более 30 государственных и коммерческих объектов. Свободно владел немецким и английским языками. Любил татарское народное творчество. Был целеустремленным, честным и обладал веселым характером. К сожалению, трагическая случайность оборвала жизнь этого яркого и талантливого человека в самом его расцвете.

Дочь – Лилия Рамильевна, имеет три высших образования и является кандидатом исторических наук. Вносит значительный вклад в развитие науки и образования, работая в УлГУ. Ее карьерный рост не стал преградой для материнства. Двое детей, которые учатся на «5» и «4», занимаются спортом и музыкой.

Сейчас, когда низвергнута общественная мораль и каждый склонен думать только о своем благе, к нашему счастью, есть еще такие коллективы, как ПСК «Степно-Шенталинский». Их немного, но хочется верить, что именно вот они и являются предвестниками будущего благополучия.

# “Хәйриячелек белән шөгыльләнә башлагач, рухи яктан байый төштем”



***Мәгълүм ки, һәр хатын-кызның чибәр буласы килә. Шуңа күрә, гүзәллеген ассызыкларга теләп, ул чәчен кистерә, кашларын, тырнакларын буйый, бизәнә-ясана. Әлбәттә инде, заманча ханымнар, туташлар моның өчен һөнәрмәндләргә мөрәҗәгать итәләр.***

*Миләүшә Газимова.*

Хәмит кызы Розалия Якупова – хатын-кызларның матурлыгын ассызыклый торган осталарның берсе.

Ул шәһәребезнең “Curly hair” (Көдрә чәчләр) салонында чәчтарашчы булып эшли. Өстәвенә, әле кашлар да, макияж да, прическалар да ясый.

Матур күңелле, күркәм холыклы татар кызы, дияр идем мин аның турында.



Ул үзе дә: “Кешеләргә нәрсәдер бирер өчен, иң беренче чиратта, үзең рухи яктан бай булырга тиешсең”, - ди.

Розалия дин таләпләрен үтәп яшәргә тырыша. Ураза тота, Ислам нигезләрен, намаз серләрен үзләштерә. Дини китаплар укый.

Гомумән, ул гел үсештә, актив яшәү рәвеше алып бара, мавыгулары да күп аның.

Розалия хәйриячелек белән дә шөгыльләнә бит әле. Самарның “Ровесник” дип аталган балалар йортына йөреп, анда тәрбияләнүче нарасыйларның һәм үзе эшләгән салонда Даун синдромы булган малайлар, кызларның чәчләрен бушлай кисә.

Яшь милләттәшебез белән шуларның барысы турында да серләшеп утырдык без.







***- Розалия, нигә нәкъ менә чәчтарашчы булырга теләдең икән? Матурлык өлкәсендәге эшең нәрсәдән башланып китте?***

- Бу - иҗади хезмәт бит. Ә мин – иҗади шәхес. Сәнгать мәктәбендә рәсем ясау сабакларын үзләштердем. Самарның дизайн һәм сервис технологияләре көллиятендә (колледж) дизайнерга укыдым, аннары Санкт-Петербург университетында реклама белгечлеген үзләштердем.

Берничә ел дизайнер булып эшләдем. Әмма тора-бара офис эше җаныма ятмаганлыгын аңладым. Күңелем буш, миңа нәрсәдер җитми сыман тоела иде.

Кул белән эшләргә яратам мин. Шуннан уйладым, уйладым да үземне матурлык өлкәсендә сынап карарга булдым. Махсус курслар узып, кашлар, макияж ясый башладым.

Халыкта «кулдан килә» дигән төшенчә бар бит. Туташ-ханымнарны бизәндерү кулыма ятып торган эш булып чыкты. Тора-бара даими клиентларым барлыкка килде.

Аннары, хатын-кызларда тулы образ тудыру теләгемне чынга ашыру йөзеннән, прическалар да ясый башладым. Шатлыкка, монысы да кулымнан килде. Алай гына да түгел, чәчләр белән эшләү миңа шулкадәр ошады ки, инде прическа ясау белән генә чикләнергә теләмәдем. Һәм, бер ел элек махсус курсларда белем алып, чәчтарашчы серләрен үзләштердем. Шулай ук кашлар, макияж, прическалар ясауны да дәвам итәм.

***- Матурлык өлкәсендә эшләүче нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?***

- Иң беренче чиратта, кешенең эчке дөньясын, аның рухи байлыгын, матурлыгын күрә белергә кирәк. Шушы төшенчәләр киемдә, прическада, макияжда чагылыш табарга тиеш. Ягъни теге яки бу кешенең характер үзенчәлекләрен, көчле һәм, киресенчә, йомшаграк якларын, канына сеңгән гадәтләрен исәпкә алып, тулы образ барлыкка китерү мөһим.

Шулай ук хатын-кызның яисә ир-атның индивидуальлеген ассызыклый белергә кирәк, дип саныйм. Әйтик, кеше кәдрә чәчле икән, аның шушы үзенчәлеген, табигыйлеген саклап калырга.

Гомумән әйткәндә, чәчтарашчы берникадәр дәрәҗәдә психолог булырга тиеш. Һәм иң әһәмиятлесе шул ки, үзеңә рухи яктан бай булырга кирәк. Шул вакытта син башкаларның эчке матурлыгын күрә беләчәксең, аларның халәтен аңлый алачаксың.

***- Гадәттә, кешегә ошаса, ул һәрвакыт бер үк остага мөрәҗәгать итә. Синең дә даими клиентларың бардыр?***

- Әйе, кашлар, макияж, прическа ясатыр өчен дә, чәч кистерер өчен дә даими рәвештә килүчеләр бар. Мактанып әйтүем түгел, кешеләр минем хезмәтемнән канәгать булып китәләр, шуңа күрә әйләнеп киләләр.

***- Чәч кистерергә килгән клиентларыңа киңәшләреңне бирәсеңме?***

- Әйе, биргәлим. Әмма беркайчан да фикеремне көчләп такмыйм. Кемдер үзе миннән киңәш сорый. Бик мөстәкыйль клиентлар да очрый: чәчен ничек итеп алдырачакларын инде анык белеп киләләр.

***- Осталыгыңны ничек камилләштерәсең?***

- Танылган осталар үткәргән мастер-классларга йөрим, курслар үтәм.

***- Синеңчә, яхшы чәчтарашчы нинди булырга тиеш?***

- Югары дәрәҗәдәге һөнәр иясе булырга. Даими рәвештә осталыгын камилләштереп торырга. Үз эшен җан-тәнен биреп, яратып башкарырга. Алда әйтеп үткәнемчә, кешенең индивидуаль сыйфатларын күрә, эчке дөньясын сиземли белергә тиеш.

***- Хәзер адым саен чәчтарашханәләр. Конкуренция зур, дип әйтәсем килә...***

- Конкуренциядән курыкмыйм. Үз эшен югары дәрәҗәдә, җиренә җиткереп, чын күңелдән башкаручы остага клиентлар һәрвакыт табылачак, дип саныйм.

Аннары кешеләр үзләренә рухи яктан, ягъни аурасы-җан халәте туры килгән осталарны сайлыйлар бит.

Әйтик, кемгәдер минем белән уңай, аралашуы кызык, рәхәт булачак. Ә кемгәдер – юк.

Гадәттә, кешегә оста һәрьяклап ошады икән, ул аның даими клиентына әверелә.

***- Үз эшеңдә иң ошаганы нәрсә?***

- Гомумән, хезмәтемне сөеп башкарам мин. Әйткәнемчә, кул белән эшләргә, матурлык булдырырга, иҗат итәргә яратам. Кешенең минем хезмәтемнән тулысынча канәгать булып, елмаеп, чын күңеленнән рәхмәтләрен белдереп китүе – шунысы иң ошаганы. Бу мизгелләр мине канатландыра, илһам өсти.

***- Хезмәтеңдәге төп кагыйдә?***

- Иң мөһиме – зарар китермәскә. Һәрбер клиентка игътибарлы-

лык, ихтирам, кайгыртучанлык күрсәтергә. Шулай ук эш урынының, инструментларның чиста-пөхтә булуы да мөһим булып тора.

***- Матурлык өлкәсендә эшләүчеләрне берникадәр дәрәҗәдә психологлар, дип атарга була, чөнки кешеләр аларга үз серләрен ачалар, киңәш сорыйлар, нәрсәгәдер зарланалар. Моңа мөнәсәбәтең ничек?***

- Мин кеше тормышына кысылмаска тырышам. Моң-зарларын тыңларга туры килә, әмма киңәшләремне бирмим. Ә болай нейтраль темаларга, әлбәттә, аралашам. Бигрәк тә карашлары минеке белән туры килә икән, сөйләшер сүзебез бар. Кайбер клиентларым белән хәтта дуслашып ук киттек.

***- Син хатын-кызларның да, ир-атларның да, балаларның да чәчен кисәсең. Кем белән эшләве кыенрак?***

- Нарасыйлар белән авыррак. Алар бер урында тик утырырга яратмыйлар бит, боргаланалар. Ир-атлар белән эшләве - иң җиңеле, чөнки алар – конкрет кешеләр.

***- Салоныгызда хәйриячелек акцияләре дә уза икән. Шул турыда сөйләп үтсәң иде. Бу эш ничегрәк башланып китте?***

- Әлеге идеяны безгә салоныбызның директоры Наталья Кудинова бирде. Ул балалар йортлары белән эш итүче бер хатын-кыз белән дус. Натальяханымның шушы тәкъдиме белән шатланып ризалаштык. Һәм менә инде 3 – 4 еллар без, берничә чәчтарашчы, Яңа ел алдыннан “Ровесник” приютына барып, анда тәрбияләнүче малайлар-кызларның чәчләрен бушлай кисәбез һәм бүләкләр өләшәбез.

Шулай ук аерым үзем аена ике мәртәбә анда йөрим.

***- Әле бит сезнең салонда Даун синдромы булган балалар өчен дә хәйриячелек акцияләре үткәрелә?***

- Әйе. Аена бер мәртәбә, якшәмбе көнне, чәчтарашханәбездә шундый малайларның-кызларның чәчләрен бушлай кисәбез.

Аларны яратам мин. Һәрберсенең исемен беләм. Үзләре белән аралашам. Дөрес, Даун синдромы булган нарасыйларның кайберәүләре бөтенләй сөйләшми диярлек.

Әмма араларында Пушкин әсәрләрен яттан укучылар да, яхшы сөйләшүчеләр дә бар.

Бик боргаланмасыннар өчен, әти-әниләре үзләрен сөйләштерәләр, телефоннан мультфильм күрсәтәләр. Ә кайсыберләре гомумән тыныч кына утыра. Һәрхәлдә, уртак тел табабыз.

Күпләре даими рәвештә килеп йөри инде. Акция турында күптән түгел генә ишетүчеләр дә бар.

Зәгыйфь нарасыйларга һәм аларның ата-аналарына, “Ровесник”та тәрбияләнүче ятим балаларга аз гына булса да ярдәм итә алуыма сөенәм мин. Малайлар, кызлар белән аралашуы, аларның шатлыклы йөзләрен,



елмаюларын күрүе, ихлас рәхмәт сүзләрен ишетүе җанымны җылыта. Гомумән, хәйриячелек белән шөгыльләнә башлагач, рухи яктан байый төштем. Татар халкы: “Кешегә игелек итсәң – үзеңә булышасың”, - дип юкка гына әйтми бит инде. “Матурлык – бер көнлек, игелек – мәңгелек”, дигән күркәм мәкаль дә бар. Кемгәдер ярдәм күрсәтә, файдалы була алуым күңелемне күтәреп җибәрә, илһамландыра. Хәйриячелек эше шулкадәр ләззәтле хезмәт икән бит ул! Аны башлап җибәргән директорыбыз Наталья Кудиновага мең рәхмәт.

***- Розалия, акыллы, тәртипле, миһербанлы кыз икәнең күренеп тора. Бу әти-әниең тәрбиясенең нәтиҗәседер инде?***

- Әтием Хәмит, әнием Шамилә – искиткеч кешеләр. Үз гомерләренә тырышып эшлиләр, без, балалары, өчен өзелеп торалар. Ярдәмчел, намуслы, әдәпле, игелеклеләр. Татар-мөселман гореф-гадәтләрен үтәп яшәргә тырышалар. Апам Эльми-



ра белән мине үз үрнәкләрендә тәрбияләделәр алар. Без аларга бик рәхмәтле. Исән-сау, озын гомерле була күрсеннәр.

***- Чәчтарашханәдә дә эшлисең, каш, макияж да ясыйсың, хәйриячелек белән дә шөгыльләнәсең, бераз буш вакытларың каламы соң?***

- Андый чакларда китаплар укыйм. Спорт белән шөгыльләнәм - йөгерәм, байдаркада йөзәм.

***- Тормышта теләгәнеңә ирештем, дип саныйсыңмы?***

- Дөресен әйткәндә, мин хәзер әле яши башлаган гына кебек. Күңелемә яткан, яратып башкарган эшкә керештем генә әле. Шуңа күрә киләчәккә максатларым зурдан. Рухи яктан да, профессиональ яктан да үсәргә кирәк.

Сүз уңаеннан, мине башлангычларымда һәрвакыт хуплаган, ярдәм кулын сузган, илһамландырып торган ирем Альбертка рәхмәтемне белдерәем килә.

***- Уй-ниятләреңә ирешергә язсын, Розалия!***



# “ТОРТЛАРЫМНЫ “БИСМИЛЛӘҺ” ӘЙТЕП ПЕШЕРӘМ”



***“Тортларымны “бисмилләһ” әйтеп пешерәм, шуңа күрә алар уңалар да”, - ди кешеләрне татлы ризыклар белән шатландыручы яшь милләттәшебез - Җәмил кызы Юлия Волкова.***

***Миләүшә Газимова.***

Югары уку йортын тәмамлагач, җәмәгатьчелек белән элемтәдә торучы белгеч почтада логист булып эшләгән. Икенче улын табып, янәдән декрет отпускасына киткәч, торт пешерү серләренә өйрәнә башлаган ул.

Ике ел эчендә кулын шомартып, тәҗрибә туплап, искиткеч матур итеп бизәлгән, тәмледән-тәмле тортлар ясаучы остага әйләнгән Юлия. Аның тортлары берберсен кабатламый, бизәү ягыннан да, тәме буенча да һәрберсе үзенчәлекле. Чөнки эше конвейерга салынмаган, шуңа күрә иҗат итәр өчен мөмкинлеге бар.

***- Тортлар пешерү идеясы ничек барлыкка килде?*** – дип кызыксындым әңгәмәдәшемнән.

- Бервакыт иремнең әбисенең туган көненә бардык. Бәйрәм уңаеннан каенанам баллы (медовый) торт пешергән иде. Ул миңа шулкадәр ошады ки, аны үзем ясап карарга булдым. Рецептын алып, бабамның туган көненә беренче тортымны пешердем. Бизәлеше гади генә булса да, бик тәмле килеп чыкты һәм барысына да хуш килде.



Бу мине канатландырып җибәрде. Шулай әкрен генә интернеттан торт пешерү серләрен үзләштерә башладым. Төрле мастер-класслар карый идем. Осталардан түләүле дәресләр дә, рецептлар да алдым. Шулай үзлегемнән өйрәнеп киттем, - дип сөйли Юлия.

Башта үзләре, якыннары, туганнары, дуслары өчен пешерә ул. Аннары иптәшләре: “Тортларың бигрәк тәмле дә, матур да, нигә аларны заказга ясамыйсың?” – дип тәкъдим итәләр.

- Беренче заказ бирүчеләрем нәкъ дусларым иде. Иптәш кызым баласының туган көненә торт пешерергә сорады. Аны мультфильм персонажлары белән бизәдем. Шуннан соң алар:

“Бүтән кибеттән торт сатып алмаячакбыз!” - диделәр (елмая).



Тора-бара, бер-берсеннән ишетеп, башка заказ бирүчеләр дә барлыкка килде. Социаль челтәрләрдә үз битемне алып барам, аннан да күреп беләләр, - ди милләттәшебез.

***- Беренче мәлләрдә нинди авырлыклар белән очрашырга туры килде?*** – дип сорыйм үзеннән.

- Килеп чыгармы икән, дип бик борчыла идем. Торт тәмле дә, тигез дә, матур итеп бизәлгән дә булырга тиеш бит. Ул беренче карашка гына җиңел кебек. Әмма бу эшнең нечкәлекләре бик күп! Шул ук крем төрле температура йогынтысы астында үзгәрергә мөмкин. Суыткычта ул яхшы саклаinitialначак та бит, ә менә юлда нишләр. Шуңа күрә барысын да алдан җентекләп уйлап эш итәргә кирәк.

Мастикадан фигуралар ясавы да баштагы чакларда авыррак булды.

Хәзер инде, Аллаһыга шөкер, тәҗрибәм дә артты, кул да шомара төште.

***- Иң яратып пешерә торган тортың нинди?***

- Яңа елга чыршы формасындагы тортлар, шикәр ширбәте (глазурь) ярдәмендә бияләй, кыш бабай, кар бабай (снеговик), кар бөртекләре сурәтләре төшерелгән прәннек-печеньелар ясарга, аларны матур итеп төргәкләргә ошый миңа. Өйдә бәйрәм рухы хөкем сөрә, күңелдә тылсымлы хисләр уяна, кәеф күтәрелеп китә.

***- Димәк, син тортлар гына түгел, ә прәннек-печеньелар да пешерәсең?***

- Әйе, капкейклар, трайфллар, кекслар да пешерәм. Аларга кешеләр бәйрәм уңаеннан гына түгел, болай чәй янына гына да заказ бирәләр, чөнки күпләрнең химия кушып җитештерелгән татлы ризыкларны кибеттән сатып аласылары килми. Ә мин тортлар, прәннек-печеньелар ясаганда бары тик табигый, югары сыйфатлы ингредиентлар кулланам.

***- Тортларны бизәр өчен идеяларны кайдан аласың, кайдан илһам туплыйсың?***

- Идеялар үзеннән-үзе барлыкка килә. Тирә-яктагы гүзәллекне күрә белергә кирәк.

Балалар белән урамда йөргәндә дә мин һәрвакыт матурлыкны күзаллыйм. Табигать илһамландыра. Интернетта берәр нинди искиткеч рәсем күреп аласың. Гомумән, гел уйланып, фантазияне эшләтеп торырга туры килә.

Мин үз-үземә бик таләпчән. Пешергән ризыкларым тәм буенча да, бизәлеш ягыннан да идеаль булырга тиеш.

***- Әзер рецептларны үзгәртәсеңме, үзеңнән берәр нәрсә өстисеңме?***

- Әйе, кайчакта ниндидер ингредиент өсти алам. Әмма гадәттә технологик карталар буенча пешерәм. Ә менә инде тортны бизәгәндә иҗат өчен киң мөмкинлекләр ачыла.

**- Нинди тортларга ешрак заказ бирәләр?**





- Балаларының, якыннарының туган көннәренә.

***- Татлы ризыкларны пешерүдә үз серләрең бармы?***

- Әйе, бар, әлбәттә. Тик аларны берсенә дә чишмим (көлә).

***- Нинди тортың белән горурлана аласың?***

- Ике ярусы, 6,5 килограммлык тортым белән горурланам. Аны, тере чәчәкләр белән бизәп, юбилейга пешергән идем. Ерак юлны узып та, ул бик яхшы сакланды.

Ике-өч ярусы тортларны ясавы күпкә авыррак. Бик күп нечкәлекләрне күздә тотарга кирәк.

***- Нинди заказ аеруча исеңдә калды?***

- Туйга чәчәкләр арасында кәләш белән кияү фигуралары сурәтләнгән тортка заказ биргәннәр иде.

Ул чәчәкләрне мастикадан ничек итеп дөрес ясарга кирәклеге турында өч көн уйланып йөрдем (көлә). Таҗ яфракчыкларын берберсенә туры китереп, тигез итеп формалаштырырга кирәк иде. Аллаһыга шөкер, нәтиҗәдә чәчәкләрем тере кебек килеп чыкты.

***- Тортлар пешерү синең өчен кәсепме әллә иҗатмы?***

- Иң беренче чиратта, иҗат. Кешеләрнең минем хезмәтемнән канәгать булып калуы, елмаеп, рәхмәт әйтүләре илһам өсти. Бигрәк тә балаларның ничек шатланганын күрсәгез икән! Шуларның барысы да минем өчен зур бүләк, сөенеч, иҗат җимешләремә югары бәя булып тора.

***- Теләсә кем, синең кебек, торт пешерү остасы була аламы әллә Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сәләт кирәкме?***

- Теләсә кем өйрәнә ала, дип саныйм, тик моның өчен, иң беренче чиратта, ихлас теләк кирәк. Әлеге максат белән янарга тиеш син. Һәм, әлбәттә инде, сабырлык таләп ителә.

Мин эшемне бик яратып, җанымны биреп башкарам. Төн уртасында уянып, тегеләй ясасам, ничегрәк булыр, болай итсәм, яхшырак түгелме икән, дип уйланып яткан чаклар да күп.

***- Юлия, ике малай тәрбиялисең. Вакытны ничек җиткерәсең?***

- Иремә мең рәхмәт. Ул миңа һәрнәрсәдә дә ярдәм итә. Торт пешерү өчен кибеттән кирәкле ингредиентларны да алып кайта. Балалар белән дә шөгыльләнә.

Заказлар күп булганда төнлә эшләргә дә туры килә.

***- Сине акыллы, тәртипле кыз буларак беләм. Бу – әтиәниең тәрбиясенең нәтиҗәседер? Аларның нинди үгет-нәсыйхәтләрен күңелеңә сеңдереп, үтәп яшисең?***







- Барлык яхшы сыйфатларны сеңелем Румия белән миндә әтиебез Җәмил, әниебез Роза, бабабыз Касыйм, әбиебез Мәдхия тәрбияләделәр. Алар безне мәрхәмәтле, эш сөючән, ярдәмчел, сабыр булырга, кешеләргә хәлдән килгәнчә булышырга, олыларны хөрмәт итәргә, кечеләрне үпкәләтмәскә өйрәттеләр. Барысын да үз үрнәкләрендә күрсәтеп үстерделәр.

Кызганычка, әти генә быел вакытсыз вафат булды шул.

Ә татар телендә сөйләшкәнем өчен мин әти-әниемә һәм бабама, әбиемә аеруча рәхмәтле. Гаиләбездә һәрвакыт ана теле яңгырады.

Бездә “мама”, “папа” сүзләре ишетелмәде, “әтием”, “әнием”, “әбием”, “бабам”, дип эндәштек.

Әби-бабай кечкенәдән догалар өйрәттеләр, динебезгә мәхәббәт тәрбияләделәр.

Ана телемне белүемә шатланам, татар кызы булуым белән горурланам! Улларымда да телебезгә, милләтебезгә, Исламга, гореф-гадәтләребезгә сөю хисен сеңдереп үстерергә тырышам.

***- Синең өчен гаилә яисә карьера мөһимрәкме?***

- “Мөселманның көймәсе елганың уртасыннан барырга тиеш”, диләр. Динебез Ислам буенча да уртадан бару хәерле. Икесе дә мөһим. Әмма татар халкында гомер-гомергә хатын-кыз гаилә учагын саклаучы булган. Гаиләбез – безнең терәгебез, тормышта иң мөһиме, дип саныйм.

***- Синең өчен бәхет нәрсәдә?***

- Якыннарымның исән-сау, янымда булуы.

***- Нинди планнар белән янып яшисең?***

- Тортлар пешерүдә осталыгымны камилләштерергә, тәҗрибәмне баетырга телим. Гомумән, бер урында торырга ярамый, һәрвакыт үсештә булырга кирәк, чөнки бу өлкәдә даими рәвештә яңалыклар барлыкка килә. Шуларны күзәтеп, өйрәнеп, кулланып тору мөһим.

Шулай ук антигравиацион тортлар ясарга өйрәнергә хыялланам.

# “ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ МИНДӘ ТИРӘН ХИС-ТОЙГЫЛАР УЯТА”



Танылган җырчы Салават Фәтхетдиновның: *“Сандугач керде күңелгә – Җырламый түзиммени?”* – дип моңланганын хәтерлисезме?

*Миләүшә Газимова*

Менә Самар кызы Алсинә Дәүләтбаеваның да күңеленә сандугач кергән икән бит!

Кечкенә чагыннан ук җырларга яраткан яшь милләттәшебез хәзер сәхнәдән төшми. Шәһәребез һәм өлкәбездә үткәрелеп килгән Сабан туйларында, башка татар чараларында чыгыш ясый ул. 20 яшьлек Алсинәнең үз тамашачылары да барлыкка килгән инде. Ә күптән түгел аны Самарның Мидхәт Әминов җитәкчелегендәге танылган “Идел” татар ансамблена солистка буларак кабул иткәннәр.

Алсинәнең моңлы, чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышы йөрәкләргә үтеп керерлек, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек. Үз җиребездән тагын бер моңлы сандугач үсеп чыкканына, милли мәдәниятебезнең киләчәге якты булуына куанырлык түгелмени?!

Алсинә әле “Яктылык” мәктәбендә укыган чагында ук, әлеге уку йортының мәдәни тормышында актив катнашучыларның берсе буларак, минем игътибарымны җәлеп иткән иде. Җырга да, биюгә дә оста булган бу кыз бирердә узган бер чарадан да читтә калмады.

- Мин иҗади гаиләдә тәрбияләндем. Әбием дә, әти-әнием дә матур итеп җырлыйлар. Әби шигырьләр дә иҗат итә әле. Җырмонга сәләтем нәселдән күчкәндер



инде. Сәнгатькә мәхәббәт балачактан каныма сеңгән.

Талантларымны ачарга һәм күрсәтергә ярдәм иткән “Яктылык” мәктәбенә, аларны күрепсизеп алган укытучыларыбыз - Асия Сәйфетдинова, Линар Абсаттаров, Инзилә Гыйззәтуллинага рәхмәтле мин, - дип сөйли әңгәмәдәшем.

***- Алсинә, син оста биюче дә бит әле. Бүгенге көндә бу сәләтеңне халыкка күрсәтү мөмкинлеге бармы?***

- Әйе, күптән түгел “Яктылык” мәктәбен төрле елларда тәмамлаган егетләр-кызлардан торган “Якты” бию төркеме барлыкка килде. Хореографыбыз Рәшит абый Гыйззәтуллин куйган биюләр белән туйларда, юбилейларда чыгыш ясыйбыз. Киләчәктә, Аллаһы бирсә, төрле бәйгеләрдә катнашу нияте дә бар.

***- Син татар телендә генә җырлыйсыңмы?***

- Сәхнәдән татар җырларын гына башкарам.

***- Сәхнә дигәннән... Анда үзүзеңне тота белергә кирәк бит әле.***





- Әйе, вакытында елмая белергә, вакытында моңсу хисләр күрсәтергә кирәк. Бу инде, әлбәттә, нинди җыр башкаруыңа карап. Һәрхәлдә күңелемдәге кичерешләрне, тойгыларымны тамашачыга җиткерергә тырышам.

Аннары кием дә зур роль уйный. Мәсәлән, миңа татар милли костюмнарында чыгыш ясарга ошый.

***- Нинди характердагы җырларны яратып башкарасың?***

- Шул мизгелдәге эчке кичерешләремә туры килгәннәрне. Йөрәк түреннән ургылып чыккан җыр тагын да ихласрак яңгырый бит ул.

***- Озын көйле җырлар җырлыйсыңмы?***

- Андый җырлар күңелемә аеруча хуш килә. Әбиемнең “Кыр казлары артыннан”, “Шаулый урман”, “Мәк чәчәге” татар халык җырларын башкаруын тыңлап үскән кыз мин. Алар кечкенәдән җанга кереп калган.

Татар халык җырлары – милләтебезнең моңлы хәзинәсе, рухи мирасы, безнең тарих ул. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай: “Халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер», – дип юкка гына әйтмәгән инде.

Татар гомер-гомергә җырмоңга хирыс булган. Халкыңның ни өчен моңлы икәнен беләсең килсә, тарихка күз салырга кирәк шул. Татар милләтенең язмышы катлаулы, ата-бабаларыбызга күп авырлыклар аша үтәргә туры килгән. Шушы кичерешләре моң булып агылган да күңел түренә үтеп керерлек җыр-көйләр барлыкка килгән, дип уйлыйм.

“Ачы тау”, “Сагыну” татар халык, Хәния Фәрхи башкарган “Авыл киче” җырларын җырлыйм. Алар миндә тирән хис-тойгылар уята, уйланырга этәрә.

***- Яраткан җырчыларың кемнәр?***

- Хәния Фәрхинең иҗаты бик якын иде миңа. Илсөя Бәдретдинова, Салават Фәтхетдиновка сокланам.

***- Профессиональ җырчы булу, татар эстрадасында халыкка үзеңне таныту теләгең бармы?***



- Андый хыялым юк түгел. Киләчәк күрсәтер. Аллаһы насыйп итсә, бар да булыр, дип ышанам.

***- Алсинә, башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрен сайлап алгансың. Моңа “Яктылык”та мөгаллимә хезмәтен башкаручы әниеңнең тәэсире тиделме?***

- Әйе, татар теле һәм әдәбиятын укыткан әнием эшен шулкадәр яратып башкара ки, бу миңа йогынты ясамый калмады. Аның эзеннән китеп, шушы һөнәргә өстенлек бирдем. Балаларны сөю дә зур роль уйнады, әлбәттә.

Педагогика университетына “Яктылык” юлламасы буенча укырга кердем. Якын киләчәктә туган мәктәбемдә эшләячәгемә бик шатмын. Бүгенге көндә биредә ике айлык практика үтәм.

***- Кемнәрдән үрнәк аласың?***

- Нәҗия әбиемә сокланам. Ул шундый көчле рухлы шәхес ки, исләрең китәр! Әтием Илдус, әнием Фәүзия, апам Алисә гомер буе миңа үрнәк булып торачаклар.

Гомумән, гаиләм белән горурланам мин. Ул – тормышымда иң кыйммәтлесе, иң мөһиме.

***- Әти-әниең биргән нинди үгет-нәсыйхәтләр күңелеңә уелып калды?***

- Әгәр дә уңышлар казанырга, югары үрләр яуларга телисең икән, моның өчен бик нык тырышырга һәм бик күп эшләргә кирәк, дигән сүзләрен гомерлеккә исемдә калдырдым.

Алар үзләре дә - эш сөючән, барысына да үз көчләре белән



ирешкән кешеләр, безне дә шуңа өйрәтәләр.

Алмагач астында: "Алма пеш, авызыма төш", - дип ятып торып булмый. Үз алдыңа максатлар куеп, шуларны тормышка ашырыр өчен, җан-фәрман эшләргә кирәк.

***- Синеңчә, камил гаилә нинди булырга тиеш?***

- Минем өчен әти-әнием – камил гаилә. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен күреп, чын күңелдән шатланам мин. Бер-берсен ихластан яраталар. Булачак ирем әтиемә охшаган булсын иде, дип телим.

***- Әти-әниеңнең кайсы сыйфатларына сокланасың?***

- Сабыр, алда әйтеп үткәнемчә, хезмәт сөючән кешеләр алар. Һәрвакыт мине аңлыйлар, ярдәм кулын сузалар. Мин үзләренә мең рәхмәтле.

***- Ә апаң Алисә белән мөнәсәбәтләрегез ничек?***

- Яшь аермабыз тугыз ел булса да, аның белән бик дус, туганлык җепләре нык безнең. Кияүгә чыгып, хәзер аерым яшәсә дә, без һәрвакыт аралашып, күрешеп торабыз.

***- Җитди карарлар кабул итәргә кирәккәндә кем белән киңәшәсең?***

- Күпне күргән-белгән, тормыш тәҗрибәсе бай булган әбиемнең киңәшләре минем өчен бик мөһим.

***- Үзеңнең холкыңны бер-ике сүз белән ничек тасвирлар идең?***

- Мин - дөреслекне биткә бәреп әйтүче, туры сүзле кеше һәм башкалардан да үземә карата шуны таләп итәм. Әмма, әлбәттә, кешене үпкәләтергә ярамый, әдәпле, тыйнак кына сөйләшергә кирәк.

***- Тормышыңда берәр нәрсәне үзгәртер идеңме?***

- Аллаһыга шөкер, барысыннан да канәгать мин. Булганына сөенеп яшим. Әлбәттә, киләчәккә ниятләр зурдан. Әмма барысы да Аллаһы Тәгалә кулында. Аның ярдәме белән аларны тормышка ашырырга язсын.

